Миңзифа
Әхмәтшина

# САРЫ ЯУЛЫК



Хикәяләр, парчалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ә87

**Әхмәтшина, М.Х.**

Ә87 Сары яулык : хикәяләр, парчалар / Миңзифа Әхмәтшина ; кереш сүз авт. Л.Кәшфи. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 143 б.
ISBN 978-5-298-01908-8

Миңзифа Әхмәтшина хикәяләренә авыл тормышы үзенең бөтен тулылыгы белән килеп керә. Авыл кешеләренең уй-хисләр дөньясы, психологиясе, фикер сөреше, әйләнә-тирәгә һәм бер-берсенә мөнәсәбәте әсәрләргә ниндидер ихласлык, күңел садәлеге өсти.

«Сары яулык» китабында М.Әхмәтшинаның соңгы елларда иҗат ителгән хикәяләре һәм парчалары тупланды.

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-01908-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Әхмәтшина М.Х., 2010

## *Иҗат кыйбласы — ихласлык*

Әлмәттә яшәп иҗат итүче каләм иясе Миңзифа Әхмәтшина исеме халыкка Татарстанның халык артисткасы Хәния Фәрхи башкара торган «Бәхетем минем», «Миңа син кирәк» кебек популяр җырлар аша күбрәк таныштыр, мөгаен. Гомеренең күп өлешен авылга багышлаган, мәдәният өлкәсендә актив тормыш алып барган Миңзифа Әхмәтшина шигырьне дә, көйне дә үзе яза, моңлы тавышы белән җырлап җибәрергә дә күп сорамый. Аллаһы Тәгалә аңа язучы каләмен дә, җырлау сәләтен дә, рәссам-бизәүче зәвыгын да биргән. Бүлмә бизәүгә, кием тегүгә генә дә ул әллә никадәр иҗат көчен сала. Бәлки, шуңадыр да аның иҗат ызаннары башкаларны кабатламый. Дөньяны нәкъ үзе күргәнчә чагылдырырга омтыла ул.

М.Әхмәтшина соңгы елларда хикәя жанрында актив эшли. Авыл тормышы аның әсәрләренә үзенең бөтен тулылыгы белән килеп керә. Авыл кешеләренең уй-хисләр дөньясы, психологиясе, фикер сөреше, әйләнә-тирәгә һәм бер-берсенә мөнәсәбәте хикәяләренә ниндидер ихласлык, күңел садәлеге өсти. Авторның табигатькә, тереклек дөньясына булган мәхәббәте, җылы мөнәсәбәте укучыда миһербанлылык хисе тәрбияли кебек. Тормышта күпне күргән, күпне кичергән әбекәй, ак әби образы, хикәядән хикәягә күчеп йөреп, татар хатыннарына элек-электән хас булган тирән акыл һәм сабырлык сыйфатларын символлаштыра.

Миңзифа Әхмәтшина зур теләк белән, ашкынып, ялкынланып иҗат итә. Аның хикәяләре кешеләргә уңай энергия, оптимизм тойгысы, кешелеклелек хисләре бөркеп тора.

Иҗат юлларың озын, уңышлы булсын, Миңзифа ханым!

*Ләйсән КӘШФИ*

# ХИКӘЯЛӘР

## *Җыр иясен көтә*

Динә уянып киткәндә, машина, ярты юлны узып, туып үскән районының биләмәләренә килеп кергән иде инде. «Эх, йоклап кителгән, таныш җирләрне карап кайтырмын дигән идем», – дип уфтанып алды ул. Арылган... Машинасы да бик җылы туры килде, шуңа оеп кителгән. Иномарканың тавышы да ишетелми. Күптән шулай озын юлга чыкканы юк иде бит. Элек, нинди вакыт булуга карамастан, төнме, таң атканмы, яңгыр-буранмы – уйлап та бирмәс, авырсынып та тормас иде. Йә каладагы кызы янына, йә туган-тумачаның, дусларның хәлләрен белеп кайтыйм дип чыгар да китәр иде. Ә хәзер? Дөресен генә әйткәндә, хәзер алай китеп-кайтып йөрерлек мөмкинлеге дә юк. Бер генә көн буш вакыты чыкты исә, әниләре янына гына кайтып хәл белеп килер иде. Юк, бер көндә генә җитешеп булмый шул, ара ерак. Тик шулай да сагындыра туган җир...

Аерылулар тиз булса да,<br>Күрешүләре озак... –

дип, эчтән генә җыр да сузып алды ул. Әйе, Динә туган ягын, әти-әнисен, авылын сагына! Тик болай ук юксынырмын дип уйламаган иде ул зур калага күчеп киткәндә. Чит җиргә тиз ияләште ияләшүен... Барып төшүгә, күңеленә хуш килердәй эше, хан сарае ук булмаса да, торыр урыны табылды. Тик шәһәргә генә һаман күнегеп бетә алмый. Әнә бит үзенең туган җирләрен күрү белән йөрәге ничек сөенә. Тәрәзәгә күз салмыйча тоеп кара син аны. Бераз онытылсын, яралар төзәлсен дип кайтмый торуына да бер ел вакыт узып киткән ич... Сагынылган!

Яз. Кырлар инде кардан арынган. Анда-санда ермак-елга буйларында гына күренә күренүен. Авыл халкы йокламый инде. Тормыш рәтен белә якташлары, иртә таңнан басуда, эштә. Авыл кешесе кулы белән генә түгел, җаны-тәне белән тоя җир сулышын. Кайчан сукага, кайчан тырмага чыгасын күңелләре белән сизеп торалар. Кырда тракторлар мәш килә. Күңеле белән алар янына да барып кайтты Динә, дегетле, соляркалы кулларыннан тотып исәнләште райондашлары белән. Үзенең дә кырда эшләгәне күп булды аның. Төнге утлар яктысында «ДТ-75» тракторы белән буразна сызып йөргәне әле дә исендә. Эх, яңадан бер ялантәпи басып торасы иде шул буразнага, җир җылысын тәнең белән тоясы иде. Ярата Динә җирне, туфракны ярата. Берәрсенең җиргә түкергәнен күрсә дә рәнҗи, әллә нишләп китә. Әти-әнисе бала чакларыннан ук:

– Җир ул – изге нәрсә, балам, аңа төкерергә ярамый, – дип, яхшыдан яманны аерырга өйрәттеләр...

Машина матур гына барган җиреннән кинәт сөрлегеп киткәндәй ямьсез итеп сикереп куйды. Динә, тотынып өлгерә алмыйча, күкрәге белән алдагы урындыкка барып төртелде.

– Уйланып бара идегез бугай? – диде көтмәгәндә шофер, саф татарча итеп. Аннан акланып: – Сезнең якның юллары шулайрак шул.

– Машинагыз бик зур, минем кебек бәләкәй буйлы кешегә тотынып калуы да кыен, – диде Динә. Шоферның татарча сөйләшүенә гаҗәпләнеп: – Мин сезне урыс кешесенә охшаткан идем, – дип тә өстәде.

– Ә мин сезне марҗа дип торам. Ак чәчле, зәңгәр күзле татар кызларын күргәнем юк иде.

Юлда авария-мазар булганмы, бик күп машиналар тезелгән. Алар бер-берсенә карашып алдылар. Күзләре очрашкач, бөтенләй кыен булып китте Динәгә. Өстенә кайнар су бөркеделәрмени, бер сәбәпсез кызарып чыкты. Ярый әле шофер сизми калды. Көләр иде, кызлар

кебек ояла да беләсең икән әле дияр иде... Бәлкем, үртәмәс тә иде. Кем белгән аны...

Алда, чынлап та, нидер бар бугай, юлны аркылыга бүлеп, «КамАЗ» машинасы тора. Шуңа ике яктан да юл томаланган, бөке хасил булган. Ә юл читендә әйләнеп капланган җиңел машина ята.

Шофер джипны шып итеп туктатты һәм кабинадан сикереп диярлек төште дә:

– Болай калдырып булмый инде, – дип, аста яткан машина янына йөгерде.

Яхшы ук түбән очкан «Жигули»га, бәхеткә каршы, берни дә булмаган. Тик, куркудан ап-ак булып агарган, машинаның бер алдына, бер артына чыга-чыга аптырап беткән техника хуҗасы гына йөри.

– Нишләргә дә белгән юк иде, сез туктамасагыз, башка туктаучы юк. Бик ярдәмчел түгел шул хәзерге халык, – дип рәхмәтләр укыды бәлагә таручы.

Куәтле джип җиңел машинаны «эһ» дигәнче тартып менгерде. Куллар кысышып, рәхмәтләр әйтеп саубуллаштылар. «Жигули» да, әкрен генә кузгалып, үз көенә кайтып китте.

– Обгонга чыгып, авария тудырган машина туктап та тормаган, – дип орышып алды шофер. Аннан канистрын урындык астыннан сөйрәп чыгарып: – Кулыма су салып торалмассыз микән? – дип, Динәгә эндәште.

Машина биек, шуңамы, Динә, кабинадан сикереп төшкәндә, чак кына егылып китмәде. Сизгер шофер аның кулыннан тотып өлгерде. Һәм аларның күзләре кабат очрашты...

– Кызлар кебек кызарасыз икән... Әйдәгез танышыйк, мин Булат булам.

– Мин – Динә.

– Исемегез дә матур, үзегезгә туры килә.

– Сезнеке дә.

– Әйдә, Динә, алгы урындыкка күчеп утыр әле. Юл да озын, миңа да артка карап сөйләшүе җайсыз.

Янәшә утыргач, күпмедер вакыт сүзсез бардылар. Әллә каян сүз табасы, сөйләшеп-сорашып кайтасы иде, кем икәнен, кайдан икәнен беләсе килә Динәнең. Йөртүче, аның уйларын сизгән кебек:

– Әллә авылда торасыңмы? – дип сорап куйды.

– Әткәй белән әнкәйнең хәлен белеп китим дигән идем. Бер ел кайтканым юк. Телефоннан гына сөйләшү күрешү түгел инде ул...

– Минем әткәй дә, әнкәй дә юк. Әткәйне хәтерләмим дә. Миңа өч яшь тулгач вафат булган. Әнкәй... – Шуннан соң бик озак дәшми торды Булат. Нindидер хатирәләре яңардымы? Динә ашыктырмады. – Саклый алмадым шул мин әнкәйне, – диде Булат, авыр сулап. – Мин бишенче сыйныфта укыганда кинәт чирләп китте. Нинди авыру булгандыр, көне-көне белән урыныннан да тормый, башын кысып бәйләп, гел түшәктә ята иде, бәгырькәем. Мин, мәктәптән кайткач, үзең беләсең, бала-чага бит инде, өстәлдә ни бар шуны капкалыйм да малайлар белән урамга чабам. Кайчагында дәү әни килеп, бер-ике көн бездә торып, керләр юып, ашарларга пешереп китә. Ул чагында урамга чыгу юк инде. Дәү әни: «Әй, кыз бала булсаң, әниең кырыннан китмәс тә идең», – дип ачулана-ачулана өйдә тота, дәрес әзерләтә. Ул безгә килгән көннәрдә мин дә яхшы гына билгеләр алгалыйм. Тик бу үзенә күрә бәхетле көннәр озакка бармый, өйдә бабай да ялгыз бит.

Тугызынчы сыйныфта укыганда, әнинең сырхавы тагын да көчәйде, табиблар операциягә тәкъдим итсәләр дә: «Баламның иң җаваплы чоры, ничекләр генә ялгыз калдырыйм нарасыемны», – дип кире какты...

Булат, машинасын әкренәйтә барып, юл читенә чыгып туктады. Озак итеп ян тәрәзәгә карап торды да, маңгаен рульне тоткан беләге өстенә куеп, үксеп еларга тотынды...

Динә бу хәлдән аптырап калды. Нишләргә? Ничек юатырга? Аның гомерендә бер генә тапкыр да ир-атның

менә шулай үксеп елаганын күргәне юк иде. Үзенең дә чигәләрен кысып, күзләрен әчеттереп яшь тулды...

Ничек тиз үкси башлаган булса, шулай тиз туктады да Булат. Күз яшьләрен кулъяулыгына сөрткәч:

– Мин сине ерактан ук күрдем. Кул күтәрмәсәң дә нигәдер утыртасым килде. Инде менә бөтен серемне сөйләдем бугай. Берәүгә дә болай чишелгәнем юк иде әле... Әни үлгәч, мин гел саташкан сыман йөрдем. Тугызынчы сыйныфны көчкә тәмамладым. Дәү әнине, калага укырга кердем, дип алдадым да, тырай тибеп тик йөрдем. Кайдан – урлап, кайдан кыйнап акча табабыз. Дусларым да үзем кебек. Кайсының әтисе юк, кайсының әнисе, булганнарыныкы – эчкечеләр...

Булат сөйли-сөйли дә уфтанып, авыр сулап куя. Үткәненә үкенеп, җан газабы кичереп, әрнеп сөйли. Әллә Динәгә сөйләп бөтен хәсрәте бетәр күк тоеламы икән? Ни генә булса да, Динә тыңлый белә. Ул, гомумән, төрле хәлләр тыңларга ярата. Әбисе аңарга кечкенәдән: «Авыз бер генә, колак икәү. Шуңа күрә кеше аз сөйләргә, күп тыңларга тиеш», – дия иде. Ул шулай эшли дә, кайда гына булса да, аны яраталар. Күп сөйләми, тыныч кына тыңлый... Тыңлый, тик бүген менә шушы сау-сәламәт, көчле кеше икәнен белдереп торган олпат гәүдәле бу ир-атны тыңлап утырганда, аның күз алдыннан бөтен бер кеше язмышы йөгереп үтте, күңеленең әллә кай җирен нәрсәдер авырттырып киткән кебек тоелды. Тышкы кыяфәте бик үткен күренсә дә, әле һаман әни назын, әти яклавын юксына торган бер сабыйны хәтерләткән бу затны юатасы, чал чәчләреннән сыйпыйсы килде Динәнең. Шул ук вакытта аны мең төрле сорау да борчый иде. Нигә соң әле Динәгә чишелде ул? Нигә якын итте ул аны?..

– Кыен булды миңа. Берәүгә дә кирәгем юк дип, үзем генә калып елап утырган чакларым аз булмады... Сыенырга туганнарым, дәү әни белән бабай да бар, тик

әнине сагынуымның гына чиге-чамасы юк. Аның үлеменә үземне гаепле саныйм. Онытылыр өчен, тизрәк чирәм төреп тәмәке тартам да кичен кызлар янына... – Булат бераз уйланып торды да яңадан сөйләп китте: – Сез миңа, зинһар, ачуланмагыз, тыңлагыз гына. Бәлки, гыйбрәт өчен кемгә дә булса сөйләрсез. Шундый «балдеж» кичләренең берсендә мин бер кыз белән таныштым. Марҗа кызы Лида иде ул. Дус кызы белән килгән бу чибәркәй, башкалар кебек үк, куна калды. Сөйләшә торгач, үзенең беренче тапкыр мондый компаниядә утырганын, әнисенә бердәнбер кыз булуын, һәм... әнисенең чирләгәнен дә әйткәч, тимәдем. Башкалардан үз сеңлем кебек яклап төн чыктык та, Лиданы тизрәк өенә илтеп куйдым. Култык таягына тотынып каршы алырга чыккан әнисен күргәч, үз әнием килеп чыккандай тоелды миңа. Кызының шулай итеп йөрүенә нык борчылуын күрдем мин бу моңсу күзләрдә. Алар «Эх, улым!» диләр кебек тоелды...

Шул ук көнне бар булган әйберемне, яхшырак киемнәремне сатып, бераз акча таптым да, «дуслар» белән араны өзеп, авылга кайтып киттем. Дәү әни мине каникулга кайтты дип уйлагандыр инде, урыны оҗмахта булсын, мул итеп сумка тутырып озатып калды, җанкисәккәем.

Себергә юл тоттым. Өч ел эшләдем. Институтка кердем, аннан аспирантурада калдым. Бүгенге көндә Уфа шәһәренең Республика клиник больницасында хирург. Зур врачмын. Кешеләр дәвалыйм. Бик күпләр аркамнан сөеп: «Рәхмәт, балам, бәхетле бул», – дип китәләр. Тик әни генә... әнине генә терелтеп булмый...

Булатның күкрәк читлеге тагын калтырап куйды. Озак елап өзлеккән бала кебек яңадан шыңшып алды.

– Сез ялгызмыни? – диде Динә, аптыраган карашын Булатка төбәп.

– Тормышымны төбеннән үзгәрткән марҗа кызы

Лиданы озак эзләсәм дә башка күрә алмадым мин. Әнисе үлгәч, күчеп китте, диделәр. Аның әнисендә үз әниемне тапкан кебек булсам, хатын буласы кешене дә нигәдер Лидага охшатып эзләдем. Олыгаеп кына өйләндем. Бер малаебыз бар. Ул да медик. Хатыным Света – маржа. Матур яшибез кебек. Әмма олыгая барган саен, үзеңнең тамырың, ата-бабаң, татар телең турында күп уйланасың икән ул. Күп вакыт рәхәтләнеп, авыз тутырып, үзебезчә, саф татарча итеп сөйләшеп утырасы килә. Малай, татар малае мин, дип йөрсә дә, үзебезчә бер сүз белми. Тик терсәкне тешләп булмый икән шул... – Бераз уйланып утыргач, Булат янә сөйләп китте: – Әни сезнең кебек ак кеше иде. Әллә кайсы ягыгыз белән мин сезне әнкәйгә охшаттым. Тавышы да сезнеке кебек тынычландыра торган, йомшак иде. – Булат тынып калды.

– Әниегезнең исеме ничек иде? – дип сорап куйды Динә, тынлыкны бозып.

– Раушания... Ә сез, Динә, җырлыйсызмы?

– Әнә үрне менгәч тә безнең авыл, – диде Динә, сүзне икенче якка борырга тырышып.

Булат аны ишетмәде дә бугай, машинаны юл читенә чыгарып туктап калды.

– Динә, сеңлем, беләсеңдер син ул көйне.

Раушаниям, бәгырем,
Күңелләрем сине юксына...

Җырла әле шул җырны? – Булатның күзләре очкын сибеп кабынып киттеләр. – Җырла инде, Динә. Дәү әни вафатыннан бирле ишеткәнем юк шушы җырны. Аны миңа ул җырлый торган иде.

Динәгә җырлау берни тормый анысы. Авылда аны «сәхнәдә туган» диләр. Тик менә чит-ят кешегә, җитмәсә, олы юлда? Шулай уйлады Динә, ләкин бу кешенең үтенечен җавапсыз калдырасы килмәде.

Диңгезнең дә була төрле чагы,
Бер давыллап ала, бер тына...

Хат-хәбәрең юк бу араларда,
Сәлам әйтми искән җилләр дә...

Челтер чишмә тавышларын хәтерләткән талгын моң кабина эченнән урамга чыгарга уңайсызланып торгандай итте дә, аннан, узгынчы машина тавышларына ияреп, зәңгәр киңлеккә таралды. Булат күзен дә алмый Динәгә карап торды. Аннан, әкрен генә машинадан төшеп, каядыр еракка китеп йөреп килде. Җыр тынгач, ике кулын күкрәгенә куеп, озак итеп Динә алдында башын иеп торды. Кинәт Динәнең кулларын, учларына алып, үбеп куйды. Тик бер сүз дә әйтмәде.

Руль артына утыргач та, байтак вакыт эндәшми барды ул. Бары тик авылга килеп кергәч кенә:

– Бу сезнең авылмы? – диде.

– Әйе.

– Динә, сез кайда эшлисез?

– Район газетасында. Буш вакытымда шигырьләр язам.

Булат нигәдер башын чайкап куйды да:

– Менә минем тарихны да тыңладыгыз. Бәлки, берәр шигырь дә килеп чыгар... Язсагыз, дим. Гомерем буе әни миңа рәнҗеп киткән кебек тоела. Дога кебек итеп күкрәк кесәмдә генә йөртер идем... Мин сезне кайдан таба алам соң, Динә?

– Мин редакциядә инде.

Машина туктагач, Динә рәхмәт әйтеп акча сузды.

– Сез нәрсә! Үзегезгә рәхмәт. Мең рәхмәт сезгә, Динә. Мин сезгә киләм әле!

Кузгалгач та, «рәх-мәт» дигән кебек озын итеп сигнал биреп китте Булат. Динә, юлны аркылы чыгып, машина киткән якка карап елмаеп куйды. Әкрен генә авылны чыгып барган машинаның ачык ишегеннән Булат аңа кул болгый иде. Динәгә нишләптер моңсу булып китте.

...Сагынышканнар. Озак итеп чәй эчтеләр, сөйләшеп утырдылар. Әтисе белән әнисенең урталарына утырып мәче баласыдай назланды Динә. Мәчеткә дип чыгып киткән әтисе артыннан карап сызланып куйды. «Картайдыгыз инде, кадерлеләрем минем!» Әнисе дә гел сыгылып төшкән кебек. Әллә инде кызларының еракта булуы да үзәкләрен өзәме? Эшкә барганда да, кайтканда да керeп хәлләрен белеп тора иде бит ул аларның...

Тамыры белән җиргә ябышып яткан әтисен кузгатып буламыни? Кунакка күрше авылга барсалар да, төнлә кайтырга өйрәнгән ич алар. Балаларын да, ерак җибәрмичә, яннарына җыеп урнаштырдылар. Шуңа да Динәнең китүен авыр кичерде өлкәннәр. Арткы урамнан Динә йөри торган бакча капкасын томалаганда, әтисенең күз яшьләре бер дә юкка атылып чыкмагандыр. Әнисе дә:

– И кызым, төнлә килеп ишек шакыган кебек буласың, – ди.

Сагыналар, димәк... Нарасыйлары бит.

Төне буе йоклый алмады Динә. Әтисе белән әнисен бер кызганды, яңа танышы Булат та күз алдыннан китмәде.

Иртәнге чәй янында төнлә утырып язган өр-яңа шигырен укыды.

**Әниемә**

Яшьли ятим калдым әниемнән,
Язмыш йөртте төрле якларда.
Тик нигә соң һаман
Әйләнәм дә кайтам
Яшь чагыма, бала чакларга?

Онытыламыни карашлары,
Елмаюы юлдаш һәр чатта.
Кичер, әнкәй, сабый идем әле,
Саклый алмадым шул ул чакта.

Сырхау алып китте сине миннән,
Аямады, жәлләмәде дә.
Тик шуннан соң, әнкәй,
Язмышым җилләре
Табиб итте мине мәңгегә.

Күпләр килә «Рәхмәт, балам» диеп,
Сөеп-сыйпый алар иңемнән.
Кичер, сиңа ярдәм италмадым,
Күз яшьләрем ага битемнән.

Әнкәй, бәгърем, өзелеп сагынам сине,
Җылы кочагыңны сагынам.
Гомер күзем җитте,
Бабай булдым инде,
Тик һаман да сиңа табынам.

Яшь чагыма, әнкәйле чагыма,
Әйләнәм дә кайтам яңадан.
Әнкәй белән рәхәт, нигә язмыш
Аера икән газиз анадан?

...Шигырь язылып беткән көннән бирле көтте Динә. Тик, килермен дип киткән Булат кына күренмәде. Беренче вакытларда, ишек ачылса да, редакция коридорыннан чит кеше килгәнен күрсә дә, ул түгел микән дип уйлап куя иде. Шушы шигырьне үзенең иясенә тапшырырга теләүме, әллә инде берәр татлы, дәртле хисме, үзендә ниндидер бер аңлашылмаган җаваплылык тоепмы, аны көтте Динә.

...Тик бу дөнья берәүгә дә мәңгелек түгел шул... Вакыт уза... Кешеләр сәламәтлеге сагында торучы ул табиб, бәлкем, үзе ярдәмгә мохтаҗдыр?..

Кайда соң син? Киләм дигән идең...

Чираттагы командировка озакка сузылды. Хезмәттәшләрен дә сагынырга өлгерде Динә. Әллә нигә иртәдән күңеле тыныч түгел. Каядыр ашкындыра, дәртләндерә торган ят бер хис күңелен кытыклый...

Эшкә йөгерә-атлый килеп кергән Динәгә карап, кызлар «тамаша» көттеләр. Ә үз чиратында Динә дә алар-

га аптыраулы караш ташлады. Өстәлендәге бер кочак ак розаларны күреп шаккатып торды.

«Ничек? Кайдан? Әллә соң аның өстәлен алмаштырганнармы?»

Кызлар узышып-узышып сөйләделәр: ике елдан артык Төньяк Кавказда – сугыш эчендә булып кайткан икән ул. Өлкә газетасында чыккан шигырне дә укыган. Олы рәхмәтен әйтергә дип кергән табиб-хирург кызлар янында озак утырган. «Ир-атның сүзе – тимернең үзе» дигәндәй, килгән бит! Сүзендә торган.

Тик язмыш дигәнең шундый була күрәсең?.. Күрештермәде...

## *Каргыш*

Гөлзәрә йоклый алмады.

Күзен йомып йоклап китүе генә була, саташып уяна. Уянган саен, бу авыр төннең һәр минутын санашкан асылмалы телле сәгатькә карап ала – бишенче егерме минут.

Гөлзәрә, янында йоклап яткан ирен уятмас өчен, әкрен генә урыныннан кузгалыйм дигән иде, тегесе, уфылдап, икенче якка борылды.

«Йокламаган, ул да йокламаган?!»

Йокларсың, бар! Атнадан бирле үз эченә бикләнеп йөргән Нияз, ниһаять, чишелде бит бүген! Чишелүен чишелде, тик аннан икесенең берсенә дә җиңел булмады. Киресенчә, тагын да авыррак тойгыларга, тирән уйларга чумдырды бу төн ир белән хатынны.

...Быел гаилә корып бергә тора башлауларына ун ел тула. Тормышлары да бик матур башланды бит. Ак таш белән тышланган алты почмаклы агач өй, абзар тулы мал-туар. Каенанасы белән каенатасы да бик яраталар үзен. Балаларына да аһ итеп кенә тора-

лар. Мәчеткә биш вакыт намазга йөргән Сөләйман картның ак оекбашына кер кундырмый йөртүе үзе генә дә Гөлзәрәне авыл картларының теленә кертеп җибәрде.

«Ичмасам, уңдылар киленнән, ут чаткысы, билләһи! Оекбашны ак кершән кебек юа бит, ә?!», «Бар нәрсәгә өлгерә, иртән сыерын да сава, сөтен дә ыздабать итә», – дип мактап кына торалар үзен...

Бәнат карчык баштагы мәлләрдә килененнән бер дә сыер саудырмады. Ике чиләкне мөлдерәмә тутырып савып керә дә:

– Сорасалар, үзем савам, дип әйт, кызым. Аның ояты юк, – дип, сөт җыючы апа килгәч, чиләкләрне Гөлзәрәдән чыгарта. Ә үзе: – Йоклар вакытыгыз әле, балалар, йоклагыз! Менә мин сава алмый башласам, үзегез карарсыз, – дип кабатлый.

Тирә-күрше керсә дә, Бәнат карчык:

– Аллага шөкер! Әлхәмдү лилләһи шөкер! Ниязны өйләнә алмас инде, ялгыз калыр дип бик борчыла идек. Утызга җитте бит! Шул баланы көтүе булгандыр. Үз кызыбыз кебек, бер күрүдә яраттык үзен. Картаймыш көнебезгә кайгырасы да юк, – дип мактанып ала иде...

Гөлзәрә каенанасының тел төбен аңлый, аның да үзенчә мактанасы, «Бәнат уңды киленнән!» дип әйттерәсе килә.

Шулай матур гына яшәделәр. Өч ел балалары булмыйча, яшьләр үзләре дә, картлар да пошаманга төшә башлаганда, беренче кызлары туды. Хәер, мәктәпне яңа гына тәмамлап, бу йортка килен булып төшкән Гөлзәрә үзе дә бала гына иде бит! Әнә быел зур кызлары мәктәпкә бара, кечкенәсенең теле ачылып килә. Малай алып кайтмаганына да ачуланмады Нияз:

– Борчылма, матурым, малаең мин булырмын, аның каравы кызларыбыз икәү, – дип юатты гына. Бер авыр сүз әйткәне булмады, кешедән дә әйттермәде.

…Барыбер йоклап булмасын аңлаган Гөлзәрә, торып, өс-башына киде. Берсе караватта, икенчесе коляскада яткан кызларының өсләренә япты. Юыну бүлмәсендә махсус куелган урындыкка утырып, чәчен тарап җыйды. Көзгегә караган иде, исе китте: аннан арыган, йончыган кыяфәтле бөтенләй чит хатын карап тора иде. Елаудан кысылып беткән күз кабаклары арасыннан сөзеп-сөзеп күпме караса да, Гөлзәрә аны танымады. Мондый хәлгә төшкәне юк иде аның.

– Әшһәдү әл ләә иләәһә илләллааһу… – Кечкенәдән, битен юа башлаганда, пышын-пышын, шушы, әбисеннән өйрәнгән доганы укый Гөлзәрә… Куллары, шешенеп беткән күз кабакларын сыпырганда, күңеле тагын шыңшып куйды: «Бер дә юкка бит, бинахакка!»

Башкаларны уятмас өчен аяк очларына гына басып, аш бүлмәсенә узды. Газ өстенә чиләк белән су куеп, җылытып алды. Аннан, әле бик иртә булса да, киенеп йортка чыкты.

Башка калдырган тана саудырмый азаплый, шуңа Нияз Гөлзәрә чыкканчы аның аякларын тышаулап, алдына чемченергә азык сала һәм: «Тик тор, Матуркай, хәзер бетә», – дип сөйләнгәләп, савып бетергәнне көтә, чиләкләрне алып куя торган иде. Ә бүген? Бүген уянып та карамады. Тормады, борылып кына ятты. Әйдә, дип әйтергә теле бармады Гөлзәрәнең, нахакка рәнҗетте бит! Булмаганны ишеттереп җанын кыйнады. Нигә, ни өчен?.. Хәзер нишләргә?..

Бер атна инде Ниязның Гөлзәрә белән авыз ачып бер сүз сөйләшкәне юк. Ачуланмый, сүгенми үзе, әмма ник бер сүз эндәшсен. Авызына су капкан кебек, бер ноктага карап, озак итеп уйланып утыра, балалар белән дә юньләп аралашмый. Эштән кайту белән ишегалдына чыгып китә дә маллар карый, машинасы тирәсендә әйләнә, өйгә генә кермәскә булсын! Ә бүген, бүген – чишелде…

– Менә, Матуркай, үзеңә тәмле ризык та салам, мин

саватмын, син чемченеп алырсың! – дип сөйләнгәләп, тана алдына камби* салды Гөлзәрә.

Мул итеп салды. Тана чиләкне этә-төртә тагаракка тыгылды. «О-о! Монда яларлык кына түгел, рәхәтләнеп авыз тутырып ашарга була!» дигән сыман, борынын тагарак төбенә җиткәнче тыгып, зур итеп кабып ашый башлады. Апасының болай сыйлаганына аптырап та китте бугай әле, яңадан ала күрмәсеннәр дигәндәй, үзе ашык-пошык ашый, ә күзләре белән ялт-йолт карангалап ала иде.

– Йә Раббым! Бер үзеңә тапшырдым, бир ярдәмнәреңне, – дип, Гөлзәрә белгән догаларын кабатлады. – Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!..

Тышаулый аламыни ул аны? Әнә алдына көрпә салганга гына тыныч кебек әле ул. Ә Ниязның:

– Яле! – дип, бер кычкыруы була, тана дерт итеп китә. Бәйләтә дә, кымшанмый саудыра да.

– Матуркаем! Апаң хәленә дә кер, тик кенә басып торчы, зинһар! Саудыр инде, бүген генә тик тор?! Өйрәнергә дә вакыт инде үзеңә! – Гөлзәрә шулай сөйләнә-сөйләнә, тышауламый-нитми генә, җылы су белән тананың җиленнәренә кагылды.

Ә тегесе ашавыннан капылт туктап, бер якка сөрлегеп китте. Арт аяклары янындагы бөтен мускуллары тартышып, бер мәлгә катып калдылар шикелле. Гөлзәрә утырган җиреннән яшен тизлегендә сикереп торды:

– Мин хәзер, бер минут, Матуркай. Ма-тур-кай соң инде! – дип, тананың сыртыннан сөйде.

«Яшь тана бигрәк тә кытыклана торган була, кызым! Саварга утыргач, сыер имчәгенә кинәт тотынма, әкрен генә, массаж ясый-ясый гына кагыл! Шулай иткәндә сөтен дә күп итеп бирә, кытыкланмый да ул», – ди иде аңа әнисе. И-и, үзләренең сыерлары бик акыллы иде шул. Ятып саусаң да кымшанмас иде.

---

* *Камби* – комбиазык.

Тана уфылдап, поши кебек колакларын торгызып, авыр сулап пошкырып куйды. Аннан, башын горур борып, арт аяклары янында йомгак кебек бөгәрләнеп утырган хуҗа хатынга бакты. Ә Гөлзәрә сөйләнә-сөйләнә башта бер, аннары ике кулы белән тананың кытыкланудан киерелгән, сөт белән тулышып ташып торган җиленнәренә кагылып массаж ясарга тотынды.

Юк, ашамый, капмый да! Тагаракны онытты тана. Гөлзәрәнең ни кыланганнарын шаккатып карап торуын дәвам итә. «Кара нинди тәвәккәл, бәйләми-нитми саумакчы бит бу» дигәндәй, хатыннан күзен дә алмый.

– Аша, хайван, аша! Авызыңны тутырып-тутырып ашап кал! Гел шулай мулдан эләкмәс, оныттыңмыни тагаракның чит-читләреннән тиз бетмәсен дип тәмләп кенә ялаганнарыңны? Әйдә тик кенә тор инде?!

Матуркай кинәт үзе янында ярты сәгатьләп маташкан хатынны жәлләдеме, әллә сөйләгәннәрен аңладымы, арт аякларын җайлап куйды да, теләсәң нишлә дигән кебек, буйсынган кыяфәттә башын тимер тагаракка тыгып, янәдән ашарга тотынды. «Кушт-кушт, кушт-кушт!»

– Матуркай! Менә ничек акыллы бит ул! Хәзер, хайванкаем!

Әкрен генә чиләккә беренче тамчылар тәгәрәште. Гөлзәрә, тананың зур-зур умырып ашавыннан файдаланып, арт аяклары янына чүгәләде. Куркуданмы, аякларының хәле бетте, тез буыннары калтыраргa тотындылар. Матуркай тышауланган булса, кечкенә утыргычка утырып, рәхәтләнеп савар иде дә соң. Монда һәр тартуың исәптә шул.

«Чиж-чиж, чужж-чужж!..» Абзар эче тып-тын. Аратирә янәшә бүлмәдә Иркәнең генә авыр сулап куйганы ишетелә. Аңа да тананың болай кылануы ошамый. Авызын ачып сөйли белсә, «Боргаланма, саудыр!» дип бер генә әйтер иде дә соң. Ул карт инде, ике елга бер игезәк бозаулар китерә иде, быелга кыш чыгарга гына калдырдылар. Аңа алмашка тананы әзерлиләр...

Гөлзәрә тартуын кызулата төште. Әллә тимер чиләккә моңсу тәгәрәшкән тамчылар тавышы, әллә инде азаплануының чиге җитеп, тананың күнүе шулай йомшарттымы, Гөлзәрә авыр сулап, шыңшып куйды. Төнге тавыш кабат исенә төшеп, тәнен чымырдатты.

«Карале! Гаепле түгел бит мин! Нигә болай нахак сүз белән талый, рәнҗетә соң ул мине? Чыгып та карамый, бәлки, тана типкәндер дип тә уйламый... Нигә миңа түгел, ә чит бер кешегә ышана ул?»

Гөлзәрәнең, һәр күзәнәген әчеттереп, янә күңеле тулды. Онытылып китеп, башын тананың сыртына терәде.

«Чижжу-чижжу! У-уу! Чиж-чиж! Жу-уу!..»

Моның хәтле моңлы тавыш, моның хәтле тынлык, тананың селкенми дә тын торуы... Гөлзәрә елый. Үзе елый, үзе сава. Эчендә булган бар үпкәсен шушы ак сөт тамчыларына кушып чиләккә тутыра ул. «У-у, ы-ы!.. Нигә?..»

...Төнлә булган сөйләшү вакытында каенана-каената ишетмәсен өчен, авызын мендәргә каплап шыңшып беткән иде. Монда ишетүче юк, рәхәтләнеп елады хатын...

– Әйт! Гаебем булса, әйт, яшермә! – дип, төнлә барысы да йоклап беткәч, сүзне үзе башлады Гөлзәрә. – Нигә болай эндәшми йөрисең? Күпме түзәргә була? Ни булды?

Ниязга шул гына кирәк иде:

– Әйтәм, тыңла алайса! – Ничек әкрен әйтергә теләсә дә, тавышы карлыгып, тамак төбеннән чыкты Нияз-ның. – Син аның белән ...! – Ир бераз дәшми торды да, тагын да ярсып: – Сөйрәлчек! Хатын-кызны елан диләр иде аны!.. – дип өстәп куйды.

Гөлзәрәнең тыны кысылды. Нинди ямьсез сүзләр ишетте ул. Ник? Ни өчен?

– Кем белән? Нәрсә сөйлисең? Эчтеңме соң әллә син, Нияз?

Нияз ярсый барды:

– Бик беләсең! «Мин аны озатып кына калмадым, миңа буласы иде!» дип, үз авызы белән әйтте. «Сезнең тормышыгыздан көнләшәм, минем бәхетем иде ул» диде. Нәрсә, исеңә төштеме? Ну?!

Ирен танымады Гөлзәрә. Аның күзләре зур итеп ачылган, нәрсә әйткәнен үзе дә аңламый, ул, нәфрәтләнеп, кычкырып, хатыны өстенә сугарга ыргыла иде.

Гөлзәрә, ике кулы белән битен тотып, ятакка ауды. Сукмады Нияз, әмма нахак сүздән дә катырак сугу бармы икән дөньяда? Тукта, кем соң ул? Нигә?

Хатын әкрен генә торып утырды. Түшәмгә карап уйга баткан Ниязның йөзенә текәлде. Аңа да бик авыр иде, ахрысы:

– Теге көнне синең белән кассага баргач, Рәдифне күрдеңме?

Гөлзәрә ни эшләргә белмәде:

– Ә? Ничек Рәдиф?! Ул бит, ул бит безнең күрше! Без аның белән бергә уйнап, бертуганнар кебек үстек.

– Вот-вот! Уйнагансыз!

– Син нәрсә, Нияз? Үз акылыңа кайт әле! Йә Раббым! Кулымнан да тотканы булмады. Мин сиңа мәктәпне яңа тәмамлаган килеш чыктым лабаса! Син... син мине беләсең бит! Ник юкка рәнҗетәсең?

Гөлзәрә тагын мендәренә капланды...

* * *

...Мәктәптә соңгы кыңгырау көне иде... Сыйныфташлар авыл читендәге аланлыкка чыктылар. Сызылып таң атып килә. Гөлзәрәнең аллы-гөлле күлмәге таң кызыллыгында аеруча матур күренә. Әйтерсең чыклы үлән өстенә чәчкәләр сипкәннәр...

Менә Рәдиф ак костюмын Гөлзәрәнең иңенә сала. Аның күз карашы... Гөлзәрә аннан читләшми дә. Ки-

чәдә дә гел икәү биеделәр, ун ел бергә укыган күрше егете абыйсы кебек якын...

Менә алар җитәкләшеп урамнан кайтып киләләр. Рәдифнең кулында Гөлзәрәнең аягын кырып, канатып бетергән биек үкчәле туфлиләре. Өй каршыларына җиткәч, инде саубуллашырга авызын ачкан Гөлзәрәне кулыннан алып, Рәдиф:

– Утырыйк әле бераз, Гөлзи! Көтү чыга башлагач керербез әле. Төн безнеке бүген, иртәгә көне буе йокласак та була. Башта – белем, кулда – букча дигәндәй, иртәгә китәм мин, – диде.

– Кая китәсең күрше кызыңны калдырып?

Кинәт уйламаган хәл булды. Рәдиф үзенә таба сораулы караш ташлаган кызны бер омтылу белән кочагына алды. Алды да:

– Күрше дә күрше! Ә мин сине яратып...

Сөйләп бетерә алмады Рәдиф, кызның тулышып пешкән ireннәре аңын томалаган иде, шашып Гөлзәрәне үбәргә тотынды. Көчкә ычкынды кыз:

– Җүләр мәллә син? Нишлисең?!

Гөлзәрәнең иңенә салган алсу шарф кына калды Рәдиф кулында. Көтелмәгән хәлдән аптырап калган кыз, ике кулы белән битен каплап, өенә йөгереп кереп китте...

Шуннан соң очрашмадылар. Капка келәсенә эленгән шарф эчендәге язудан, Рәдифнең иртән-иртүк Уфага, нефть институтына укырга китеп барганы беленде... Аны тәмамлап, озак кына Себер якларында эшләде ул. Яхшы гына мая туплап туган якка кайткан егет, күкрәк киереп: «Волга» алырлык акчам бар!» – дип мактанып та йөрде әле. Әмма ул акча, СССР таркалган арада, ике пачка чәй алырлык кына булып калды. Кызыл дипломлы белгечкә кайда да эш бетмәс дип, егет кайгырмады да. Әмма Себердән баеп кайткан елны башта әнисе, аннан әтисе бер-бер артлы дөнья куюлары кайгысыннан ул эчүгә сабышты. Ике атна эчендә чәче агарды,

дип сөйләделәр. ...Өйләнмәде, ялгыз яшәде Рәдиф. Беркая да эшләмәде, мал симертеп сатып көн күрде. Тик, ир хатынына яла ягу нигә кирәк булды икән Рәдифкә? Нигә кеше тормышын вата ул? Ни өчен? Ир белән хатын арасына кысылганчы, тимер арасына кысылсын иде...

...Мендәргә капланды да әрнеп, чын йөрәгеннән рәнҗеп елады Гөлзәрә. Нахак сүз ишетермен дип уйламаган иде. Керсез, саф килеш, яратып чыкты ул. Бүтән егетләр барын уйларга да өлгерә алмый калды, урлап китте аны Нияз.

– Ипидер, җир йотсын мине, әгәр яман эшем булса! – дип карганды Гөлзәрә. Иренең атна буе дәшми-сөйләшми йөрүе тәмам чыгырыннан чыгарган иде аны. Юктан чыккан тавышны ничек туктатырга белмәде. – Оныттыңмыни, саф килеш чыктым мин сиңа! Нигә болай газаплыйсың мине? Балалар борчыла, әниләр аптырашта. Күпме түзәргә мөмкин?.. Минем бер гаебем дә юк! Күз яшьләрем төшә аңа, менә бүген, менә хәзер үк төшә! Күрерсең!..

Төне буе елады Гөлзәрә...

Нияз да йокламады. Юкка рәнҗетүен белсә дә, колагыннан Рәдифнең әйткән сүзләре, күз алдыннан аның мыскыллы карашы китмәде. Очрашканда исәнләшүдән кала бер сүз сөйләшмәгән Рәдиф, Нияз янына килеп, үзе кул биреп сәламләште дә... бал кебек татлы тормышына бер олау дегет салып китте.

* * *

«Елап кына берни эшләп булмый. Минем абзарда елап утыруым кемгә хаҗәт? Нияз белән бүген үк Рәдиф янына барып кайтырга кирәк. Күземә карап әйтсен! – Гөлзәрә, үзен юатып, елавыннан туктады. – И-и, бу дөнья! Андый түгел иде ул, тормыш авырлыгы үзгәртә адәм баласын», – дип, күршесен җәлләп тә куйды.

– И Матуркай! Менә рәхмәт! Минем хәлне аңлавың булдымы соң бу? – дип, исән-имин савып бетерүенә сөенеп, тананың сыртыннан сыйпады Гөлзәрә, тулы чиләк сөтне алып куйганда. Иркәне күз ачып йомганчы сауды. Ул арада урамнан сыер мөгрәүләре, көтүчеләрнең чыбыркы шартлатулары ишетелде. Көтү китә!

Куып тормады, капканы ачып чыгарып кына җибәрде Гөлзәрә сыерларны.

– Ярар, үскәнем, үзем алып барам, иртәгә син куарсың, – дип, капка төбеннән үк алып китте аларны күрше апа.

Гөлзәрә ике чиләк сөтне, сөзеп, кар базына төшереп куйды. «Бүгенгә кеше күзенә күренеп йөрисем юк, каймак та беткән, көндез аертырмын әле», – дип уйлады. Ул, шулай сөйләнә-сөйләнә, абзар эчләрен чистартып алды, аннан, көрәк алып, арт бакчага чыгып китте. Өйдә тыныч булмагач, бәрәңге кайгысы да бетте, бакчага чыгарга уйлаучы да юк. Өяр вакыт җиткән ич! Бер кат чүп үләннәреннән арындыргач, ат белән генә тарта иде Нияз бәрәңге арасын. Ул да кайгыда...

«Ничек үзгәрде Нияз, атнадан артты бит! Болай яшәү мөмкин түгел, өстәл янына ашарга утырганда да урыны янәшә булмасын, балаларны да «вакыт юк» дип этеп кенә җибәрә. Тукта әле, хатынны юкка рәнҗетәм бит мин дип уйлап та карамый».

Көн кыздырырга охшап тора. Гөлзәрә, иртәнге чыктан буразна ярып, бәрәңге өя.

...Нияз хатынының чыгып киткәнен сизеп, тоеп ятса да, урыныннан торып йортка чыгарга ашыкмады. Ул да борчуда, бәгыренә каты бәрелделәр шул. Гөлзәрәне елатканына да йөрәге әрни, Рәдиф сүзләре дә кабат-кабат исенә төшеп җанын газаплый иде аның.

– Карале, нишләп һаман йоклап ята бу? Әллә тананы бәйләргә дә чыкмаган инде? – Йокы булмәсенең

ишеген ачып япты Бәнат карчык. – Әтисе! Әтисе, дим, тор әле! Намаздан соң ятмаска иде. Тавышланганнарын белдең, бар, йортка чык! Гөлзәрәне тана типкәндер инде?! Йә Раббым! Көтү дә әллә кайчан китте...

– Ничек, көтү китте? Ә тана? – Нияз ятагыннан сикереп торды, тәрәзәдән инде терсәк буе күтәрелгән кояш карап тора иде.

– Нәрсә син, малай актыгы, ник туганыңа үкенеп ятасың! Бар, әнә хатыныңны кара! Бөтен йортны әйләндем, беркая да юк. Бар, бар! Ятма монда урыс гробы кебек, – дип сөйләнүен дәвам итте Бәнат карчык.

Сөләйман карт, уфылдап, улының ятагы янына килеп утырды:

– Сыер типкәндер дип тә уйламыйсың, ә?! Нәрсә бар? Төн буе йоклатмадың. Нәрсә кирәк? Ул баланың эше әз дип уйлыйсыңмы? Синең күеңне күләп кенә торырга монда!

Инде ике бала атасы булса да, ата хакын хаклый белә Нияз. Сорау арты сорау яудырган әтисенә күтәрелеп тә карый алмады. Үз гаебен танып, эндәшми-нитми, мыштым гына киенде дә йортка чыгып китте.

Өйдәге тавыштан әле яхшылап үз хәленә дә килә алмаган Нияз капкадан кереп баручы Рәзинәне күреп алды:

– Нәрсә иртәләдең?

– Кит инде, Нияз, мин соңга калдым ди-ди чабам, ә син иртә дигән буласың. Әллә эшкә түгел?

– Ял ич!

– Кемгә ял, кемгә кабер әнә. Нияз, чакыр әле Гөлзәрәне, – Рәзинә тавышын әкренәйтә төште.

Арт капкадан Гөлзәрә кереп килә иде:

– Монда мин, машина туктагач, син икәнне белдем, исәнме, апа?

– Мин исән, Аллага шөкер! Авылда кайгы бит әле, Гөлзәрә. Төнлә урманнан кайтканда, күрше Рәдиф касимсут тракторы белән әйләнеп капланган. Үгезләренә

карда* тотам дип җенләнеп йөргән, ди. Киртәгә барган булган.

– Ну? – дип ашыктырды Нияз.

– Нәрсә «ну»? Шул! Дамбаны менгәндә ауган. Кешеләр килгәч тә тиз генә ала алмаганнар, кабинада кысылып яткан, ди. Бүген күмәләр.

– Әни?! – Гөлзәрә үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде, колагында, аңын томалап, бер-бер артлы аның «Тимер арасына кысылсын, кысылсын!..» дип, ире белән үзе арасына кергән Рәдифне каргаган сүзләре яңгырады.

Гөлзәрә, ике кулы белән башын тотып, ишегалдындагы эскәмиягә утырды. Аннан Ниязга карады. Аптыраудан авызы ачылган ир дә, ничек инде дигән кебек, Гөлзәрәгә карап тора иде.

## Болытлар артында кояш бар

Хәсрәт хәсрәткә охшамый,
Хәсрәт урыны бушамый...

*Халык җыры*

Кая ялгышты соң Зәрия? Кем каргышы төште дә кемне рәнҗеттеме икән ул? Килеп төпләнгән җире үз итмәдеме, әллә язмышына шулай язганмы? Әй язмыш, язмыш?!

...Мең төрле сорау катыш күңеле сыкрап елый Зәриянең. Автобус тәрәзәсеннән урамга баккан, инде елый-елый шешенеп беткән күзләреннән яшь ага да ага...

Баласы йөргән эзләрне, күрше малайларының һәр көн иртән шау-гөр килеп мәктәпкә баруларын күреп йөрәге әрнегәнгә бер тынычлык эзләп чыгып киткән иде бит ул бу шәһәргә!

* *Карда* – мал-туар яба торган махсус урын.

Ата-ана ризалыгын алмый эш эшләргә ярамаганга, сорамый-эзләми китмәде, сорады:

– Мин Чаллыга китәргә булдым, – диюенә әнисе дә каршы килмәде:

– Минем өчен борчылма, кызым, авылда адәм ялгыз булмый ул! Тирә-күрше бар! Эш табып урнаша алсаң, мин дә сөенер идем, – дип фатихасын бирде бит. Эше дә әйтерсең аны гына көткән! Ашханә хезмәткәрләре дә иптәшләрен чираттагы ялдан килгән кебек итеп, колач җәеп каршы алдылар. Ул яшәгән урамнан автобус йөри башлавын да, гомер булмаган тукталышның төп-төгәл ул торган йорт каршына куелуын да бәхеткә юраган иде Зәрия…

* * *

…Беренче көнне үк сменадан кайтканда, берәү:

– Сез дә шул якка бугай, – дип сүз башлап, өенә хәтле озата килде. Аның очравы ярады тагын, төнге шәһәр урамыннан берьялгызы ничек кайтыр иде. Ишек катында бераз сөйләшеп тә тордылар…

Күзләре кабат мөлдерәп тулды Зәриянең. Кулъяулыгы белән яшьләрен сөртеп алды да тирә-ягына каранды. «Шомланма, шомланганыңа юлыгырсың!» дип бер дә юкка әйтмиләр шул. «Миннән дә бәхетсезе юктыр», – дип уйлады ул, әкрен генә ишетелеп торган көй астында йоклап кайткан пассажирларга карап. Эче калтыранып, шыңшып куйды. Ничек онытасың ди аны. Кабат-кабат искә төшеп, җелекләрне сызлаткан хәлне.

…Берничә көннән, һич көтмәгәндә, аны эзләп, эшенә килде яңа танышы. Бу юлы Зәрия аңа ни өчен авылдан шәһәргә чыгып киткәнен, вакытлыча туганнан туган апаларында гына тукталуын, очсызрак фатир эзләвен сөйләде. Тын да алмый, бүлдерми дә тыңлады аны яңа танышы. Аннан шаярту катыш:

– Борчылма, сабыр иткән, морадына җиткән, – дип

куйды. – Ялгыз хатынга ярдәм итсәң, оҗмахка керерсең, диләр. Әле син мишәр дә бит! Миңа – двойной оҗмах! Во! Рәмзәт абыең берсүзсез сиңа булышырга тиеш!

Юл ерак шул, бөтен бер гомереңне барлап, һәр гамәлеңә бәя биреп була. Тик әнә шундый абынулар, егылулар булмасамы?.. Зәриянең уйлары янә буталдылар.

...Эштән бик соңарып кайтканга, аш бүлмәсенә узып тормады Зәрия. Аяк очларына гына басып, йокы бүлмәсенә узды да ятагына ауды. Яңа урынга әле үзе дә, күңеле дә урнашмаган бер мизгелдә, бу сөйләшүдән бераз бушанып, күңеленең кайсы почмагынадыр өмет җылысы өрелеп киттеме? Шул мизгелдә әллә нәрсә булды. Инде байтак кайгылар сыйдырган, сабыр итә-итә дә арып беткән башын ялгыз мендәргә түгел, көчле ир-ат иңнәренә куеп бер генә минутка онытыласы, бала сыман назланасы килде аның. Тик... күңеленнең тулып ташуы шул буладыр инде. Күрше бүлмәдәгеләр ишетмәсен дип, авызын мендәргә каплап, үксеп-үксеп елады...

Шул төндә күргән төшеннән таң алдында куркып уянып китте. Әнисе якында булса, юрап бирер иде... Ерак шул, йөгереп кенә кайтып булмый.

...Хәтфә җәйгәннәр диярсең, яшел болында Зәрия ялгызы. Күзләрне чагылдырырлык яктылык арасыннан улы, газизе, әнисенә таба килә. Юк, килми, оча... Кинәт туктала да кулларын алга сузып нидер әйтә кебек. Ә Зәрия:

– Улым, бәбкәм! – дип, аңа омтыла.

Шулчак улының үзәк өзгеч тавышы ишетелә:

– Әни! Әнием!!! Аннан кит, әни!.. Анда басма, әни-и-и!!!

Улының сузылган куллары, әнисенеке белән күрешә дә алмыйча, әллә кая югалалар...

– Улым, китмә, мине дә ал, улы-ы-м!.. Бәбкәм!!! Айнур!!!

Инде караса, өстендә бер киеме дә юк икән. Аягын-

дагы башмаклары җиргә ябышкан диярсең, күтәрә алмас дәрәҗәдә авырлар... Шыр ялангач Зәрия нишләргә, кайсы якка барырга икәнен белми интегә... Үзе бертуктаусыз: «Улым, балам!» – дип кычкыра. Анда сугыла, монда бәрелә... Баскан җире дә убыла түгелме соң? Ай-ай!.. Йә Раббым! Нәрсә бу? Ике куллап ябышкан агачы да ниндидер кешегә әверелә дә аны упкынга этә... Чү! Бу – ул бит! Рәмзәт! Әмма нигә аны, Зәрияне коткармый соң ул? Ямьсез күзләренең мыскыллы карашы, бар дөньяны яңгыратып «ха-ха-ха!» дип көлүе... Шулчак агач ботаклары шартлап сына...

Шушы куркыныч төш Зәриянең уеннан һич китмәде. Баласының аны кисәтүе булган бит ул! Зәрия шуны да аңламаган... Тик ана, йөрәк парәсе – баласының төшенә керүенә сөенде генә шул. Алып китмәде, үзенә чакырмады ич! Төштә мәет белән китү хәерлегә түгелен ишеткәне бар аның...

– Мин фатир сөйләштем, иртәгә үк барып карыйбыз. Син ризамы? – диде Рәмзәт чираттагы килүендә.

– Әй, бигрәк әйбәт булган, – дип, сөенеченнән кулларын чәбәкләде Зәрия. Кеше өсте – без өсте дигәндәй, апасы өендә озак юана алмас бит инде.

Рәмзәт бик ярдәмчел булып кыланды шул, никадәр сизгер булсаң да, аңлап булмас иде аның мәкерен. Ә Зәриянең җаны канаган чагы иде...

Кием-салым гына салынган булса да, йөк авыр иде. Шәһәрнең икенче башына хәтле ерак. Рәмзәт такси чакыртты. Җитмәсә, тугыз катлы йортның лифты да эшләми булып чыкты. Киң җилкәле, эре сөякле, озын буйлы бу ир-егеткә чемоданнар хатын-кызлар беләгенә кыстырып йөри торган бәләкәй ридикюльне генә хәтерләтеп калдылар. Җилтерәтеп алып менде генә түгел, аларны урнаштырырга да булышты егет.

Барлык уңайлыклары булган, затлы җиһазлы, хәтта телефоны да булган бу фатир бик ошады Зәриягә. Җитмәсә, гел түләүсез торачак икән ул. Чит илгә озак ва-

кытлы командировкага киткән хуҗалар, фатир бер карауючысыз тормасын дип кенә кеше кертергә булганнар.

– Минем танышлар алар. Эшләре шундый, китәләр, кайталар. Син – авыл кызы, чиста-пөхтә тотсаң, шул җитә, – дип өстәде Рәмзәт. Аның шушы кешелекле сыйфатлары, һәрдаим кайгыртып йөрүе якынайтты да бугай араларын. Кичке сменадан килеп ала, кайчакларда куна кала. Баштагы мәлләрдә Зәрия:

– Йә Раббым! Әллә соң елаганнарымны ишеттең дә, хәсрәтемне бүлешергә җибәрдеңме миңа бу бәндәңне? Кайгыдан каңгырмасын, дидеңме? – дип шөкер кылса да, ялгызы калган авыр көннәренең минут-сәгатьләрен, йөрәк парәсе – газиз улының исемен әйтә-әйтә елап илерде. «Бәхетле бала туган сәгатеннән бәхетле була» димәсләр иде аны...

Балачагын искә төшергәндә дә күңеленә әллә ни җылылык йөгерми Зәриянең... Ул туган көнне авыл янындагы күлдән урман кискәндә бер аягын өздергән, инвалид таягы белән йөргән әтисенең суга капланып яткан үле гәүдәсен алып кайттылар. Балык тотарга дип киткән җиреннән ярдан егылган. Шулай итеп, кыз дөньяга килгән беренче көненнән әтисез үсте. Әтиле балаларга кызыгып та, алардан көнләшеп тә үтте аның балачак еллары. Алар белән дуслаша да алмады ул. Мәктәптән кайту белән өй эшләренә тотына, кичен әнисе белән бәйләм бәйли, чигү чигә... Абыйсы, сеңлесе дә булмады, ичмаса...

Буйга житкәч тә, бәхет кояшы болыт арасыннан бер күренеп алды да, аннан Зәриянең бар дөньясын тоташ караңгылыкка күмде. Тормышка чыгып кияү куенының җылысын татырга да өлгермәде, ялгыз калды. Нибары сигез ай яшәп калдылар. Җиңел машинада дүрт кеше гомере кинәт өзелде ул кичтә. Юан бүрәнә тартып, юл аркылы чыгып баручы тракторны күрми калганнар. Ә трактор руле артында аның Хәбире булган. Яңа өйләнешкәнсез дип тормадылар, әллә ничә

статья белән утырттылар Хәбирне. Бик еракка да алып киттеләр. Төмән тирәсенә. Өйдә ни бар, шуны алып, Зәрия свиданиегә баргалады. Һаман-һаман бара торган җир түгел шул, ерак, әнисенең пенсиясе юлга да җитми. Аннары үзенең барлыгын күптән сиздергән бала белән ничек юлда йөрисең. Зәрия үзе дә коры сөяккә калды, врачлар токсикоз диделәр. Бала тугач, мөмкинлек булса да, ниятләп юлга чыга алмады. Хатларын укыганда да борчылып, елап бетә иде. Көнләшеп җанына тиде Хәбир. «Кем ул? Ястыгыңны кем белән бүлешәсең? Кайтыйм гына!..» кебек юллар аның йөрәген телем-телем кискәләде.

Алай тәртипсез кебек түгел иде дә аның ире. Әйтерсең алмаштырып куйдылар. Язмышы кинәт башка якка борылды шул... Ә хәзер барыйм дисәң дә барыр җирдә түгел. Дөньяда юклыгына да ун ел була. Баласын да күрә алмады, гәүдәсе дә чит җирдә калды.

Каенанасы һәрдаим хәл-әхвәл белешеп, булышып яшәде. Еш килә, кечкенә Айнурны сөя-сөя күз яшьләренә тыгылып кайтып китә иде. Ялгыз үстергән бердәнбер баласы хәсрәтеннән чиргә сабышып, ул да вакытсыз вафат булды.

Ялгызына бала тәрбияләү, башта бакчага, аннан мәктәпкә әзерләү, авыру әнисенең барлы-юклы пенсиясенә яшәү авырлыгыннан тәмам сыгылып төшәр иде Зәрия. Бетеп бара торган авылның ни эше, ни ашы дигәндәй, әнисе белән исәпләп киңәштеләр дә район үзәгеннән ерак түгел бер авылга кайтып төпләнделәр. Шөкер, бу авылда юрганына күрә аягын сузып яшәргә мөмкинлек таба алдылар. Кулына тоткан пешекче дипломы белән ашханәгә чакырсалар да, бара алмады. Авыру әнисенә баланы озын-озакка калдыра алмаганга, үзләре яшәгән йорт янәшәсендә урнашкан азык-төлек кибетенең идәнен юды...

* * *

Айнур төскә-биткә матур, дүрт ягы сәламәт булып туды. Мәктәптә уку алдынгысы булды, гел «биш»кә укыды. Ата-аналар җыелышларына баргач, ничек горурланып кайта иде Зәрия. Йорт-тирә эшләрендә дә бик теләп булышты малай. Буш вакыты булды исә, йөгерә-йөгерә машина-трактор паркына төшәргә ярата иде. Авылның ир-ат заты белән кул биреп исәнләшә, тегеләре дә:

– Нихәл, брат! – дип,ерактан елмаеп килерләр иде. Улының әтием юк дип кимсенгәнен, көйсезләнеп утырганын Зәрия хәтерләми дә. Киресенчә:

– Безгә болай да рәхәт, әйеме, әнием?! – дип юаткан чаклары күп иде балакайның. Туган сәгатеннән әтисез үскәнгә шулай сабыр булдымы, әллә үзен ир-ат, гаилә башлыгы, әби-әнисенә терәк итеп тойдымы, сер бирмәс, зарланмас бала булып үсте. Үртәлгән, кыйналган чаклары да булгандыр, кайтып әләкләп йөрмәде...

«И-и, балам, балакаем, Айнурым!.. Никләргә генә, кемнәргә генә калдырып киттең мине? Балакаем, бәгырькәем минем!» Зәрия тагын үксеп куйды, тавышы чыкмасын өчен, кулъяулыгы белән борынын тотты. Яше ага да ага. Автобус авылга якынлашкан саен үкси төште. Яклаучы, назлаучы, авыр чакта: «Сабыр ит, балам!» – дип юатучы әнисе янына кайту аз гына булса да юата, шуңа күңеле йомшарып тыелалмый елый ул. Тагын кеме бар соң аның?

Тик шушы талгын көй онытылырга мөмкинлек бирмәде, уй артыннан уйга чумдырды гына...

* * *

...Тормышлары көйләнгән иде. Үзе эшләп йөри, әнисе соңгы вакытларда гел авырмый башлады, Айнуры да көн дә алга бара. Ундүрт яшен тутырып кулына

паспорт алгач, үсеп, җитдиләнеп китте. Чиләк-көянтә асып, чишмәгә суга барсынмы, йорт-кура эшләрен әйтергә дә юк, барысына өлгер, әнисенә ярдәмчел булды. Мәктәпне бетергәч, институтка барырга хыялланды...

Авылга бер төркем эшче көчләр, ирләр килгәч башланды хәлләр. Алар совхозда төзелеш эшләре белән мәшгуль иде. Исенә төшерәсе киләме соң Зәриянең ул көннәрне?! Ялгыз ирләр «ишсез» хатыннарны тиз таптылар. Төрле сәбәпләр белән, кая эш, кая аш-су янына җыелышып аралашулар күбесен «парлаштырып» та куйды. Вакытлыча, билгеле.

Зәрия дә Әслах белән кибет идәнен юганда танышты. Ипигә кергән саен, хатынга шоколад бүләк итте ул. Аннан малаен ияләштерде. Зәрияләр торган ике катлы йортның күршесендә генә яшәгәнлектән, кич утырырга кергәләде. Аннан бөтенләй торырга күчте. Төскәбиткә әллә-ни чибәр булмаса да, аракы белән мавыкмавы, кулының да бар эшкә ятып торуы ошадымы, әнисе дә риза булды. Гаиләсе юк, әти-әнисе вафат икән. Ягымлы булды, бер әчмуха чәен, күчтәнәчен онытмады.

Бөтенләй үзенә күндереп бетергәч, инде гаилә башлыгы сыман канатланып-очынып йөри башлады. Айнурга кычкыргалауларын да тәрбия йөзеннән дип аңлап эндәшми калдылар. Тик Зәрия дә, әнисе дә ир салган ятьмәгә эләккәннәр иде инде. Эчми торган ир, башта кәеф өчен, соңрак һәр көнне яхшы гына салгалап кайта башлады. Акча таптырып йөдәтте, кулын уйнатырга да тайчынмады. Чын-чынлап өмет өзелсә дә, куып чыгара алмадылар, курыктылар... Миһербансыз бу бәндәнең хатынын үтереп төрмәдә утырып кайтканын да бик соңга калып ишеттеләр шул...

Айнур, әнисе белән ялгызы калганда:

– Ялгыштык, әни, әйеме? – дисә дә, җавап көтми, чөнки әнисенең күзләрендә урнашкан моңнан барысын да аңлый иде. Соңгы төндә дә шулай булды. Иртән, Әслах эшкә дип чыгып китү белән:

– Әни, мин барысын да ишетеп, күреп торам, әби дә борчылып елый. Син дә куркып кына ризалашып торасың. Куып җибәр син аны, кирәкми бит ул безгә! Минем өйгә дә кайтасым килми башлады инде, – дип өзгәләнде.

– И-и, улым! Үз башыбызга булды, балам! Куып кына чыгарыр идем, куркам мин аннан, «барыгызны да үтереп китәм» ди бит!

– Алайса, үзем сөйләшәм...

Иртән шулай дип чыгып китте һәм беренче тапкыр өйдә кунмады Айнур. Сыйныфташлары аның бүген мәктәптә дә булмавын әйткәч, йөрәге жу итеп китте Зәриянең. Шушы яшенә чаклы күршегә дә кунарга кермәгән малай, саламга төшкән энә кебек юк булды... Төне буе каян эзләргә белмәделәр. Әслах та эзләште.

– Кайтыр, күрше авылга киткәндер. Иртәгә кайтыр, – дип юаткан булды. Берни булмагандай тыныч иде ул бу көнне. Айнык та иде.

Малай икенче көнне дә табылмады. Авылның аягында йөри алган яше дә, карты да эзләде Айнурны. Мәктәптә укулар булмады. Укытучылар, укучылар елга буйларын, бакча артларын айкап бетерделәр. Бу эшкә район милиционерлары да тартылды. Айнур гына табылмады.

Малай югалган көнне иртән Айнурның Әслах белән машина-трактор паркы ягына таба китүен күрүчеләр булган. Шуны белеп алып, үги атаны допроска алып киттеләр...

Малай югалганның өченче көнендә авылның участок милиционеры, авыл читендәге чытырманлыклар арасында янган чирәмне, яңа казылган җирне, аннан чыгып торган кеше кулын күреп, өнсез калган...

* * *

Хәл болай булган. Иртән мәктәпкә барырга дип чыккан Айнурны Әслах ишегалдында көтеп торган.

– Син, маңка малай, нигә минем белән сөйләшмисең?! – дип кычкырган ул.

– Әйдә соң, кайда сөйләшәбез, – дигән Айнур.

Алар, икәүләшеп, авыл читенә таба киткәннәр...

Шунда Әслах Айнурны мәктәп сумкасының бавы белән буып үтергән. Аннан күмеп куйган. Кичен шул урынга килеп, солярка түгеп, ут төртеп киткән. Авыл өстенә таралган исне сизеп, клубка чыккан яшьләр «О-о, кемнәрдер шашлык пешерә» дип уйлаганнар...

Зәрия малаен ярым тере, ярым үле килеш соңгы юлга озатты. Фельдшер кыз янының китмәде. Баласының күмергә әйләнгән гәүдәсен җыеп җирләгәндә, көл салынган шушы кечкенә кәгазь тартмага хәсрәттән көйгән ананың урталай ярылган йөрәге дә кереп посты.

– Балам башына булды. Улы-ы-м, бәгырем башына булды... – дип сыкранды ул.

Кечкенә татар авылында булган бу коточкыч вакыйга бөтен республикага таралды...

...Айнур югалган көнне өйдә кунды Әслах. Шушы куллары белән тотып ипи ашады, Зәриянең йомшак ятагында бер хәсрәтсез ятып йоклады... Суд карарын укыганда, керфеге дә селкенмәде хәтта.

Аннан соңгы көннәрен яшәмәде дә кебек Зәрия. Аның көн дә зиратка баруын күргән авыл картлары:

– Алай йөрү кирәкмәс, кызым! Мәңгелектән берәү дә кире кайтмый, үлгән артыннан үлеп тә булмый! Гомере кыска булгандыр. Тынычланырга тырыш, догалар укы! Синең әле яшисең, әниең турында кайгыртасың бар, син дә аның бердәнбере, – дип үгетләделәр.

Бөтен өмете, киләчәге иде бит ул Зәриянең! Бердәнбере, иң кадерлесе иде...

Әнисе өчен ул да бер генә дә бит, әмма Зәрия аны аңлый алырлык хәлдә түгел шул. Баласының каберенә барып, сөйли-сөйли елап кайтса гына тынычлангандай, газизен күргәндәй була...

Һаман шулай йөрер иде, яшәүне дәвам итәргә кирәген аңлапмы, әллә туганнан туган апасының кабат-кабат үз янына чакыруына җитди карапмы, Чаллыга китте...

* * *

Инде менә кайтып бара...

Өч ай, бары тик өч ай! Барысы да әйбәт иде. Аерым фатир да ошады Зәриягә. Ике көнгә бер сменага бара, буш көннәрендә оек-бияләйләр бәйләп сата. Тирә-күрше кибет-повильоннардагы сатучыларны балтырлы оеклар бәйләп кинәндерде. Юлда туктатып сорыйлар хәтта. Юк-бар товар алырга гомумән гадәтләнмәгән Зәрия, акча сарыф итеп йөрмәде. Киресенчә, җыя барды. Беренче эш хакын алгач, сөенечтән елады. Андый акча күргәне бар идемени аның? Җиде мең сум! Хезмәттәшләренең:

– Юабыз, беренче хезмәт хакын юабыз! – дигәннәренә дә:

– Юарбыз, кызлар, урнашып бетим инде, – дип кенә куйды. Бер сменасын сөйләште дә әнисе янына кайтып килде. Әниле-кызлы сөенешеп елаштылар. Яңа танышы турында әйтеп әнисен борчымады. Төшен дә сөйләмәде.

– И-и, әни, бар да әйбәт, менә үзеңне кунакка алып барырмын, күрерсең, – дип сөендерде генә.

Яңа ел бәйрәменә кайтырмын, дип китсә дә, тиз генә кайта алмады. Ашханәдә куна калып эшләргә туры килде. Эш күп булды, банкетлар, кичәләр дигәндәй...

* * *

Урыныннан иртәрәк кузгалган булып чыкты Зәрия. Күрше авылга туктаган автобус кешеләр төшергән җиреннән тиз генә кузгалып китә алмады. Шофер арт

ишек янында, ачкыч тартмаларын шалтыратып ачып, нидер эшли башлады…

Аннан соң булган вакыйганы уйлыйсы да килми Зәриянең…

– Әйдә, иске яңа елда бергә утырыйк, – дип килде Рәмзәт. Унөченче гыйнвар көн иде ул. – Мин сине үзебезгә чакырам, син ризамы?

Шунда ризалашмаган булса соң? Нәрсәдер сизенеп, теләр-теләмәс кенә барды Зәрия.

Рәмзәт авыру әнисе белән генә тора икән. Үзе заводта эшли. Әнисе авыргач, хатыны ташлап киткән. Балалары булмаган икән. Шуннан артыгын белә алмады Зәрия. Рәмзәт тә бик ачылып китмәде. Урын өстеннән тора алмаган әнисен ашатканнан соң, шәм яктысында икәү генә иске яңа елны каршы алдылар. Рәмзәтнең шампан шәрабы да эчмәве ошады, чөнки Зәрия исерек ирдән тәмам гарык иде. Тик вакыт-вакыт кәрәзле телефоннан яшерен сөйләшүе генә сәер тоелды. Телефон төнлә дә, таң алдыннан да йокыны бүлде…

Икенче көнне кич белән генә Рәмзәт Зәрияне озатып куйды. Тик үзе машинадан төшеп тормады:

– Ашыгам, матурым! Кичкә килермен! – диде.

Зәрия фатир ишеген ачып керү белән егылып китә язды. Өй эчендәге барлык затлы әйбер юкка чыккан иде. Бәллүр люстраларга кадәр алганнар. Шалтыратыйм дисә дә, аптырап калды. Ишек янындагы тумбочка өстеннән көмеш кыңгыраулы телефон да юкка чыккан иде. Аптыраудан йөзе агарган Зәрия нишләргә белмәде. Рәмзәтнең үзе генә килгәненә күнеккән иде ул. Аның телефонын да, кая торганын да белмәвенә менә хәзер генә исе китте. Кайсы районга, нинди өйгә барганнарын да хәтерләми, гомумән, Чаллыны белми икән ул. Апасына шалтыратырга читенсенде. «Бездә генә тор» дигән сүзләренә каршы килеп чыгып киткән иде бит!

Рәмзәттән башка милициягә шалтыратырга да батырчылык итмәде. «Бәлки, хуҗалар үзләре кайткан-

дыр, ишекләрне каермаганнар ич. Ачып кергәннәр. Иртәгә эшкә баргач та шалтыратыр Рәмзәт. Шунда барысын да әйтермен», – дип үзен юатып, дүшәмбене көтте.

Әмма шалтыратучы булмады. Көне буе ут йотып йөрде Зәрия, эше – эш, ашы аш булмады. Сменадан кайткан төндә генә килде Рәмзәт. Килде дә, бу хәлне күреп, акырырга тотынды:

– Ачкычыңны кемгә бирдең? Үзең җавап бирерсең! Мин сине җәлләп керткән идем. Югалма, җир читеннән табам! Менә адрес, менә телефон, акча җыеп биргән бул! – дип җикеренеп китеп барды.

Эштәге иптәшләре бер телефон биреп җибәргәннәр иде. Аннан хәзер һәр көн диярлек Рәмзәтнең ачулы-янаулы тавышы акча сорап кисәтеп тора. 100 мең сум!

– Теләсәң ничек тап! Анда минем эшем юк! Счетка куям!.. – дип кычкыра ул.

Шушы сүзләр, шушы янаулар гына хәзер Зәриянең колагында. Бөтен өмете челпәрәмә килде аның. Әнисен дә үзе янына алып килергә дигән уе бар иде бит аның...

* * *

Автобус, ниһаять, кузгалып китте...

«И, китмәгән генә булсамчы?! Нинди хәсрәтләр алып кайтам бит!..»

Ике сменасын хезмәттәше белән алмашып, авылга кайтып бара Зәрия. Нишләргә? Акча сорарлык беркеме юк! Озак кайта алмам, ике смена, өч смена эшләрмен! Әмма әнигә белгертергә ярамый! Йөрәге күтәрә алamы-ни бу хәлне? Газиз әнисен күрергә генә кайта ул...

Бик күп кайгыларга түздең,
Түзәрсең йөрәккәем...

Зәриянең күзеннән яшь кипмәде...

* * *

Әнисе өйдә юк иде.

«Аягым авырта дип тормый, каядыр чыгып киткән» дип уйлады Зәрия. Идәннәрне юып, өйне җыештырып бетергәч, чәй куеп җибәрде. Өй эшләре белән онытылып китеп, әнисе кайтып кергәнне сизми дә калды.

– Кызым кайткан икән! Ә мин аңа шалтыратырга дип күршеләргә кергән идем. Өйдә дә чисталык! Кай арада өлгердең, балакаем? Идәннәремне дә юып куйгансың. «Ялкау таягы» белән өйне әллә ни матур тотып булмый шул. Астан-өстән генә юам инде. Рәхмәт, кызым!

– И-и, әни! Минем кайтканга ике сәгатьләп бар инде.

– Озак утырылды шул. Әдилә апаңның Үзбәкстанда яшәүче сеңлесенең малае кайткан. «Үзем белән татар кызы алып китәм» дип әйтә, ди.

Зәрия әйтерсең берни ишетмәде:

– Әйдә әле, әни, күчтәнәчләр белән чәй эчик...

Табын артында әнисе Зәриягә авыл хәлләрен, «соңгы хәбәрләр»не җиткерде. Күршегә кайткан «кияү» турында да кабат кайтып:

– Ташкентның үзеннән кайткан. Ул матурлыгы, акыллылыгы бит әле. Дәүләт җитәкчесе янында тәрҗемәче булып эшли икән, чит илләргә чыгып йөри, ди. Утыз өч яшьтә...

Тыңлады да, тыңламады да Зәрия күрше егете хакындагы мәгълүматларны. Аның эче тулы хәсрәт һәм шуны ничек тә әнисенә сиздермәскә, аны борчуга салмаска тырыша ул. Тик ни эшләсә дә, ничек кенә онытылырга талпынса да, күңел түрендәге шушы борчу һаман саен исенә төшеп йөрәген чәнчи иде...

...Көянтә-чиләкләр алып, суга дип чыккан Зәрия күршегә кайткан кунак белән ишек төбендә очрашты. Көтмәгәндә каршына килеп чыккан хатынга баштанаяк күз салып өлгергән егет:

– Бәлки, бу чибәргә булышырга кирәктер? – дип, саф татарча сүз катты.

– Кирәкмәстер! – Кырт кисте Зәрия. Дөресрәге, ул аны күрмәде дә. Чиләкләрен шалтырата-шалтырата көянтәсенә элеп, горур атлап китеп барды.

Суга киткән бу сылуның кем икәнен белер өчен, Икрам йөгерә-атлый апасы янына керде.

– Апа, син тәрәзәдән кара әле, кем кызы микән бу сылу?

– Төшкә хәтле ике сәгатьләп бездә кызлар сайлашып утырган күрше Хәтирә апа кызы бит бу, Зәрия! Кайчан кайтты икән? Теге бала турында сөйләдем бит инде мин сиңа. Шуның әнисе ул. И-и, язмыш! Әй бу язмыш! Бер дип тормый, син хәсрәтле дип тормый шул, әллә нинди кайгыларга сала адәм баласын. Киткәненә ике айлап бар микән? Чаллыда ул хәзер, шунда яши. Безнең авылга да күчеп кенә килделәр алар.

– Ә ире?

– Ире дә үлде. «Бер бәхетсез – гел бәхетсез» димәсләр иде...

* * *

...Ике генә күрештеләр алар. Берсе суга барганда, икенчесе судан кайткач...

Читтән кайткан кунак бик әрсез булып чыкты. Тотты да өзде, әйтте дә бетте! Йоласына туры китереп никах укыттылар. Ике күрше арасында ишекләр ябылып тормады. Күчтәнәчләр тотып озатырга килүче дә күп булды. Зәриягә чын күңелдән бәхет теләде авыл халкы.

– Бәхетле бул, бала!

– Бәхет телим, кызым!..

...Чаллы аша киттеләр.

– Килеп, әниеңне борчып йөрмәсен, акчаны кертә китик, – диде Икрам.

Зәрия яшәгән фатирга килеп кергәч, аларның исләре китте. Кайдандыр хатынның кияүгә чыкканын, Үзбәкстан ягына китәргә җыенуын ишеткән Рәмзәт, аны бүтән килмәс дип уйлаганмы, фатирга ике яшь кыз керткән. Яңа ел төнендә аны мең хәсрәткә салып юкка чыккан бар әйбернең дә үз урынында булуына гаҗәпкә калды Зәрия. Монда Рәмзәт кулы уйнаганы аңлашылды. Көмеш кыңгыраулы телефон да, бәллүр люстралар да Зәриянең аптыраган йөзенә «тынычлан» дигән сыман елмаеп карап калдылар...

* * *

...Инде менә поезд тәрәзәсеннән күренеп барган ерак офыкка карап уйланып бара Зәрия. Туган ягы, әнисе, улы Айнур белән арасы ерагая шул! Әнә поезд кечкенә авыллар аша уза. «Пу-пу-у! Пу-у!..» Йөгереп кенә кайтыр җир түгел. Сагынылыр, сагыныр инде... Кабат үткәннәре күз алдына килде, ләкин Зәрия еламый. Аның хәзер таяныр терәге, ышанычлы юлдашы бар. Бар икән бит, бар икән болытлар артында кояш!

* * *

Йә Раббым! Бир бәхет, бир шатлык бу бәндәңә!

Әнисен сагынудан, ире Икрам белән башлаган бәхетле тормыштан атылып чыккан күз яшьләре шатлык яшьләре булып кына тамсыннар иде! Әнә нинди бәхетле ич алар! Кечкенә сабыйдай изрәп йоклаган иренең иңнәренә башын куеп, яңа тормышка зур өметләр баглап, ерак тарафларга китеп барышы бит бер баланың...

## *«Художник»*

Кызы алып кайткан рәсемне бик ошаткан булып кыланды Гасимә. Беренчедән, яңа күчкән фатирларына җиһазның гел яңасын гына алырга ният кылдылар. Әлегә әкренләп булса да җыела үзе, менә монысы да нәкъ кирәк урынга туры килде дә куйды. Икенчедән, кызына ошагач, булган инде. Яшь кеше заманча уйлый бит ул!

Җитмәсә, сатучысы да ни җиткән «простой» түгел, «лечить» итә икән шул рәсемнәре белән. Имеш, рәсемне өйгә кайтарып элеп куясың да, бөтен авыруларың юып алган кебек бетәләр дә китәләр, ди! Әле кешенең киләчәгенә дә бик нык йогынты ясый икән! Кызы Зәринә рәсем сайлап торганда, берәү килгән дә, менә монысы гел сезнең эзләгәнегез инде, дип ышандырган. Унҗиде ел шәһәр прокуратурасында эшләгән Зәринә алдатмас! И, аның хәзер заманасы да әллә нишләде. Адым саен «экыстрасинс». «Космыс» белән дә элемтәдә торалар икән, дип тә өстиләр әле...

Рәсем матур, әйтеп торасы да юк! Зәңгәрсу эскәтер япкан өстәл өстенә әйтерсең җәйге алан үзе килеп төшкән!.. Кыңгырау чәчәкләре, ромашкалар!.. Күзнең явын алып торалар. Карасаң, күңелләр күтәрелеп, бар мәшәкатең онытылып китә. Ирексездән, хыял канатларына утырып, авылга, хуш исле чәчкәле болынга кайтып төшәсең...

Төшүен төшәсең, әмма ромашкалары әзрәк түгелме соң моның? Берле-сарлы, анда-санда бер чәчәк тора инде. Шуның хәтле кыйммәтле булгач, күзгә күренеп торырлык чәчкәләре дә булсын инде аның. Кызына әйбер-кара әйтмәде әйтүен, тик әнә шулай уйлый-уйлый, ул өйдә юк чагында буяулар алып, «олы эшкә» кереште Гасимә. Кулындагы пумаласы уйнап кына торды. Уйнамаска, бер дә юкка «художник» дигән кушамат такмадылар ич аңа! Район мәктәпләрендә, авыл

музеенда, хәтта терлекчеләр йортында әле дә ул ясаган рәсемнәр саклана.

И, анысын сөйләп кенә бетерерлекме?

...Уйлары белән ерак яшьлегенә кайтып китте Гасимә.

Кечкенәдән рәсем ясарга яратты ул. Мәктәпне «гел яхшы»га тәмамлады. Укырга китәргә дә исәбе юк түгел иде. Тик әнисе, кызым, ялгызымны калдырма инде, дигәч, кузгалып китәргә базмады шул. Яңа гына әтисен җирләгәннәр иде, шундый авыр чакта ничек чыгып китәсең. Авыл идарәсенә сәркәтип кирәк чак, бер елга дип кенә кергән иде, аннан калды да калды. Гомере буе мәктәбенә, клубына, кая кирәк шунда плакат, стенд, тагын әллә ниләр ясады. Әйе, аңа киләләр иде...

...Кылны кырыкка ярырлык чак – урак өсте! Урыпҗыясы гына да бит булган уңышны! Юк! Авыл тулы яше-карты – исерек. Идарә рәисенең йоклаганы да юк. Кайсын өеннән, кайсын айнытып, кайсын каян табып дигәндәй, төш җиткәндә кырга озата. Яңгырлар тотынганчы дип сикерә-сикерә эшләргә иде... Кибеттә инде күптән аракы сатмыйлар, анысын күз уңында тота ала рәис. Тик менә боларны тыя алмый. Каян эчәләр, нәрсә эчәләр? Ут йота мескенкәй. Аптырагангадыр инде:

– Гасимәкәй, синең рәсемең бик урынлы булыр, яса әле берәр нәрсә. Бәлки, хурланып, эшкә тотынырлар, – дигән иде.

Ясады Гасимә, рәис ничек сөйләде, шулай ясады: бер кулында шешә, икенчесендә комбайн иттереп тә, шул «явызҗан» аракы белән җитәкләштереп тә ясады. Бер адәм мәхлугының, комбайн башына басып, чайкала-чайкала пес итеп торуын ничек калдырасың? Район вәкиле килгәнен дә күрмәгән бит! Күзе тонган! Ул гына түгел, патша үзе килсә дә күрми...

Иртәнге наряд вакытына элеп тә куйдылар. Баш авыртуыннан кая барып сугылырга белми, агу ашаган күселәр кебек алпан-тилпән килеп, ничек эшкә тоты-

нырга дип йөргән әлкәшләрнең рәсемне һәм анда үзләрен күреп чәчләре үрә торды. Кысылган күзләре ачылып кына калмады, пахмельдән йөз грамм салып бирделәрмени, айнып ук киттеләр...

– Бер минут үттеме-юкмы, трык-трык комбайннарын кабыздылар да кырга тайдылар, – дип, Гасимәгә сөенче җиткерделәр. Сөенченең көенече дә булды булуын:

– Теге кәкре сыйракның гына эше инде бу, художник, блин!.. – диделәр салмыш йөрүчеләр. Диюен диделәр, эчүләреннән дә туктадылар бит!.. Шуннан Гасимәгә ябышты да калды инде «художник» дигән нәре...

И Гасимә, ул көннәрне уйлаганда, кабат-кабат елмаеп куя. «Кәкре сыйрак» дими ничек әйтсеннәр инде. Үзе ябык, аяклары тагы да дигәндәй. «Кечкенәм дә, төш кенәм» дип, ире генә яратып дәшә иде шул аңа...

Йә, йә! Әллә бик күбәеп тә китте инде бу ромашкалар? Әле менә кызы ни дияр? И, сизмәс тә әле, күренми дә кебек бит! Гасимә, тынычланып, рәсемне диварга элеп куйды. Күңеле җылынып китте, әйтерсең яңа пешеп чыккан боткага бер калак май китереп салдылар! Үз эшенә үзе сокланып, озак кына карап торды. Чү! Әллә ничек кенә бер мәлгә рәсемдәге чәчәкләр селкенешеп куйган кебек булдылар. Караган саен үз күзләренә үзе ышанмады Гасимә. Ул ясаганнарын читсенәләрме, әллә болары үзләрен үз савытларында хис итмиме? Гасимә ике кулы белән күзләренә баскалап алды. Арылды бугай! Күптән кулга буяу тоткан юк ласа! Аннан соң гына үзенең самимилеге белән: «Әй, кипкәч, бөтенләй башка төс керә әле аларга, пойдет!» – дип куйды.

Ниһаять, эштән кызы кайтты! Күрерме икән, үзем әйтимме?..

Күрмәде! Ничек? Шулай ук күренми дә, беленмиме икән? М-м-м, оста да икәнмен!.. Мең уй узды башыннан Гасимәнең.

Көннәр үтә торды.

Ә беркөнне…

Кызы кайтырга да байтак вакыт бар, Гасимә ялгызы гына юыну бүлмәсен җыештырырга керәште. Рәхәт ичмасам! Ниндидер сулы краска гына сылаганнар иде түшәмгә, инде берничә ел ап-ак тора. Бераз саргаеп китсә, сулап юып аласың да вәссәлам! Тагын ап-ак, рәхмәт төшкере! Кафельләрне, ваннаны ялт иттерде Гасимә. Менә түшәмне кызыннан башка булмас, мөгаен…

«Булыр! Ул кайтканчы «сүрпериз» ясап куям әле! Исе китсен, ничек юдың, дисен!..»

Кызының исе китте, ничек кенә китте әле! Ишек ачарга чыккан әнисенең кулы буйлап кан сиптергәнен күреп, ул егылып китә язды.

– Әни! Нишләдең инде тагын?

– ?..

– Әни, кулың…

Шунда гына күрде Гасимә: авыртмаган да кебек иде, яхшы ук кан ага икән…

Кул, терсәк турысыннан ярылган иде. Аны марля белән аз гына бәйләгәндәй иттеләр дә, травма үзәгенә барып, яматып, бәйләтеп кайттылар.

«Ярый әле машинасын стоянкага куеп кайтмаган, ярый әле теге «үзәк» дигәннәре ерак түгел! Вакытында кайтып җитте, Аллага шөкер! Каным агып беткән булыр иде… Тәүбә-тәүбә!» — дип уйлады Гасимә.

Ничә тапкыр әйтә инде кызы: «Миннән башка бернәрсә эшләмә, әни! – ди. – Син олы бит инде, ялгыш басуың бар! Аннары интегеп йөрерсең…»

«Көне буе өйдә торгач, эштән арып кайткан кешене көтеп торырга аның «совесте» дә, җаны да түзмәгәнен беләмени ул?.. Әй, үзем дә шул эшсезлеккә өйрәнә алмадым инде! Рәхәтләнеп ял ит, кибетләргә чыгып кер, имеш! Кибетендә ни бар инде? Авыз ачып сөйләшергә бер кешесе юк бит! Авылда, ичмасам, ипигә дип кенә барасың да өч сәгатьләп йөреп кайтасың. Бодайны

кырдан суктырып, он ясап, ипи пешергән вакыт үтсә үтә, тик рәхәт бит! Бөтен яңалыкны ишетеп, аны тагын да арттырып сөйләрлек булып «җитешеп» кайтасың...»

Кайткач, ванна бүлмәсендәге урындыкларны күреп, кызы тагын аһ итте:

– И әни! Кем инде таш плитәгә урындык өстенә урындык куеп менеп баса... Әле дә Алла саклаган бит үзеңне!

Кызы кулы сызлаудан әрнеп яткан әнисен кочып алды. Тегесе сызлавыннан тәмам тулышып, монысы әнисен жәлләп елашып алдылар.

Аннан сүз башлады кызы:

– Әни, бу ромашкаларыңны бик оста ясагансың, әмма аларны юып алырга кирәк. Ярар әле майлы буяулар белән тотынмагансың! Ул бит кеше иҗаты, әни! Кешенең күңел халәте, илһам чагылышы! Үзе ничек күрә, шулай иҗат итә ул аны. Кеше әйберенә тияргә ярамый, дип, мине өйрәткән әни кая соң?

Җиңелчә генә шелтәләгән булды да, тукта әле, бераз куркытырга кирәк дип, тагын өстәп куйды:

– Урлау белән бер инде бу, әни! Кемнеңдер күңел халәтенә хыянәт иткәнсең бит син! Шуңа күрә сиңа «наказание» килде, беләсеңме, «художнигым» минем!

## *Кеше өсте – без өсте*

Авыр, бик авыр уйлар белән йокларга ятты Гөлем.

Калага килеп кергәч тә, Ләйлә янына ашыккан иде бит ул... Гөлйөземнең:

– Йөрмик әле, Гөлем, кеше өсте – без өсте, диләр, кунакханә бардыр ич? – дигәненә дә карамады:

– Барыйк әле. Минем аны шундый күрәсем килә. Килегез, диде ич!

Кечкенәдән авыртып интеккән Гөлйөземгә табиблар күптән инде операция ясатырга киңәш итәләр. Тик ул: «Күпме бирелгән, шул гомеремне яшәрмен, пычак астына кермим», – ди. Гомер-гомергә шулай инде авылда. «Бүлнис» дигән сүзне ишетсәләр, йөрәкләре ярыла. Бала-чага бәләкәй чакта бара алмыйсың. Бүлнис юлында йөрергә дә ай-һай! Эшеңдә дә үз урыныңа калдырыр кешесе табылмый. Ә йорт?.. Мал-туар, кошкорт? Син чыгып китсәң, балаларны, йорт-җирне кем карый? Бакчасына, мәктәбенә кем озата? Әле каенана сөйләнә, әле ире… Мең төрле сәбәп табып сузасыңсузасың да, олыгая башлагач, берәр җирдән килеп чыга инде. Ярый ла соңармасаң. Күпләр яшьли китеп тә бара. Менә ятимнәр, менә сыңар канатлар, менә җимерек гаиләләр…

Үз гомерендә бер тапкыр да ялгыз-яры юлга чыкканы булмаган Гөлйөземгә игезәк сыңары:

– Бергә барып кайтыйк инде, юл газабы – гүр газабы, диләр, иптәш булырсың, – дигәч, ул каршы килә алмады.

Һәм менә алар калада. Ике сумка тутырып алып килгән күчтәнәчләре янына шәһәр ширбәтләре дә өстәлде. Буш кул белән йөрми инде авыл кешесе.

…Ишекне Ләйләнең ире ачты. Ләйлә үзе кайтып җитмәгән икән әле. Нәрсә-нәрсә, ирдән уңган Ләйлә, монысы хак! Әллә кай арада өстәлен әзерләп чәй дә эчертте, ачык итеп сөйләшеп тә утырды, авыл хәлләрен, гаиләләр иминлеген сорашып чыкты. Рәхмәт!

…Ләйлә кичке җиделәрдә генә кайтты. Машинасы белән нидер булганмы, юлда тоткарланган булып чыкты. Үзе йөртә ул. Шуннан арысын кем белгән?

– Сез, күрәм, бик әйбәт урнашкансыз. Чәйләр эчтегезме соң? Хәзер берәр нәрсә әзерлим, ашап алырбыз, – ди-ди, юыну бүлмәсенә узды. Тик нәрсә исенә төшкәндер, нигә шуның хәтле тиз арада әйтү кирәк булгандыр, Ләйлә бик тиз әйләнеп тә чыкты: – Аяк-

ларыгызга тапочкалар алып килү кирәк иде, – дип куйды.

Ток суктымыни Гөлемне. Бер Ләйләгә, бер аягына карый-карый катып калды. Аягында әле кер кунарга да өлгермәгән ап-ак йон оек. Нәрсә ярамады, ковер пычрана, дидеме, Гөлем аңламады.

Тапочка йөрт, имеш. Ничек инде? Авылдан килгәндә сумкаңа күчтәнәч салырга, авылча, мөселманча суйган итен, маен-каймагын, эремчеген авыз иттерергә тырышасың бит! Инде үзең белән аяк киеме дә алып йөрергә кирәк, күрәсең... Шәһәр халкы шулайдыр инде...

...Күзенә һич йокы кермәде, әйләнде дә әйләнде Гөлем.

Ләйлә – аларның күрше кызы. Бергә уйнап үстеләр. Мәктәптә дә өч кыз гел бергә булдылар. Алай гынамы, дәресләр беткәч, бергәләшеп кайталар да бер-берсенең идәннәрен дә бергә юалар иде ич алар... Укыды да укыды ул. Соң гына кияүгә чыкты, балалары булмады. Ничек тарайган Ләйләнең күңеле. Кая соң ул балачактагы, челтер чишмә суыдай саф күңелле Ләйлә? Әллә куна килүләрен ошатмады микән? Уйлый-уйлый да, әмма барыбер соңыннан ни булганын хәтерләми бугай Гөлем. Чынында Ләйлә ачык иде үзе, сөйләде дә сөйләде... Авылдан килгән дустының кәефе кырылганын сизмәде дә бугай. Гөлемгә авыр тиде шул. Утырып кичке ашны ашаулары, гаилә альбомын караулары бар да куе томан эчендә калган. Ни сөйләшкәннәре дә хәтердә юк. Бары тик, кая басыйм икән, монда бассам, кәефләре кырылмас микән, дип уйлап йөрүе генә истә калган. Үзе анда, уе әллә кайда булды...

Һәрхәлдә, кунакка барам дип атлыгып торган Гөлем гел икеләнеп кенә килгән Гөлйөземнең йөзенә туры карый алмады. Ул да борчылды, Гөлемнең йоклый алмый ятуына эче пошты. Үзе дә йокламады...

Гөлем Ләйләне кызганып куйды. «Җанына туганда ук ана сөте белән җир җылысы да иңгән бала туган

кадерен дә, кеше кадерен дә белер ул, белми калмас» ди иде Гөлемнең әбисе. Мәктәпне тәмамлауга шәһәргә киткәнлектән, Ләйлә, бәлки, дуслык дигән җылы хисне татый да алмагандыр. Ә шәһәр җире маңгай күзен тиз томалый шул. Ике институт бетереп, хәзерге вакытта зур бер университетта ректор урынбасары булып эшләгәч, авыл кешесе белән вакланып тормас бит инде!..

Кая гына бармады да кем белән генә аралашмады Гөлем?! Тик менә авылдашыннан, күршесеннән, якын күргән балачак дустыннан мондый карашны көтмәгән иде. Ял иткәндә танышкан венгрияле гид Ливия Фекете белән әле дә хат алышуы, Үзбәкстан кызларыннан әле дә килеп торган посылкалары үзе генә ни тора! Ә авылда? Авылда да бик яраталар Гөлемне, кунак өзелеп тормый. Үзе дә кайсы йортка керсә, шунда якын. Бөтенләй чит-ят, гомердә бер күрмәгән күпме юлчы ишек шакып кергәне, кунып киткәне бар аларда. Рәхмәт әйтеп газеталарга яздылар хәтта...

Гөлем – абруйлы укытучы, галимә. Ничәнче кат инде авылдашлары, аңа ышаныч белдереп, авыл советына депутат итеп сайлыйлар. Олысы-кечесе киңәш сорап та, башка сорау белән дә килә аңа. Кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә, авылдашларының хәтерен калдырмаска тырыша, көчен дә, вакытын да кызганмый. Ничек итеп кешене шулай яратмаска кирәк?!

...Авыр уйлар белән таң алдыннан гына йоклап киткән Гөлем, тагын да авыррак төшләр күреп, бөтенләй ял да итә алмыйча йокысыннан уянганда, барысы да йоклый иде әле. Хуҗалар уянмасын дип, кымшанырга куркып ята-ята да арып бетте инде ул. Тизрәк таң атсын да, тизрәк чыгып китәсе иде...

Иртән битен юарга дип юыну бүлмәсенә кергән Гөлемнең исе киткән тагын бер хәл булды. Кичтән ваннада ялтыр-йолтыр килеп торган калай савытларга сокланып карап торган иде ул. Калай савыт та, теш щеткалары белән сабыннар да юкка чыккан! Алып юыныр-

лар дип шикләндеме икән? Паста-щеткасын, сабын-сөлгесен үзеннән калдырамыни ул?!

...Ләйлә танымаслык булып үзгәргән. Үзгәрткән дөнья Ләйләне. Дөньямы? Дәрәҗәме?.. Авыл кызы, бергә уйнап үскән күршесе бер генә җөмлә әйтте дә соң... Аңлады Гөлем, дурак түгел. Ул аны бөтенләй ят итте. Моның хәтле дә чит булырмын дип күз алдына да китермәгән иде. Ә нигә чакырды соң ул аны? «Юк, бүген өйдә булмыйбыз, барасы җиребез бар!» дигән булса соң? «Китмәгез инде, барыбер киләм» димәс иде лә Гөлем. Барыр җире, кунар урыны юк түгел, бар бит аның. Дөнья күрмәгән, беркем белән дә аралашмаганмыни ул? Ләйләне күрәсе, аның белән сөйләшеп утырасы килгән иде... Бәллүр савытлар тутырылган затлы шкафлар белән, заграничный паласларын күрсәтәсе, менә мин нинди тормышта яшим диясе генә килде микәнни?..

Ләйлә:

– Үз күчтәнәчләрегез белән чәй дә эчмәдегез, – дип озата чыкты.

– Анализлар бирәсебез бар, ач карын барырга ич анда, рәхмәт, Ләйлә, – дип саубуллаштылар.

Кая ул, эчәме соң! Тизрәк, тизрәк чыгып китәсе, һавага чыгасы килде аның. Ничек кенә зур булмасын да, нинди генә затлы җиһаз белән тулмасын, бу кысан, тар бүлмә хуҗаларының үзләре кебек үк кичәдән бирле җанны талый, сулышны кыса иде.

Иртә кузгалсалар да, шәһәр урамында халык гөж килеп тора, кем эшкә, кем эштәндер. Этешә-төртешә автобуска ашыгалар. Шушы иртәнге ыгы-зыгыда Гөлем белән Гөлйөзем дә бар. Таң белән торып, сыер саварга чыкканчы ук ипиләп, каймаклап чәй эчәргә өйрәнгән Гөлйөзем бераз дәшми барды да:

– Чәй эчәргә иде инде, минем болай башым әйләнә бит! – диде.

Гөлем аны кочып алды:

– И-и, Гөлйөзем, җаным! Хәзер, бераз түзә алсаң,

мин сине шундый тәмле итеп чәй эчертермен, бераз түз генә.

Алар «Гөлнәзирә» кафесында көлешә-көлешә коймаклап чәй эчтеләр.

Юллары уңды, эшлисе эшләре дә эшләнде. Табибына да күренделәр. Ходайның рәхмәте чиксез шул!

Ә менә Ләйлә күңелгә юшкын утыртты. Йөрәгеңә йон үскән булса, исемем илдә, урыным түрдә, дип кенә булмый шул ул. «Мосафирны чәй эчереп чыгарсаң, урының җәннәттә булыр», – ди иде Гөлемнең әбисе.

Бу дөньяда кеше хакы барын да онытмаска иде...

## *Курыктым шул, улым*

Кош-кортларын карап кергән Мәймүнә түти сәгатькә карады да хәйран калды. Дүрт тулып килә.

«И, Алланың рәхмәте, сине көтеп тормый шул вакыт дигәнең, чаба да чаба», – дип, үзалдына сөйләнеп куйды ул. Күпме ашыкса да, вакыт бик аз калганын күрде. Югыйсә төшке ашны ашаганда ук, кичке автобуска чыгарга уйлаган иде дә...

Әлмәт шәһәрендә яшәүче кызы күптән кунакка чакыра. «Кил әле, әни, ял итеп китәрсең. Мәтрүшкәгә барырбыз» дигәненә дә байтак. Бүген тәвәккәлләп юлга чыгарга иде исәбе.

Буш бармый Мәймүнә түти. Авылдан килә бит! Онытгы ничек көтә авыл каймагын! Үзенеке юк югын, аның каравы күршеләрендә өч сыер. Шөкер, сөте дә бар, катыгын, турасын да ясап тора Мәймүнә карчык. Бер чиләк сөт сатып ала да каймагын да аерта, маен да атлый.

«Аллага шөкер, Ходай исәнлек бирсен», – ди-ди тутырган сумкасын күтәреп карагач, авырсынып куйса да:

– Афтабус авыл уртасыннан үтә, иншалла! – дип, ашыга-ашыга киенә башлады.

Урамдагы эсселеккә чыдар чама юк. «Урак өсте бит. Бирсен Ходай, әрәм-шәрәм итми генә игене дә җыелсын». Кызы бүләк иткән ачык яшел күлмәген киеп, ак яулыгын бәйләде дә көзге янына килде Мәймүнә абыстай. Көне буе чирәмдә каз бәбкәләре саклый-саклый каралып беткән йөзе, ак яулык бәйләп куйгач, ачылып, матураеп китте. «И, аның бит хәзер көзгесе дә әллә нишләде. Менә ичмасам безнең заманда бар иде көзгеләр, карап туймас идең, иллә дә матур күрсәтәләр иде», – дип, үз-үзенә шаяртып алды. Телевизор сүнгәнме, утюг-фәлән калмыймы икәненә инангач, бисмилласын укып, ялгыз калачак өенең почмакларын сыпыргалап чыкты. Янәсе, карак кермәсен, җен илермәсен! Ишеген бикләп, капкадан чыкканда да сәфәр алдыннан укый торган «Лә иләһе илләллаһу хәерле хәләс, лә иләһе илләллаһу Хозыр Ильяс» догасын укып, тәвәккәлләп юлга чыкты.

Чыгуын чыкты, тик автобусы гына утыртмыйча китеп барды шул. Инде нишләргә? Өйгә кире кайтса, балаларга дигән күпме күчтәнәче әрәм була. Өзелеп көтеп торган оныгы... «Юк инде, Алла язмаган эш булмас, ялгыз-яры шоферга утырмам» дип, юлчы машиналарга кул күтәрергә булды.

Шулчак «Газель» машинасы килеп туктады.

– Әлмәткә, сынок, Әлмәту, – диде ул, кабинада ике кеше икәнен күргәч.

– Әйдә, әби, без дә Әлмәткә кайтабыз!.. – Шоферның уң ягына утырганы, ак күлмәкле, галстуклысы әбигә «Газель» ишеген ачып утырырга булышты.

«Монысы нәчәлнигедер инде», – дип уйлап куйды әби.

– Әй, рәхмәт төшкерләре, менә рәхмәт...

Беренче күрүедерме, Мәймүнә түти машина эчен күзәтергә кереште.

«И, кара ничек итеп кеп-кечкенә афтабус ясап куйганнар бит, ә? Ни генә юк хәзер! Бәрәкалла, ул урындыклары дисеңме! Өйдәге диванмыни, аның йомшак-

лыклары!..» Күрмәсеннәр тагы дип уйласа да, урындыкларны сыйпап карарга да өлгерде карчык.

Шофер егет белән «нәчәлник» гөлдер-гөлдер (рус телендә инде) сөйләшеп барсалар да, руль тотканы әледән-әле маңгай каршындагы көзгедән әбигә караштыргалап ала. Мәймүнә түтинең күзләре бер генә түгел, әллә ничә очраштылар инде аның белән, тик ул баштарак игътибар да итмәгән иде. Ә менә ешракка киткәч, әбигә шик керде бит!

«Юньсез бәндәләр генә була күрмәсен берүк. Алла, диген! Хәзер кешене тышкы кыяфәтенә карап кына белеп булмый. Милициясе дә бур аның, галстуклысы да бандит! И Аллам!» Мәймүнә түти күңеленә килгән уйдан әллә нишләп китте. «Йә Раббым! Бер Ходаем! Кодрәтең киң, рәхмәтеңнән ташлама! Изге юлга чыктым, балалар хәлен белеп йөрим ләса».

Машина, әкренәя барып, юл читенә килеп туктады. Шофер да, аның янына утырганы да, чыгып, сөйләшә-сөйләшә, тәмәке көйрәттеләр. Эсседән сусауларын басып, шешәдән генә «Кола» эчтеләр...

Үзе белә торган догаларын кат-кат укып, Алладан исән-имин алып баруын ялварып утырган Мәймүнә түтигә монысы да ярады. «Эчеп тә куйдылар. Нихәл итим? И-и, борылыплар гына кайтасым калган икән!» – дип уйлады ул.

Байтак юл үтелде. Дога укый-укый барган Мәймүнә түтинең дә шикләре бераз тарала төшкәндәй булды. «И, бу уй дигәнең! Уйларга да өлгермисең, күңелгә керә дә урнаша. Әй йөрисең аннан соң интегеп, ут йотып, яна-көя...»

Машина кинәт уңга, юл читеннән ерак түгел урман юлына борылды. Шул вакыт әле тынычлана гына башлаган Мәймүнә түти әче кычкырып ишеккә ташланды.

– И Ходаем!.. Йә Раббым!.. Останави! Останави юлкы-палкы, не иду я! Здесь останави... А то худо будет... Оятсызлар, сиксән яшьлек карчыкка тимәсәгез, юлда беткәндер шул... И Аллам!

Ике кулы белән ишек бавын күпме тартса да, «Газель» ишеген тиз генә ача алмасын аңлады үзе. Шуннан соң гына ул «нәчәлник»нең:

– Әби, нигә кычкырасың? Без әнә шул комбайннарны гына карап чыгабыз бит! Монда минем участок бар. Тынычлан да, догаларыңны укып, Алладан сора! Яңгырлар бирми тор, диген! Бик ерак юлдан кайтабыз әле. Кызлар түгел, үзебезне дә күрәсебез килми. Бик алҗыдык, – дигәнен ишетеп алды.

Үзенең уйдырмаларыннан гаҗиз калган Мәймүнә түти оялып та, шатланып та:

– Әйе, сиңа кирәктә, Алласы да әллә кая йөри бит әле аның, – дип тынычланып, кеткелдәп куйды...

Кырда кызу эш кайный. Комбайны ура, машинасы ташып тора. Уңды быел икмәк! Вакытында, югалтуларсыз җыеп алырга насыйп ит, Раббым Аллам!

Олы юлга чыгып, кайту юлына борылгач та, «нәчәлник» әбигә карый да көлә, карый да көлә:

– Ну, әби! Бирдең кирәкне! Көлдереп, бөтен арыганнарны бетердең, ә?! Үзең юл буе укып барасың, үзең ышанып та бетмисең бугай Алла дигәненә, ә?

– И улым! Алай дия күрмә. Алла бар ул! Ансыз яшәү юк! Аңа тел-теш тидерү – зур гөнаһ! Гел юлда йөрисез, догалы булыгыз, балакайлар! Курыктым шул, улым, дөньясы үзгәрде бит!

Мәймүнә түтине кызы торган өйнең ишегалдына ук китереп куйдылар.

– И, Алланың рәхмәте, килеп тә җиттем, – диде ул, шатланып.

Әби төшеп киткәч тә уйга калды «нәчәлник». Менә авызын тутырып дога укып килгән ак яулыклы карчыкның да күңеле тыныч түгел. Куркып, шикләнеп, нихәтле борчылып килде. Кычкырып ишеккә ташланганда ниләр уйлагандыр, мескенкәй?.. Әй, бу заманның үзгәрүе, әй, бу кешеләрнең кырыслануы... Адым саен үтереш, суеш, көчләү... Кая таба барабыз соң без?..

## *Кабатлана икән язмышлар*

Мәдинәнең күзенә йокы кермәде. Төнне көчкә чыкты. Күзен йомып караса да онытылып йоклап китә алмады. Кичә кичен, унөченче июльдә булган фаҗигагә шаккатып, елый да, йоклый да алмады.

«Нәрсә була инде бу? Әй Ходаем! – ди-ди ыңгырашты. – Башка сыймаслык хәл бит. Күргәнгә сабырлык бир дә, күрмәгәнгә күрсәтмә!» – дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, инде йоклап булмасын белеп, бүлмә якка чыкты.

Таң атып, яңа көн туса да, аңа тормыш тукталгандай тоелды. Бер эшкә кулы бармады. «Йә Раббым» дип уфтанды да уфтанды ул.

Һәркемгә мәгълүм, үлек өстенә барганда тәһарәтсез барырга ярамый. Ул, йоласына туры китереп, әбисеннән калган җиз комган белән юынып керде. Олы яктан ире Рамилнең чыгып килгәнен күреп:

– Кабер казышырга барасың булыр, чистарынып алуың кирәк иде, – диде. Мәдинәнең тавышы чыкты да кебек, чыкмады да.

Инде ничә көннән бирле эшкә бара алмас дәрәҗәдә «салмыш» йөргән иренең көндез дә, төнлә дә йоклаудан шешенеп беткән күзләре зур булып ачылдылар:

– Нинди кабер, кемгә?..

Менә шунда әллә нәрсә булды Мәдинәгә. Иренең эшләмичә эчеп йөрүенә ачуы тулып ташкан идеме, төне буе сызланып чыккан йөрәге бушанырга теләпме, ике кулын битенә куеп, үксеп еларга тотынды.

– Илмир бит, Тәлгат малае Илмир, – дип кенә әйтә алды.

Яшьләре су урынына актылар Мәдинәнең. Күкрәк түреннән әрнеп, улаганга охшаган тавыш чыгарып, үксеп-үксеп елады ул. Берничә тапкыр салкын су белән битен юып караса да туктый алмады. Дүрт ел элек кенә нәкъ шул көнне үлеп киткән Тәлгатне дә уйлап, инде

берданберен – малаен югалткан, улсыз калган Равиләне дә уйлап елады...

«Йә Раббым, сабырлык бир!» Юынып-кырынып мунчадан кайтып кергән ирен күргәч кенә, үз-үзен кулга ала алды. Башына бәйләргә дип ак яулык тоткач, йөрәге тагын жу итеп китте Мәдинәнең.

«Әй Ходаем! Ничекләр итеп шушы сөлектәй сабыйны, яңа уналты яшен тутырган баланы кап-караңгы, сап-салкын гүргә илтеп тыкмак кирәк? Әй, бу әҗәл дигәнең, беркемне дә аямый, яшь дими, карт дими шул...»

...Кызу урак өсте иде. «Равиләнең Тәлгате үлгән!» дигән хәбәр яшен тизлегендә авылга таралды. Равиләне жәлләп халык гөр килде:

– Әй, балакай! Әнисе язмышын кабатлый икән...

– Ярый әле улы Илмиры бар...

– Менә Равилә дә ялгыз калды... – диештеләр.

Үзе кебек бик күп иптәшләре белән урак өстендә комбайнда эшли иде Тәлгат. Иртән бергә килгән, инде эш башлаган иптәшләре:

– Ник һаман кузгалмый соң бу? – дип янына барсалар, Тәлгатне комбайнга сөялеп утырган килеш күрәләр... Ярдәм итәргә соң була инде. Аны әнисе яши торган авыл зиратына алып кайтып күмделәр. Менә шулай ирен югалтты Равилә. Дүрт ел элек, нәкъ шушы көнне. Унөченче июль иде ул...

– Улым, иртәгә әтиең янына зиратка барырбыз, озак йөрмә! – дип кичтән озатып калган Равилә мотоцикл белән күрше авылга киткән малаен. Йә Алла! Менә бүген дә унөче. Бара балакай, әтисе янына бара...

Уйласаң уй – Равиләнең әнисе Галимә җиңги дә утыз биш яшендә тол калды. Ничек диген әле! Эштән кайтканда трактор белән әйләнеп капланды ире. Ул да шушы «каһәр төшкән» унөче, хәтердә әле, коеп яңгыр яуган көн иде. Тимерләр астында озак кысылып яткан. Эх, күрүче булса, бәлки...

Каенана-каената йортында буйга җиттеләр Галимә

җиңгинең кызлары. Бер бәхетең булмагач дипме, Галимә апа башка кияүгә чыкмады. Югыйсә сораучы да булмады түгел. Үз көенә яшәп, кызларын урнаштырды. Шөкер, тәртипле булдылар, яманатлары чыкмады. Тик менә язмышлар кабатлана икән шул. Уртанчысына – Равиләсенә – үз язмышы язган икән.

Кечкенә чагыннан җырлый Равилә. Авылда концертлар аннан башка үтмәс, сорап-сорап җырлаталар. Берәүне дә кабатламый торган, үзәккә үтәрлек, үзенә генә хас моңлы тавышы белән җырлап җибәрә дә күңелеңнең әллә кайсы җирендә яшеренеп яткан сагышларыңны айкап чыгара, шушы хискә түзә алмый елап җибәргәнеңне сизми дә каласың. Әллә инде «моңлы бала бәхетсез була ул!» дигәннәре дә хакмы соң?

Әнә шундый уйлар белән килеп җитте Мәдинә Галимә җиңгиләр өенә.

...Капка төбе халык белән тулган. Бер читтә ир-атлар җыелган, икенче якта – хатын-кызлар. Кайсы чыш-пыш сөйләшә, кайсы яулык чите белән авызын каплап шыпырт кына елый. Күзләре белән күпме эзләсә дә, Мәдинә төркемнән Равиләне күрә алмады.

– Әнисе, каенанасы, туганнары барысы да мәет янында – өй эчендә, – диде кайсыдыр.

Авыл тирән кайгыда. Урам әле кичә генә мотоцикл белән күрше авылга, сөйгән кызы янына дип киткән улы – баһадирдай егете белән хушлаша. Кая карасаң да, кемгә күз салсаң да, сөйләшү юк. Ым гына кага халык.

Беравык капка төбе тып-тын калды. Төркемнәр капка тирәсенәрәк тартылдылар.

– Илмирны алып чыгалар, – диде кемдер.

Мәдинә алгарак күз ташлады. Ишек төбендәге ак яулыклы әбиләрне икегә аерып, Равиләнең әнисе Галимә җиңгине, аның бертуган ике сеңлесен, аларның кызларын күреп алды. Әнә Равилә дә күренде. Аны җитәкләп чыгалар... Мәдинә үксеп куйды, көчкә авы-

зын тотып өлгерде. Равилә сыгылып төшкән, аягына да баса алмый. Аны күтәреп диярлек йөртәләр. Үзе бертуктаусыз:

– Улым, Илмирым!.. Бәбкәм, балам-м!.. – дип ыңгыраша. Янында табибә сеңлесе беренче ярдәм күрсәтеп тора. Улының гәүдәсен ихатадан алып чыгып киткәндә Равиләнең үзәк өзгеч:

– Алып китмәгез, калдырыгыз! Бала-а-ам, Илмирым!.. – дигән тавышы һаваны ярып җибәрде. Ул, якын тирәдәге һәрбер йортның тәрәзәсенә кагылып, нишләргә дә белми тирбәлеп торды да аннан йорт эченәме, сарай почмакларынамы кереп тынып калды. Аңсыз калган Равиләне машинага утыртып, улын соңгы юлга – зиратка алып киттеләр…

…Мәдинә аякларының хәлсезләнә, күз алларының караңгылана баруын тойды. «Бераз булышырмын, бәлки, юышырга, җыешырга кирәктер», – дип өйгә керергә уйлаган ниятеннән дә кире кайтты. Тамак төбенә килгән төер сулыш алырга да, төкерек йотарга да ирек бирмәде. Хәле сизелеп начарая барды. Ул әкрен генә кайту юлына борылды.

Әй, язмыш, язмыш! Нигә шулкадәр кырыс соң син? Нигә дип инде ялгыз хатын ишегенә кагыласы иттең? Болай да ялгыз бит ул! Нинди олы хәсрәткә салдың тагын бер бәндәңне! Бөтен өмете, таянычы иде бит ул аның!

Кунак кына булып киләбез дә, әллә нинди күрәчәкләргә тап булабыз, упкыннарга төшәбез шул.

«Сабырларны җәннәт рәхәтенә күмәрмен, дигән Ходай, сабыр булыгыз!» – ди иде әби…

Сабыр итим, сабыр итим,
Сабыр итми ни хәл итим…

Мәдинә җырлый, ә ике күзеннән туктаусыз яшь ага да ага иде…

## *Күңел җылысы җитә*

Урамда көз. Бит читләрен кытыклатып, вак кына яңгыр сибәли. Бар җиһан, алда салкын кышлар барын тоеп, тарткалаша, елый сыман. Алтын-сары яфраклар сагыш төсе булса да, көз – муллык чоры. Язын кырда сайрашкан көзен ындырда ыңгырашмый инде! Хезмәт үзенең җимешләре белән сөендергән, уңыш җыелып, амбарларга салынган, авыл кешесенең беразга гына булса да ялга туктаган чагы.

Бүген укытучы Шәһрия дә чыршы-нарат урманы эченә урнашкан шифаханәләрнең берсендә ял итеп ята. Тәрәзәдән карасаң, ярым ай рәвешендә бер-бер артлы чыршы агачлары тезелеп киткән. Кыл уртада, горур башларын ерак күккә төбәгән өч каен янында, ниндидер сәнгатьче кырлап-сырлап ясаган агач эскәмия тора. Чык та утыр гына, чыршылар җил дә тидерми саклар үзеңне.

Шәһрия табигатьне ярата. Бала чагыннан рәссам булырга хыялланган кыз, гомере буе урман-кырлар, басу-болыннарга чыгып ләззәтләнде. Анда гына рәхәтләнеп ял итә, онытыла иде. Матурлык дөньясында ул үзен бөтенләй башка дөнья белән аралашкандай тоя. Һәр чорның үз матурлыгын, үз гүзәллеген күрә, тоя белә. Тән-җан байлыгы, рухи байлык таба ала. Шуңа да күңеленнән «бүлмәм бигрәк җайлы җиргә туры килде» дип уйлап куйды.

Кичкә каршы бүлмәгә ике яшь кыз килеп керде. Шәһриянең беразга кәефе китеп, яшьләр белән кыен булыр, үз ишем кирәк иде дигәндәй, борчылып алды. Тик, шикләнүләре бушка икән. Ике бертуган Гөлназ белән Гөлшатның сөйләп сүзләре бетми, сөйләшәләр дә көләләр, икесе дә бик ачыклар. Кичке ашка ашханәгә төшкәндә, Шәһрия апаларын ике яктан җитәкләп үк алдылар:

– Шәһрия апа, сез безне үз кызларыгыз дип белегез, – диде Гөлшат.

– Бәйләнә башласалар, минем кызларга тимәгез, дип, безне яклагыз, – дип шаяртып алды Гөлназ.

Шәһрия апаларының кызлары юклыгын, кызлы булам дип, биш малай алып кайтканын, аларның һәркайсының инде үз гаиләләре барлыгын, бүгенге көндә җиде оныкның әбисе ялгыз гына авылда яшәвен кызлар кичен, йокларга яткач кына белделәр.

Ә Шәһрия үзе әле һаман калада үскән кызларны сынавында булды.

Иртән чәй эчәргә дип өстәл янына утырдылар гына, тәрәзәгә нәрсә беләндер бәрделәрме, бүлмә селкенеп куйды. Доңк иткән тавышка сискәнеп кызлар тәрәзәгә йөгерделәр.

– Смотри, птичка упала, – беренче булып Гөлшат кычкырды.

– И Аллам! А что делать? – диде Гөлназ, тәрәзәне ачып.

Шәһрияләр торган бүлмә шифаханәнең икенче катына, кыл ашханә өстендә урнашкан. Тәрәзәне ачуга, бүлмәгә шифр түбә тоташып китә. Песнәк очып килеп бәрелгән дә түбә өстенә, әмма ераккарак килеп төшкән икән. Кул сузып кына аңа ярдәм итеп булмый. Тынсыз, өнсез яткан песнәк кузгалырмы дип, кызлар түбә буйлап су агызып җибәрделәр. Кош, тәненә барып тигән судан, бераз селкенеп куйды.

– Исән, исән!

– Ой, Слава Богу, үлмәгән! – Кызлар сикергәләп, кулларын чәбәкләп алдылар.

Әмма «терелү» озакка бармады, бәлагә тарыган җан иясе тагын хәлсезләнеп башын салындырды.

Бәләкәй буйлы, җитез Гөлшат, тәрәзәдән чыгып, шифр түбә буйлап кош янына атлады. Шәһриянең:

– Юк! – дип кычкыруын ишетмәде дә курку белмәс кыз:

– Түздерә* ич, курыкмагыз! – диде ул.

---

* *Түздерә* – җимерелми, түзә, чыдый.

Гөлшат ярым үле кошны, менә хәзер эреп юкка чыгачак кар бөртеге белән эш иткән сыман сак кына тотып, бүлмәгә алып керде. Аны кулъяулыкларына төреп, печеньедән бушаган кәгазь тартмачыкка салдылар. Авызын көчкә ачтырып, сөт эчерттеләр, башыннан сыйпап назладылар. Шәһрия исе китеп, күзен дә алмый кызларга карап торды. Бу минутта алар аңа яшь балалы әниләрне хәтерләттеләр. Чәйләре чәй булмады. Кулларына чәшкеләрен* тоткан килеш тәрәзә төбендәге тартма яныннан китмәделәр.

Ходайның рәхмәте, кошчык терелде! Пырр итеп тартмадан очып чыкты, әмма ерак оча алмады әле, туп-туры идәнгә килеп төште. Кызлар тагын, ай-вай, ди-ди, «авыруны» күтәреп алып тартмага салдылар.

– Аның тәпиен җылы суга тыгарга кирәк, кан әйләнешен яхшырта ул, – Гөлназ шулай сөйләнә-сөйләнә кошчыкның аякларын суга тыгып торды, авызы белән җылы сулышын өрде. Башыннан ук төреп, янә урынына салды.

Бу кече күңелле кызларның күзендә яшь бөртекләре күреп, Шәһрия гаҗәпкә калды. Ягымлылыкларына игътибар итте. Нинди тәрбияле балалар, дип кызыксынып һаман кызларны күзәтте. Эх! Бу җылы сүзләр, җылы кулларның тәэсире!

Тик уйлар хөкемендә озак юана алмады, бар тынлыкны кинәт шау-шуга әйләндереп, кош кабат тартмадан очып чыкты да түшәмгә, аннан ачык ишектән коридорга атылды. Кечкенә канатларын пырылдатып очты да очты. Кызлар, бала-чагалар кебек чырык-чырык көлеп, аның артыннан йөгерделәр.

«Кош өйгә керсә, үзе үк очып чыгарга да тиеш» дигән борынгылар. Авыл кешесенең сынамыш-юрамышлар белән башы катып беткәнгә, Шәһрия, ах-ух килеп, кызлар артыннан:

---

* *Чәшке* – чынаяк.

– Кумагыз, куркытмагыз, кызлар! Үзе чыгарга тиеш ул! – дип кычкырып калды.

Кош бер-ике урады да ачык форточкадан урамга очты.

Кызлар, бүлмәгә бик якын әйберләрен югалткан кебек сөмсерләре коелып керсәләр дә, кошны күзәтеп бер тәрәзәдән икенче тәрәзәгә йөгерделәр.

– Әнә каенга кунды... Әнә очты... – ди-ди куаныштылар.

Олы буынның «Яшьләр безнең өметне аклый алырлармы, юкмы?» дигән шөбһәләрен пыран-заран туздырып, эчкерсез, самими, гади бүлмәдәшләренә карап куанып торды Шәһрия. Менә кошчык та суыкта аңына килә алмый үлеп киткән булыр иде, терелде бит! Яши! Бер җылы караш, татлы сүз кирәк шул бәлагә таручыга.

Суынып өлгергән чәйләрне эчеп тормадылар, иртәнге ашка барыр вакыт җитте.

Ә кичен барысы да бүлмәгә җыелгач, Шәһрия кызларның кечкенәдән әби-бабай янында үсүләрен, шәһәрдә яшәүләрен белде. Кызлар берсенә ике, икенчесенә биш яшь чагында ук әтисез-әнисез калганнар. Бу юлламаны аларга институт биргән икән. Кызлар узыша-узыша институтта стипендия алып укуларын, һәр ел саен бушлай ял итүләрен, моннан тыш кием-салым алу өчен акчалата зур ярдәм алуларын сөйләделәр.

Шәһрия аларны тыңлаганда кабат уйга чумды. Калебенә яшьтән сеңгән матур гадәт кенә шулай сөйкемле итә ала кешене. Әби-бабай тәрбиясендә яхшыны яманнан аерып үскән бу кызларның телләрендә шуңа да җылы сүз, ә күңелләре мәрхәмәт белән тулы.

Бирсен Ходай! Гомер юлларында үзләре кебек үк мәрхәмәтле кешеләр очрасын, бәхетле булсыннар!

## *Изге Рамазан ае иде*

Без алты бала үстек, яныбызда һәрвакыт әби булды. Мәктәптән кайтуыбызга телеңне йотарлык итеп бәрәңгесен кыздырып куяр, кыстый-сыйлый ашатыр. Урамнан егылып, пычранып керсәк, чалбар-ыштаннарыбыз кипкәнче мич башында тотар. Кулындагы чебен «палкасы»ннан шүрләп утыра торгач, үзебез дә сизми йоклап китәрбез...

Елаганда юатучы, кечкенәдән эшкә өйрәтүче дә әбиебез булды. Без дүрт кыз белән ике малайга күз явын алырлык төсле ситсылардан матур-матур күлмәк-ыштаннар тегеп бирүче дә, ертык киемнәребезгә беркем сизмәслек итеп, җырлый-җырлый асыл ямаулар салучы да, җылы оек-бияләйләр бәйләүче дә бар эшкә өлгер яраткан әбиебез иде. Шуңа да балачакны искә төшергәндә, кечкенә буйлы, кулына дисбесен тотып намазлык өстендә утырган ак яулыклы әби күз алдына килә...

Алай гынамы? Тормышта да һәрвакыт янәшәмдә тоям мин аны, ул гел күзәтеп-кисәтеп тора кебек...

Көзге кич. Көндез күренгән кояш, көн үткәнгә үпкәләгән сыман, җылысын куенына яшергән. Әрсез җил җиң уемнарыннан, итәк асларыннан кереп җылы эзли. Салкыннан бөрешәсең дә адымнарны кызулый-кызулый өйгә ашыгасың. Шушы халәткә бирешмәскә тырышып, көзге үзгәрешләрне беренче күргәндәй күзәтеп, эштән кайтып киләм.

– Әни! Мин сине эзлим. Өйгә дә кереп чыктым, син кайтмагансың... – Миңа каршы килгән улымны танымадым. Үзе йөгереп арыган, ике бите уттай яна... – Әни, тизрәк әйдә әле, анда бер әби! Ул адашкан, әни!

Мин ни уйларга да белмәдем.

– Улым, зур шәһәрдә торабыз бит! Кем адашмас та, кем югалмас. Янында кешеләр бардыр, – дидем.

Аның йөзе кинәт агарып китте.

– Без дә булышмасак, ул туңып үлә, әни. Аның өстендә дә юк бит, бер нәзек кофточка гына. Менә үзең дә плащ кигәнсең бит.

– Киемнәре пычрак түгелме соң? – дидем мин тагын. Күз алдыма чүплектән шешә җыючы «салмыш түтәйләр» килеп басты.

– Нәрсә сорашып торасың инде, әйдә үзең күрерсең. Якын ич у-у-ул...

Киләсе елга паспорт алырга яше җиткән, инде балигъ булган улымның сузып торып елап җибәрүе хисләремнән айнытып җибәрде. Бәлки, чынлап та ярдәм кирәктер?

Ашыгып, улым күрсәткән якка киттек. Юк икән! Бөтенләй үк битараф түгел икән бит кешеләр.

Әбине чүп түгәргә чыккан берничә хатын юлның икенче ягыннан күзәтеп торалар иде. Без килеп җиткәч, шуларның берсе:

– Пошли, нашлась она, – диде дә, хатыннар төркеме ташпулатлар арасына кереп югалды.

– Картлык көнемдә үз аякларымда йөрт, зиһеннәремне алма, йә Раббым, – дип тели иде әби намаз укыган саен. – Яшәсен иде әле, дип сагынып торсыннар, сырхаусыз, җиңел үлемнәр бир, Раббым, – дия иде. Картлык шатлык түгел шул. Менә берәвең ярдәмгә мохтаҗ.

Бәләкәй буйлы, ап-ак матур йөзенә килешле итеп яшел яулык япкан әбине күргәч, йөрәгем кысылып куйды. Ул чынлап та адашкан иде. Йөзенә карап, сиксән тирәләре булыр, аксыл бизәкле күлмәк өстеннән яшькелт төстәге җиңелчә йон кофта кигән. Тик бу вакытта шулай җиңелчә киенеп ишегалдына гына чыгарга мөмкин шул. Ә ул инде байтак йөргән бугай, җыерчыкланып беткән бәләкәй куллары салкыннан комач кебек кызарганнар. Аягына ак йоннан бәйләнгән тула оек, чиккән кызыл чүәк кигән. Күз алдыма әбием килеп басты.

Кулларымны сузып, сак кына итеп әбинең иңнәренә кагылдым:

– Кая барасың, әби?

Әле генә елмаеп торган әби кинәт юк булды. Каршымда, учын кул өстенә куеп, аптыраулы карашы белән йөрәгемне урыныннан кузгаткан ят әбине күреп алдым.

– Белмим, – диде ул.

Үз әбиебез икән, татар карчыгы! Тик, нишләргә? Караңгы төшеп килә ич!

– Әни, әйдә өйгә алып кайтыйк, караңгы да төшә, – диде улым шатланып.

– Юк, улым! Песи баласы түгел бит ул, аның өе, балалары бардыр. Югалтып, борчылалардыр.

Ерак түгел элемтә бүлеге барын белә идем. Ябылып өлгергәнче шунда барырга кирәк. Мине кая алып барасыз дип тә сорамый безгә иярде әби. Ике ягыннан җитәкләп алдык та тротуардан атлыйбыз. Улым кош тоткан кебек канатланып бара. Ярдәм итә алдык дип сөенәме, балакайның шатлыгы эченә сыймый. Ә мин әкрен генә исем-фамилиясен, нинди йортта торуын сораштыра киләм.

– Кызым, Хәтирә минем исемем. Хәбиулла кызы мин. Гомер буе укытучы булып эшләдем.

– Кая эшләдең соң әби? Әлмәттәме? – дим, әбинең теле ачылуга сөенеп.

– Белмим бит мин, оныттым, кызым... – күзеннән яшь чыкмаса да, әби калтыранып шыңшып куйды. «Хәзер кая барыйк инде?..» диләр кебек иде аның моңсу күзләре.

Элемтә бүлегендә безгә милициягә хәбәр итәргә куштылар.

– Исем-фамилиясе бармы? – диделәр аннан.

Хәтирә Хәбиулла кызының адресын әйттеләр дә, телефон өзелде. Кабат шалтыратып та:

– Адрес сказали, больше не знаем, – диделәр.

Милициядән әйткән адрес белән килеп җиткәндә,

кояш ярыйсы ук баеп бара иде инде. Лифты да эшләми торган йортның җиденче катына әби, һич ялгансыз, бер авырсынмый менде. Тик, билгеле бер төймәгә басkач, аннан килеп чыккан егетнең:

– Здесь никакой бабушки не проживает, – дигәнен дә ишеткәч, егылып китә яздык.

Менә хәзер, чынлап та, кая барырга?

Баскычтан төшкәндә, әби тагын телгә килде.

– Иптәшем Рәшит белән бик матур яшәдек. Больницага алып киттеләр дә, менә аның хәлен белим дип чыккан идем. Ике кызыбыз, бер малаебыз... Рәис исемле...

Әби тагын ялгышып китте бугай, бер кулы белән баскыч култыксасына тотынды да кинәт көләргә тотынды. Улым – миңа, мин улыма карап аптырап калдык. Күз алдымнан олы бер тормыш юлы узды... Ни булды сиңа, дөнья? Ни булды сиңа, халкым? Нишләп бу хәлдә калды синең бер балаң?.. Моннан соң да күз яшьләремне тыеп кала алмадым. Әбине жәлләп тә, үзебезгә картлык килүен уйлап та акты яшем.

– Әни! Елама, әни! Үзебезгә алып кайтыйк.

Бала шул әле. Бүгенге, менә хәзерге кыйммәт аңа. Иртәгә мин – эшкә, ул укырга киткәч, әби өйдә кем белән калыр дип тә уйлый белми шул әле ул, нарасыйкаем! Менә шулай нечкә күңелле булып, бәлагә тарганны күреп, ярдәмче булып үсүең өчен рәхмәт, балам! Ходай үзеңне зурласын, бәбкәм!

Ары карап, бире багып аптырап торганда, көтмәгәндә милиция машинасы килеп чыкты. Без инде эштән кайтып баручы бер төркем халыкка хәлне якынча аңлатып өлгергән идек, машинаны алар туктаттылар. Бәхеткә каршы, милиционерларның киң күңелләре туры килде. Мөлаем егет кабинасын ачкач, утырыйм дип ишеккә тотынган әби кинәт миңа борылды да:

– Кызым, син бармыйсыңмыни? И Алла! Мин нишләрмен инде?.. – дип куйды.

Шул вакыт әбинең аягындагы тирән эчле галошларны күреп өнсез калдым. Тәнем эсселе-суыклы булып китте. Аның тула оегы да юк, колготки өстеннән зәңгәр носки кигән ич ул... Ә беренче күргәндә...

Милиционерлар безгә борчылмаска кушып, табарбыз, дип, әбине алып киттеләр.

Мин улымны җитәкләп өйгә таба атладым. Күңелемдә дә, күз алдымда да, һаман-һаман чиратлашып, тула оеклы чиккән чүәк белән зәңгәр носкилы галош пәйда булдылар. Изге Рамазан аенда үз әбием, күземә күренеп, «Булыш, балам, бу бәхетсез бәндәгә» дип әйтергә теләде микән?

## *Курәчәк күренеп килә*

Мәңмүрә карчык күңеленә, эчке сиземләвенә нык ышана. Кая барса да, нинди эшкә тотынса да кат-кат уйлый һәм фәкать калебе кушканны гына исәпкә алып хәл кыла. Дөресе шулай булса да, дүрт аяклы ат та абына дигәндәй, гомер ялгышуларсыз булмый. Андый чакта ул үз-үзен айлар буе битәрләп, борчылып йөри. «Әй, күңелем сизенгән иде аны!» дип уфтана.

Сиксәнне ваклап баручы Мәңмүрә түти ялгызы яши. Ире Әмәл сугышта бер аягын калдырып, инвалид булып кайтты. Озак яшәде, ахырга таба гел урын өстендә булды. Шөкер, соңгы юлга хәер-фатихасын биреп китте. Мәңмүрә ике бала өчен ана, идән-кер юучы, ашарга пешерүче генә булмады, ир-ат өстенә йөкләнелгән барлык авыр эшләрне үзе алып барды. Балалары үсә төшкәч, тормыш итүләре бераз җиңеләйсә дә, озак юана алмады. Армиядән сау-сәламәт кайткан улы, әзмәвердәй Флүсе, ерак Себер якларына эшкә китте дә... вакытсыз гүр иясе булды. Кызы Флүрәсе иртә кияүгә чыгып куйды. Үз тормышлары бик җитеш, әниләренә кунакка гына кайтып китәләр...

Авылның иң көчле хатыны дигән ярыш оештырылса, һичшиксез, Мәңмүрә карчыкка җиңүче «тәгәрмәче» тагылыр иде. Ник дигәндә, 50 килограммлы шикәр капчыкларын ул әле дә җилтерәтеп кенә ала, диләр. Ихатасындагы мунча, кое бураларын да үзе салган, дип тә сөйлиләр.

Ялгызлыгына да уфтанмый карчык. Кыш димәс, җәй димәс, иртән-иртүк капка төбенә чыгып утырыр, эшкә киткән-кайтканны хәерле көннәр теләп озатып калыр. Гайбәт сөйләмәс, һәркемгә яхшылык юрар. Яшьрәк чагында, иренең гариплеге аркасындамы, сынап карар өченме, әллә уңганлыгына кызыгыпмы, чит ирләр сүз кушкалаган, ди. Ул вакытларны әле дә кызык итеп сөйлиләр. Бер шундый «тәвәккәл»ен чак кына коега салмаган ул. Әй, бичара! Картайганчы бу урамга менәргә курыкты, диләр. Тик Мәңмүрә түтигә гомерлек кушаматны тагып калдырган. «Ата хатын» Мәңмүрә карчык үзе инде.

Мәңмүрә түтинең телевизоры юк. Күрше-мазарга керсә дә, «теге карубкыгызны сүндерегез әле!» дип кенә тора, әмма соңгы хәбәрләрне иң беренче булып ишетә. Көне-төне сөйләп торган иптәше – радиосы бар аның. Арып-талып эштән кайтучылар авыл хәлләрен аңардан ишетә икән, бер дә гаҗәп түгел. Алар иртән эшкә китә дә кич кайта бит.

Бу юлы да шулай булды.

Кыш иде. Ипигә дип кибеткә баргач ишетелде бу шомлы хәбәр. Күрше авылга борыла торган юл чатында, бер-берсенә сарылып кочаклашкан ике кыз гәүдәсен тапканнар. Юл чистартучы тракторчы күреп алган...

Мәңмүрә карчык егылып китә язды. «Йә Раббым!» – дип авыр сулап куйды ул. Аннан кибеттән чыгып ук китте. Чиратка баскан карчыклар бер-берсенә карашып куйдылар. Мәңмүрә түтинең кинәттән генә, саубуллашмый да чыгып китүенә аптырадылар.

– Яше дә байтак инде, нигә килгәнен дә онытты бугай...

– Соңгы араларда әллә нишләде әле ул... – дип көлештеләр.

Ә кибеттән уктай чыгып киткән карчыкның, дөресен әйткәндә, эче-тышына ут капкан иде...

...Яңа ел бәйрәмен клубта, утызынчы декабрьдә үткәрергә булдылар, чөнки утыз бере көнне һәр гаиләнең үз мәшәкате – баласы, туганы кайта дигәндәй... Күршесе Рузагөлнең:

– Әйдә, Мәңмүрә апа! Тотынышып барырбыз, арысаң, кайтып китәрбез, – дигәненә каршы тора алмады, ике күрше җитәкләшеп клубка төшеп киттеләр. Гомере буе яратты шул бәйрәмне Мәңмүрә түти. Яшьрәк чагында клуб идәннәрен дөбердәтеп биеп, Кыш бабайдан бүләген дә алып кайта иде. Картаелды, яшь чактагы егәрлекләр акрынлап таушалды, сиксән үзенекен итә шул инде.

Клуб гөр килә. Мәңмүрә әбиеңнең маска кигәннәргә карап исе китте. Элекке замандагы кебек тискәре тун гына кимиләр шул хәзер... Рузагөлне йөдәтеп бетерде:

– Монысы ни атлы, тегесе кем малае? – дип сорап теңкәсенә тиде.

Яңа ел бәйрәмен каршыларга килгән иң өлкән кунакка, Кыш бабай бүләге дип, олы чәчкәләр төшкән кашемир яулык бәйләттеләр. Беркөнне ипигә дип төшкәч, кибетче кызның кыстый-кыстый биргән лотерея билетына иң зур приз – шампан шәрабы чыкты әбигә...

– И-и, рәхмәт төшкерләре! Анысы миннән сезгә бүләк булсын, – дип, шешәне кулына да алмады карчык...

Кайтыр юлга чыктылар. Клуб эче яшьләр белән шыгрым тулы калды.

– Әй, яшьлек! Ару да юк бу балаларда, чатыр чабалар. Ә йөзләре кояштай яна, Ходайның рәхмәте! Узган ел да соңгы килүемдер дигән идем, шөкер, исән-сау монысын да каршыларга язды. Сиңа рәхмәт, Рузагөл! Кем мине шулай йөртер иде.

Клуб яныннан бераз киткәч, авыл уртасын икегә бүлеп уза торган юлны чыкканда, утларын сүндереп килүче машинаны күреп, алар сагаеп калдылар. Даң-доң, даң-доң!!! Көчле музыка астында әллә нинди сүгенгән тавышлар да ишетелде кебек. Кайта торган юлларыннан кире артка чигенделәр. Килеп җиткән машина бераз туктап торды да кинәт выжлап китеп барды…

Ялтырап ай чыккан, зыкы салкын төн иде ул. Бу суыкка бер дә туры килми торган җиңелчә курткадан ике кыз төшеп калган икән! Кулларында сумка-мазар да юк. Рузагөл, авыл кызларын таныйсы килепме, әбине кызулатты. Якын ук килделәр, ай яктысында кызларның йөзләре ялтырап күренә. Таныш түгелләр. Бәйрәмнән кайталар, ахры. Берсенең күзләре яхшы ук «майланган», йөзе дә янып, кызарып тора. Ә икенчесе нигәдер елый. Күзендәге сөрмә карасын, кулындагы ак мамык бияләе белән сөртептер инде, битен буяп бетергән. Анысы, апалардан оялып булса кирәк, йөзен читкә борды.

– Кая барасыз, кызлар, кемнәргә кайтасыз? – дип сорады Рузагөл.

– Нам в сторону Нурлат, – диде салмыш кыз.

– И-и, балакайлар! Нинди Норлат? Бу Әлмәт юлы бит! Төнлә ниткән машина булсын ди?

Икенче кыз елап ук җибәрде:

– Без Казаннан кайтабыз, апа. Бер юлчы машинага утырган идек, эчәргә кыстадылар. Мин эчмәдем. Әнә Лена алар белән каядыр барырга да риза булды хәтта. Сезне күреп, мин сикерәм дигәч кенә төшереп калдырдылар. Минем сумкам да алар машинасында китте.

– Ты, дура, сама виновата! Если б не ты! Не то бы было!

Рузагөл, кызларның дустанә сөйләшмәүләрен күреп, аларны тынычландырырга ашыкты:

– Сез, сеңлем, болай итеп юлда тарткалашып тормагыз. Юлда йөргәндә алай тарткалашырга ярамый ул.

Дуслашыгыз! Әнә клубка кереп җылынып чыгыгыз, барыгыз!

Шул вакыт сүзгә Мәңмүрә түти кушылды:

– Яисә әйдәгез безгә, иртәгә иртүк юлга чыгарсыз. Бигрәк салкын бит, балакайлар.

– Нет! Мы в город поедем. Это рядом. Там моя тетя живет!..

Тыңламадылар, кара төнне ярып, үрдән сызгырып төшкән машинага кул күтәрделәр дә утырып киттеләр кызлар. Әбиләрне күреп утырттымы шофер, әллә кызларны җәлләдеме?..

– И-и Раббым! Төн уртасы бит! Ничек кайтырлар инде? Берәүнең газизләре ич! Юк, аларны җибәрмәскә иде. Үзебезгә алып кына кайтырга, көч белән булса да, машинага утыртмаска иде. Тагын әллә кая алып китәрләр. Юньсезләр белән дөнья тулы. Тегесеннән аракы исе дә килә, җитмәсә, – дип әрнеп куйды Мәңмүрә әби.

– Әллә нинди кызлар алар, кем белә? Бәлки, юри төшереп калдырганнардыр, әнә янәдән утырып киттеләр бит! Әйтмәдек түгел, әйттек. Кемгә ышанып була хәзер? Хәсрәтләнмә, кайтырлар әле. Дөньяның нинди икәнен беләләр, автобуска утырсалар ни булган инде?

Юк, кайтып кергәч тә тынычлана алмады Мәңмүрә карчык. Күз алдында һаман шул ике кыз торды. Ничек кайтырлар? Бик юка да киенгәннәр, ичмасам...

«Күңелгә килгән иде лә! И-и, кулларыннан тотып алып кайткан булсамчы. Тыңламадылар. Әллә тагын, Рузагөл әйткәндәй, үзләре гаеплеме соң? Ниләр генә булды соң сезгә, балакайлар, ул кичтә? Кайларда гына, ниләр эшләп кенә йөрдегез?.. Нигә юлда калдыгыз, калага дип киткән идегез лә! Әй, балакайлар! Әти-әниләрегез нишли? Ходай төшкәненә сабырлык бирсен дә, төшмәгәнгә күрсәтмәсен инде!..»

Ә Рузагөл үзенчә кайгырды. Әбине тынычланды-

рыр өчен генә әйтте шул хәсрәтләнмә дип. Теге елап торган кыз аның күз алдыннан китмәде. Балакай ялгышкандыр, теге юньсезенә ияреп. Туңмасыннар гына инде…

Әй, шулай әрәм була инде кыз бала. Авылдан чыгып китә дә, әллә кем белән аралаша, әллә нәрсә эшләп йөри шунда. Әнә Тукран Әсхәтенең кызы, Бөгелмәдә матур гына укып йөргән җиреннән каникулга кайткач, үз-үзенә кул салмадымы? Балакай! «Әни, мин бүтән бармыйм анда», – дигәч, әтисе авызын да ачтырмаган: «Ни акчалар түләп керттем, авыл халкы алдында мине рисвайга калдырма, барасың!» – дип кырт кискән. Карга Раузасының кызын нишләттеләр?.. Рузагөлнең күңеленә бер-бер артлы шомлы хәлләр килеп кенә торды.

«Йә Раббым!.. Үземнең балалар да гел юлда. Ходаем, күрәчәкләр генә булмасын инде, үзең сакла берүк!» Рузагөл дә шундый уйлар белән йокыга китте…

Мәңмүрә карчык, сыкрана-сызлана, юлдан күзен алмый, эскәмиягә утырып, Рузагөлне көтте. Басып торып та, йөреп тә арыды. Төшке ашка сәгатьләп кенә кайткан халыкның, анда сугылып, монда кагылып йөрергә вакыты да юк, шуңа күрә күршесен үзе көтеп алырга булды.

…Әллә нигә хәле генә китеп тора менә. «Ничекләр итеп Рузагөлгә бу хәбәрне әйтми калыйм ди. Йә үтеп китәр, күрми калырмын. Мин дә, ул да гаепле монда! Өебезгә алып кайтып кундырган гына булсакчы! Алар яшь бит әле, Ходайга менә безнең кебекләрне алу кирәк иде ул», – дип җаны-тәне белән сызланып куйды…

…Алу кирәк… алу кирәк!

Ахшам намазына чакырып авыл өстенә азан яңгырады. «Алла-а-һу әкбәр-р! Алла-а-һу әкбәр-р!..»

Азан вакытына туры килеп, гомерендә кеше түгел,

чебенне дә рәнҗетмәгән авыл карчыгының теләге чыннан да кабул булдымы, әллә, кызлар өчен кайгырып, йөрәгенең бер кылы өзелдеме, утырган җирендә оеп кына китте әби…

Рузагөл кибеттә тоткарланып соң гына кайтып килгәндә, Мәңмүрә карчыкның тәне суынган иде инде…

## *Кунак ашы кара-каршы*

Нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләре бәйрәме якынлашкан саен, Рөстәм Шакировичның йөрәге тыеп була алмас дәрәҗәдә дулкынланып типте. Идарәдә эшләүче сеңлесе әйткән сөенчедән шатлыгы эченә сыймады аның. Картлык билгесе булып бераз бөгелә башлаган озын гәүдәсе тураеп, озынаеп киткәндәй булды.

– Ниһаять! Ниһаять, күрделәр бугай! Белделәр абзаларының инде егерме елдан артык шул оешмада чиләнгәнен. «Кулы алтын…», «Аннан башка беркем булдыралмый…» дип сөйләнәләр, «Алдынгы мастер» дигән булалар… Бәйрәм-мазар булса, исемемне дә атаганнары юк! – дип сөйләнде ул, үзе генә калган чакларында.

…Озак көттергән бәйрәм көне килеп җитте. Төштән соң бар халыкны оешманың актлар залына чакырдылар. Аны бәйрәмгә бу чаклы бизәгәннәрен күргәне булмады микәнни соң Рөстәм Шакировичның? «Күр әле син, ничек матур итеп ясаганнар! Шарлар белән әллә нинди сыннар әвәләп була икә-ән!» Шулай уйлый-уйлый бөтен бүлмәне күзе белән айкап чыкты оешмада егерме өч ел әйдәп баручы инженер булып эшләгән Мостафин.

Хәер, бәйрәмнәргә ул ничек тә калмаска, нинди сәбәп табып булса да анда катнашмаска тырыша иде шул.

Ә бүген Рөстәм Шакирович затлы костюм-чалбарын киде, ак күлмәге түшенә галстугын тагарга да онытмады. Май кояшы кебек елмаеп, залдагы урыннарның иң алгы рәтенә менеп кунаклады да әле артына, әле як-ягына каранып алды. «Менә күреп калыгыз, бу Рөстәм абзагыз булыр, бүләк тә алыр», – ди иде аның елмайган йөзе...

Көткән кешегә озак инде, директорның докладады су буе булды. Аннан алар, профком рәисе белән икәүләп, алдынгыларга мактау кәгазьләре, дипломнар тапшырдылар. Акчалата бүләкләр... Сәхнәгә менгән һәркемне зал алкышларга күмде. Әлбәттә, башлап кул чабучы да, алкышлар сүрелә башласа:

– Сыек, иптәшләр, әйдәгез тагын бер тапкыр алкышлыйк әле, – дип залны уятып торучы да Рөстәм Шакирович булды.

Профком рәисенең:

– Шуның белән тәбрикләүләр тәмам, иптәшләр, ун минут тәнәфестән соң Казан артистлары концертын карарсыз, – дигәнен ишетте дә, ишетмәде дә Мостафин. «Ничек? Мин... миңа кая?..» Ул як-ягына каранды, тик берәү дә аны күрми, барысы да тәнәфескә дип ишеккә юнәлгән иде...

Ни гарьлек!.. Ярый әле иптәшләренә мактанып өлгермәгән иде. «Алдан кычкырган карганың башы авырта» дигәнне ул яхшы белә. Шуңа да берәүгә дә сөйләмәгән иде. Сөйләвен сөйләмәде, әмма... диплом да, мактау кәгазе дә... юк бит!

Шулай булса да, халык өерен ера-ерта урамга ташланмады Рөстәм Шакирович, сабыр гына утырып торды. Күңеленең кайсыдыр бер җирендәге «Минем сеңелкәш монда юк бит! Ул алып кайтып киткәндер әле, минем җыелышларга йөрмәгәнне белә» дигән җылы тойгы тынычландыра иде аны. Аның әкрен генә торып чыгып киткәнен дә күрми калдылар.

Һәр бәйрәмгә килә торган туганнары бу юлы да чакырганны көтмәгәннәр. Табын түгәрәк, ул кайтканчы өстәл янына гына утырмый торганнар. Шаулаша-гөрләшә исәнләштеләр, хуҗаның кәефсез икәнен күрүче дә булмады. «Әйдә, уз, синең бәйрәм бүген» дип, аны табын түренә утырттылар. Керфек асларыннан сөзеп кенә хатынын, сеңлесен күзәтте Мостафин. Кәефләре шәп! Җитмәсә, күзләр очрашкан саен, ияк кагып, каш сикертеп алалар, янәсе, сабыр ит! Чишелә бугай төер, күкрәкне кысып торган начар уйлар тарала бугай...

– Ярый, сине генә көттек. Сүз сиңа! – диделәр.

– Бүген безнең бәйрәм инде... табынны ачык дип белдерәм. Хәл белешеп йөргәнегез өчен рәхмәт, сәламәт булыйк!

– Туктагыз, беренче тостны үзем әйтәм. Абыйга зур бүләк алып кайттым мин, – диде сеңлесе. – Менә тыңлагыз: «За многолетний и добросовестный труд дипломом первой степени награждается ведущий инженер Мустафин Рустем Шакирович!» диелгән. Абый, тәбрик итәм! Шуның өчен, әйдәгез!

Кул да чаптылар, бәллүр стаканнарны чыңлатып, чәкештереп тә эчтеләр. Тик Рөстәм Шакировичның хәлен генә күрүче булмады. Җыелыштан чыгып киткән сәгатьтән теткәләнгән йөрәге күкрәк читлегеннән сикереп чыгардай булып типте-типте дә... әллә бөтенләй туктадымы? Бөтен тәненә йокы килүгә охшаган тынычлык йөгертеп кул-аякларын камырга әйләндерде дә күз алларын караңгыга күмде...

– Рөстәм, Рөстәм, ач күзеңне! Нишләдең син? Нәрсә булды?!

Хатынының елау катыш куркып эндәшүләре аңга китерде Мостафинны. Күзен ачу белән, тирә-ягындагы хәлләргә хәйран булды: инде беркем дә көлми, барысы да, тынып, агарып-төссезләнеп киткән хуҗага карап катып калган иде. Күрше Гөлнараны күргәч кенә аңлады: табиб чакыртырлык булгач, булган икән монда хәлләр.

– Рөстәм абый, берүк тора күрмәгез, сезгә селкенергә ярамый! – дип тә кисәтте Гөлнара.

Ире күзен ачкач батыраеп киткән Хәдия:

– Барысы да әнә шул дипломнан китте. Гомер булмаганны, быел гына бирмәсләр... Сеңлең язды бит аны!.. Һәр бәйрәм саен кимсенеп йөргәнгә инде.

Шунда аңлады, диплом хатыны белән сеңлесенең кызык өчен уйлап чыгарган чираттагы уеннары гына икән! Буласы булган инде, ачуланмады. Ну уйнап та куйды соң сеңлесе! Моның кадәр дә хәтере калыр дип уйламады шул. Алдан әйтүе күңелен алгысыттымы, әллә инде олыгая бару үзен сиздердеме, чак кына дөнья белән хушлашмады бит!

Бәйрәм пешкән ашны утырып ашау белән тәмамланды. Кунаклар:

– Торып йөрмә, йөрәк белән уйнарга ярамый!

– Үзеңне сакла, борчылма! – дип, хуҗаны кисәтеп киттеләр.

Саубуллашканда, ишек катына чыккач:

– Уеныгызны әйтер идек инде...

– Шулай ярыймыни? – диделәр алар, хатыннарга шелтә белдереп.

...Мөмкинлек үзеннән-үзе килеп чыкты. Үзбәкстаннан апалары кунакка кайтып киттеләр. Авыл күчтәнәчләре – тәмле сөттән корт, атланмай, каклаган каз, тагын әллә ниләр куйганда, җизнәсе:

– Әй, без җимешне бик күп киптерәбез, кайтуга посылка ясап җибәрәбез, боерган булса! – дип өметләндереп киткән иде.

Менә бер ай булды инде, һәр көнне почта әрҗәсен капшый хатыны. Сеңлесе дә җиңел генә җимеш ашамакчы, эштән кайта да:

– Посылка килмәдеме, апа? – дип, почта буенда йөреп алҗыган җиңгәсен йөдәтә.

Боларны күреп торган Рөстәм Шакирович: «Кунак ашы кара-каршы, бәбкәләрем, мин сезнең уеныгызны

күрсәтәм! Белерсез абзагызның кем икәнен!» – дип мыек сыпыра.

Беркөнне инде посылкадан бөтенләй өмет өзгән Хәдия шатлыгыннан егылып китә язды. Почтальон кыз алдында да кыен, кибеткә ипигә чыгарга да ояла башлаган иде ич! Авызында сүз тормый, башта күршегә, аннан кешегә дигәндәй, кемне күрә шуңа мактанып та өлгерде, ичмаса. Менә шатлык! Посылка килгән! Почта әрҗәсендәге гәҗитләр арасыннан килеп төшкән кош теле хәтле «алхәбәр» кәгазен алып чыгып та китте... һәм алып та кайтты. Бәләкәй буйлы, чандыр гәүдәле Хәдияне кайчакта Рөстәм Шакирович «Ярка хәтле весың юк!» дип үчекләп куя. Унбиш килолап булыр, зур ак капчыкны ничек күтәрә алды микән?

Төшке ашка кайткан Мостафин сеңлесе Люциягә күз кысып куйды. Янәсе, килгән бит! Сөенегез!

Шыплап тутырган посылканы ачкач, аерым кәгазьләргә төрелгән төенчекләрне күреп, ике хатын да егылып китә язды.

– Чуерташ?!

– Ник?

– Ничек?

– Мин... мин берьялгызым күтәреп кайттым, исәнлегем дә шуның кадәр генә... Ник болай мыскыллыйсыгыз инде, кайсыгыз?

– Сигезенче март белән сезне, бәбкәләрем! – диде Мостафин.

– И-и, абый инде!..

Өстәл артында тыныч кына тавык шулпасы чөмергән Рөстәм Шакирович, аларның бер агарган, бер кызарган йөзләрен күргәч, рәхәтләнеп елмаеп:

– Өйрәнә торыгыз, бәбкәләрем, мондый хәлләр кабатланыр әле, кунак ашы кара-каршы була ул! – дип тә өстәп куйды.

## *Бака*

Үземнең биш яшьлек чагымны хәтерлим. Бабай (әтиемнең әтисе), мәрхүм, табынга чәй эчәргә утырган саен, бакчага бөтнеккә чыгара иде:

– Шушы кызымнан да тыңлаучанрагы юк. Үзе уңган, үзе җитез! Аны күрми дә каласың, бер аягы тегендә, берсе монда булыр, – дигәч, ничек чыкмыйсың инде. Бер-бер артлы үсеп килүче дүрт кыз туган арасыннан мине генә шулай мактый бит ул! Алмагач төбенә яшел хәтфә кебек җәелеп үскән бөтнекне җыюын җыям, әмма иртәнге чыкка рәхәтләнеп, юеш үлән арасында сикереп йөргән берәр бака килеп чыкса, бетте инде, өйдәгеләр чыгып алганчы елыйм. Әйтерсең менә хәзер аягыма бер бака сикерер дә ябышып калыр кебек. Дөрес, соңрак, үсә төшкәч, аягыма балтырлы резин итекләр киеп чыга торган булдым. Әби әйтә торган иде:

– Әй, кызым, бакадан курыкмасын дип, бабаң махсус сине чыгара иде, тәки өйрәнә алмадың.

Бакадан курыкканга күрәдер, гомеремдә дә су кермәдем. Бакча артыбыздан бик матур елга ага иде. Тирә-күрше кызлары шунда коенырга төшәләр, ә мин, аларның күлмәк-ыштаннарын тотып, су буенда утырам. Билгеле, тал төбендә түгел инде, ачыклыкта, басма өстендә. Анда да, бака менә алмасын диптер инде, әбинең кызыл эчле тирән галошын чирәм арасында югалтып кайтканчы гына утырдым. Ул су буйлары башкача истә калмаган. Гел ялт-йолт карап, бака эзләгәнем хәтердә. Мин ул бака дигән җанвардан әле дә, хәтта телевизордан күрсәм дә куркам. Тәннәрем чымыр-чымыр итә дә, әллә тагын, аякларым үзләреннән-үзләре җирдән аерылып киткәндәй булалар.

Бәләкәй чакта өйрәнмәгәч, йөзә дә белмим бит инде. Комсомол путевкасы белән чит илгә ял итәргә баргач, «казлар җәяүләп йөрерлек» бассейнда бата яздым хәтта! Суны урталай бүлеп торган кызыл тасманы калын тор-

ба дип белгәнмен. Анда хәтле ничек тә йөзәм дә шунда тотынып калам, янәсе. Таш бәйләгән кебек, су төбенә киттем! Егерме дүрт көн буе миннән көлделәр. Көлмәслекмени? Программада һәр көнне суда йөзү, бассейннарга йөрү каралган бит!.. Аягымны чылатып кайтудан ары уза алмадым...

Бакадан курыкканымны сыйныфташларым да белә, күрше Сибгат абзый малае, күчерергә рөхсәт итмәсәм:

– Кызый, мәктәптән кайтканда буадан чыгасың бар, – дип кенә куя.

Инде ярыйсы ук зур кыз булгач, әбием әйткәндәй, борынга егетләр исе керә башлагач, кичен озата килгән егеткә:

– Ярый, керим инде, сау бул, – дисәм, ул да:

– Зифа, ә син беләсеңме минем кесәмдә ни барын?.. – дигән була.

Монысы әле капка төбендә. Ә клубта кино булган көнне – зур хәсрәт! Күпме генә олы юл аша әйләнеп кайтырга тырышсам да, егетемнең батыр булып күренәсе килгәнгәме, буа аркылы кайтабыз. Ә төнлә буа өстенә судагы бөтен бака менеп утыра. Басып тыңласаң, ерактан килгән кешене сизеп, шап-шоп суга сикергәннәре ишетелә аларның. Анда инде чирәм арасында йөрүче кечкентәйләр генә түгел, ай яктысында ерактан ук ялтырап күренгән ап-ак олы корсаклы, өскә калкып торган яман зур күзлеләре...

Шушы буа төбендә, төнге авылны яңгыратып, берничә тапкыр әче итеп кычкырам да әле мин. Аяк астындагы ташлар да бака булып тоела бит!.. Егетем бер-ике тапкыр басма аша чыгып күрсәткәч, тәмам бүтән бака калмаганына ышангач кына, горур атлап, мин чыгам.

Менә шулай бакадан куркып үстем. Бәрәңгене бакчадан рәхәтләнеп җыйсам да, алырга дип базга да, идән астына да төшкәнем булмады, чөнки анда да бака бар ич! Ниндие әле – гөберлесе! Килен булып төшкәннең икенче көнендә каенанамның:

– Кызым, бәрәңге алып бирсәң, мин каршы алыр идем, – дип җылы итеп эндәшүенә эреп китепме, әллә бакадан курыкканымны белдерәсем килмәгәндерме, бәрәңгегә төштем. Базга! Чиләкне күз ачып йомганчы тутырдым үзем, ләкин башта бәрәңгене бирмичә менеп булмый бит, баз тирән! Җитмәсә, каршы алырмын дигән каенанамнан да җилләр исте. И-и, ул курку дигәнеңне! Бакалар менә-менә миңа килеп ябышырлар кебек! Әй кычкырам:

– Миңлегөл апа!.. Миңлегөл апа!..

Бераздан ни күрим: алдый төшсәң, зурлыгы урыс бияләе хәтле бардыр, тиресе дә крокодил тиресе кебек шакмакланып, сырланып-сырланып тора торганы, мин әлегә хәтле күргәннәрнең дә иң зурысы, чиләгем янына ук килеп баскан да, күзләрен мелт-мелт китереп, миңа карап тора. Әллә тагын алгы аякларын күтәрә үк төште инде?! Йә Ходай!.. Сикерә бит! Йөрәгем кеп-кечкенә калды, туктады да бугай...

– Әни-и-и!!! – дип үзәк өзгеч тавыш белән кычкырып та җибәрдем.

– Әллә кайчан шулай диләр аны, – ди каенанам, көлә-көлә чиләгемне алганда.

Килен булып килгәнемә ике көн, ә мин аңа бер тапкыр да «әни» димәгәнмен. Нишләсен инде, чарасын тапкан! Тик, әни дияргә өйрәтәм дип бакалар янында тотмаска иде инде мине! Ят җир, ят урын дигәндәй. Мин оялам да ич әле! Әни дигәне дә ят кебек... Шөкер, гомер буе әни дип яшәдем үзем! Ә теге «бака» дигәнем бәрәңге алырга төшкәч кияр өчен куелган бияләй булган бит! Баскычтан төшкәндә, ялгыш бәрелеп, мин аны җиргә төшергәнмен. Курыкканга куш күренә шул!

Алтыдагы – алтмышта, дигәннәр борынгылар. Тик мин, әбиебезнең Ташкент якларыннан кайткан туганы сөйләгән шушы риваятьне ишеткәндә, алты түгел, дүрт яшьләр тирәсендә генә булсам да, аны бер дә онытмыйча хәтеремдә саклаганмын.

Имеш, шундый бакалар бар икән! Кеше тәненә ябышып, тырнаклары белән тамыр җибәрәләр дә, кисеп тә, тунап та алып булмый ди үзләрен! Кеше ашаган ризык белән тукланып яшиләр, ди...

Ике әбинең дә бер-берсенә карашып, күзләр кысышып, безне су буена барудан туктатыр өчен генә сөйләгән шушы уйдырмалары, бака күргән саен исемә төшеп, тәннәремне чымырдатмыйча калмый. Әбиләрем күптән гүр ияләре инде. Авыр туфраклары жиңел булсын! Догаларым барып ирешсен үзләренә, амин!

Курыксам да, язгы җылы көннәрдә, аеруча кичке эңгердә бакалар «сайрашканын» ләззәтләнеп тыңларга яратам. Үзара сөйләшә, аралашалар ич алар. Үзләренә күрә бер тереклек дөньясы бит! Авыл кызы булып су янында яшәсәм дә, мин аларны аңлый гына алмадым...

## *Сусылу*

Сусылу килеп җиткәндә, елга яны гөж килеп тора иде. Авыл фельдшеры Гамир Остазаров Мирһадиның җансыз гәүдәсенә ясалма сулыш алдыру белән мәшгуль.

«Ничек инде?.. Ник?..» Шушы уй миен ярып узды Сусылуның. Иртәгә... иртәгә аларның туе булачак иде...

Тау башына килеп туктаган машинадан төшкән укытучы кызны күреп, авыл халкы тамаша көтә башлады. Хәзер ул Мирһадиның үле гәүдәсенә капланырга һәм «Нигә мине калдырып киттең?» дип еларга тиеш.

Әмма Сусылу сабыр итә дә, түзә дә белә. Үзенең кыска гына гомерендә аз күрдемени ул хәсрәтне? Су дигән олы дәрья бигрәкләр дә «ярата» бит аны...

Тик сабыр итүнең дә бер чиге була, күрәсең. Мирһади гәүдәсе янына якын килә барган саен, Сусылу аяк баскан җир убыла барды...

– Әни, канатым!..

* * *

Күзләрен ачып, янында шәфкать туташын күргәч кенә, ул үзенең хастаханәдә икәнен аңлады.

Бала чагын искә төшерә башласа, күз алдына ап-ак чәчле, ак яулыклы әбисе килеп баса Сусылуның. Дөньяда яши башлавының беренче сәгатендә үк әнисез калды ул. Ак әбисе күз алдында пәйда була да тагын югала. Балачакның иң матур мизгелләре әбисе янында узды да соң, әмма ул иң кирәк чакта китеп тә барды шул. Әбисе якты дөньядан ахирәткә күчкәндә, аңа унике генә тула иде...

И балачак! Озын ак күлмәген киеп, намазлык өстендә утыручы картәенә – әбисенә – абыйсы Әмир белән бергәләп бер тынгы да бирмәделәр алар. Сәҗдәгә киткәнен генә көтеп торалар да, икәүләшеп аны артыннан төртеп тә җибәрәләр. Намазлыгы аша сикереп уйнасыннармы? Куллары, авызлары белән ямьсез ишарәләр ясап үртәсеннәрме?.. Ә картәй, керфеген дә күтәрми укуын белә. Уйныйлар, көләләр дә, намазы беткәнче шым булалар. И-и, аның сабырлыклары! Юк, ачуланмый, ялгыш та каты итеп кычкырмый иде. Мәрхүмә картәен искә төшергәндә, күз алдында гел шушы мизгелләр яңара Сусылуның.

«Табынга утырганда бисмилла әйтмәсәң, авызыңа шайтан керә!», «Йокларга ятканда дога укымасаң, төнеңне саташып чыгасың!», «Дога укып битеңне сыпырсаң, күз тими!..» дип, тормышта адым саен кирәк догаларны һәм тагын бик күп матур гадәтләрне әбисе өйрәтеп калдырды аларга. Юлга чыкса, яңа эш башласа, «Аллага тапшырдым!», уңышларга сөенсә, «Әлхәмдүлилләһ!» дип куюы, билгеле, әбисенең сүзләре. Йөзен хәтерли алмаса да, берәмтекләп күңеленә салган догаларын да, «Акыллы, ярдәмле, яхшы булыгыз!» дип, изге эшкә өндәгән сүзләрен дә онытканы юк Сусылуның. Киресенчә, үсә барган саен күбрәк кызыксынды ул карт әнисе

яшәгән дөнья кануннары белән. Картәе акыллы, бик укымышлы кеше иде шул. Аңа төрле җирләрдән авырулар килә, ул аларга сөлек сала, фал китабы өстендә таш тәгәрәтеп дәвалый. Кыскасы, авылга бер остабикә иде. Вафаты алдыннан әбисе: «Кызым, мин китәм инде... Син зур кыз хәзер, абыеңны ач йөртмә, киемнәрен чиста тот!.. Дога укы, кызым! Алла бар ул! Иншалла, ярдәменнән ташламас...» – дигән иде.

Сусылу шулай эшләде дә. Күрше Хәдичә абыстайга йөреп гарәп телен өйрәнде. Баштарак сүрәләрне, аннан Коръәнне укып чыкты! Кабат-кабат укып, догалар ятлады. Кечкенә чагыннан калебенә сеңгән гадәте, болгавыр заманда адашып калмас өчен, туры юлдан тайпылдырмый алып баручы юлдаш та булды үзенә.

Кыз бала тыйнак булырга тиешлеген дә белә Сусылу. Баткак суда бергәләп тачка* тәгәрәткәндә абыйсы бер генә әйтте:

– Кит инде, син – кыз кеше, курчак белән генә уйнарга тиешсең. Зуррак үскәч, өй җыештыру, идән юу, кер юу, тагын да үсә төшкәч, синең эшең кияүгә чыгып, бәби карау, – диде.

Кызыгын тапмадымы, курчак белән уйный алмады Сусылу. Гел абыйсы янәшәсендә, күбрәк малайлар арасында булды. Сабыр, түзем булырга да малайлардан өйрәнде. Тормышка бик ярады: әбисе киңәшләрен дә тотып, абыйсы белән якын дус, сердәшләр дә булып, тормыш баскычларыннан үзенчә, абынмый-сөртенми барырга тырышты.

Әмма кеше язмышлары туганда ук языла, диләр. Яши-яши онытылды дигәндә генә, Сусылуның йөрәген әрнетерлек хәлләр һаман кабатланып тора. Менә тагын су...

---

* *Тачка* – таяк башына кигертелгән кечкенә тәгәрмәч.

Ничек онытты соң ул әбисенең беренче тапкыр чишмә яки су буена килсәң, Су атасы Сөләйманга һәм Су анасы Сылубикәгә дип, су читенә хәер куярга кирәк дигән акыллы киңәшләрен?..

...Яңа гына мәктәпне тәмамлаган иде, баксаң, гомер узып та бара икән!

Авыл мәктәбендә укыта Сусылу. Казан дәүләт университетының филология факультетын тәмамлап, авылга кайтуына да биш ел тула. Ничек кенә «Авылда, абый янында мин» дип, шатлана-сөенә йөрсә дә, тормышның үз кануннары шул, абыйсының үз тормышы...

* * *

Сусылу, Сусылу,
Уем сөйгәнең булу... –

дип җырлый-җырлый килеп керә иде аларга абыйсы Әмир белән бер сыйныфта укучы Фәһим. Бәләкәйрәк чагында Сусылу аны абыйсы кебек якын, үз итсә, үсә барган саен, Фәһимнең күзләрендәге серлелек, аның озак итеп текәлеп карап торулары кызны оялтып кына калмый, ә сагайта да, уйландыра да башлады.

– Иртә әле сиңа, кызый, егетләр турында уйларга. Борыныңны сөрт тә, дәресеңне кара, – ди иде абыйсы, дусты белән сеңлесенең карашларын күреп алганда.

Мәктәпне тәмамлап, институтка киткәнче, Сусылу абыйсыннан башка клуб ишегенең кайсы якка ачылганын белмәде. Ул аны кирәксенмәде дә, чөнки иртә «үскән» кызларның көндәлек-дәфтәрләрендә «өчле»дән зур билге булмады. Алар укымадылар. Дәрестә чыш-пыш сөйләшеп, запискалар язышып, уйнап утыралар да, кыңгырау шалтырагач, күрми дә каласың – чыгып чабалар.

Үзе кебек үк әбиле гаиләдә тәрбияләнгән Фәһимнең

сеңлесе Фәнүзә белән генә уртак иде аның сере. Берберсе белән киңәшләшеп, хәтта бераз ярышып та укыды кызлар. Озын толымлы, оялчан Фәнүзә – Сусылуны, ә Сусылу Фәнүзәне тулыландырган кебек, гел янәшә булдылар. Алар икәү булганда гына кыю кызларга әвереләләр, бергә чакта гына аларның тапкырлыгы күпләрне хәйран калдыра. Мәктәптә дә бергә, өй эшләрен дә бергә эшләп үсте кызлар. Уйнаганда да абыйлары яныннан ерак китмиләр иде.

Соңрак Фәһим Сусылуга, юк-бар бәйрәмнәрне дә сылтау итеп, бүләкләр бирә башлады. Кыз егеткә һушын җуеп гашыйк булмады. Хисләр тирәнгә үк кереп китмәсен дип читләште, әмма күз алдында аның мөлаем сурәтен йөртте.

...Абыйсы белән Фәһимнең техникумда укып йөргән чаклары. Кичтән соң гына авылга кайтып төшteләр алар. Атна үткәне ай кебек сизелсә дә, тезгенне нык тотты Сусылу, ничә чакырса да, Фәһим янына чыкмады. Иртән Сусылу беренче дәрес беткәнен түземсезләнеп көтте һәм дус кызына:

– Фәнүзә, сиңа әйтми кемгә әйтим, тыңлыйсыңмы? – диде.

– Тыңлыйм, сөйлә.

– Сиңа Фәһим бер сүз дә әйтмәдеме?

– Әйтмәде, балтасы суга төшкән кебек тик йөри.

– Кичә килгән иде, мин чыкмадым.

– Ну и җүләр! Шулай кыланып йөрсәң, колак кагарыңны көт тә тор!..

– Абый да, ник сөйләшмисең, яхшы малай ул, ди башлады инде.

– Берәү атып алыр, берәү карап калыр дигәндәй, сизми дә каласың, белеп тор. Миләүшә шалтыратып йөдәтеп бетерә.

Тыштан белдерергә тырышмаса да, эчендәге борчуын яшерә алмады Сусылу, әллә нишләп китте:

– Поши кызымы?

– Ну!

Сусылу дустын тыңлады, үзенчә эшләде. «Яратса килер, яратмаса, өлгерермен әле, егетләр бетмәгән», – дип уйлады. Ә Фәһим барыбер килде. Аның:

– Сусылу, мин сине сагынып кайтам, ә син сөйләшмисең дә!.. – диюе кызны елмаерга мәҗбүр итте.

Көзен абыйсын да, Фәһимне дә армиягә алдылар. Сусылуга хат артыннан хат язды, фоторәсемнәрен җибәрде Фәһим. Хатларының берсендә: «Абзагыз су асты көймәсендә Тын океан төпләрен айкый, хезмәт итүләре кызык», – дип язган иде... Язган иде шул...

Кайтырына өч ай калгач, Фәһим югалды. Хәрби укулар вакытында юкка чыкты. Гәүдәсен дә таба алмадылар. Сусылу инде беркайчан да Фәһимнең: «Сусылу, Сусылу, уем сөйгәнең булу...» – дип шаярта алмавын күз алдына китерә дә, аның үлеменә ышана да алмады. Көтте, ул көтмәгәндә генә кайтыр кебек тоела иде...

* * *

Еллар үтте. Бөтен барлыгын укуга багышлаган Сусылуга Салават исемле башкорт егете гашыйк булды. Аудиториядә укыганда да, китапханәнең уку залларына барса да, ул кызга тынгылык бирмәде. Гел янәшәсендә йөргән егеткә Сусылу үзе дә сизмичә якынайды, үткәннәрен онытырга тырышты. Кышкы сессияләр беткәч, Салават аны туганнары янына алып кайтты. Инсафлы, акыллы Сусылуны егетнең әти-әнисе дә, туганнары да якын итте. Очрашудан бик канәгать кайткан яшьләрнең арасы күрелмәс җепләр белән тартылып бәйләнә, якыная барды. Хәзер инде күп вакытны бергә үткәрә, сессияләргә бергә әзерләнә башладылар. Салаватның телендә гел бер сүз:

– Җәйгә син минеке булачаксың, өйләнешәбез, гөрләтеп туй үткәрәбез...

Ә җәй көне...

Кулга дипломнар алгач, курсташлары белән табигатькә чыктылар. Җылы, кояшлы көн иде. Төрлесе төрле якка таралысы егет-кызларның бөтен игътибары яшьләрдә булды. Бер-бер артлы тостлар әйтелде:

– Матур яшәгез!..

– Бәхетле булыгыз!..

– Туегызга чакырыгыз!..

Аннан егетләр су коенырга төшеп китте, кызлар учак янында мәш килделәр.

Сусылу искиткеч шат. Кайчандыр ул, мин аны гына ярата алам, миңа башка беркем дә кирәк түгел дип, Фәһимне онита алмый йөргән булса, хәзер үз хисләренең тезгенен тыя алмый, Салаватка тартыла, тизрәк аның хатыны булу теләге белән яна. Әниләрен дә бер күрүгә үз итте бит. Бала чагы авыр үткән, ата-ана назы күрми үскән кызның иренең куенына кереп сыенасы, аның көчле, назлы кулларыннан назланасы килә иде…

Үз уйларыннан үзе оялып утырган кызны тирә-якта булган тавыш айнытып җибәрде.

– Тизрәк ясалма сулыш ясагыз!..

– Юк, пульсы юк…

Сусылу аңына килгәндә, Салаватны җирләгәннәр иде инде…

* * *

Кулга диплом алган сөенечле көн аның тормышына икенче кайгы мөһерен сукты. Хыяллары челпәрәмә килеп, бар өмете сүнде Сусылуның. Ярый янәшәсендә абыйсы булды. Аның сүзен санлап, киңәшен тыңлап, авылга кайтты ул. Кайтты да башы-аягы белән эшкә чумды. Бөтен барлыгын балаларга, укучыларына багышлады. Ике ел дигәндә, аның җаны-тәне белән эшенә тугрылыклы зат икәнен белеп алдылар. Хезмәтен күреп алган роно җитәкчеләре мәктәпкә директор итеп куйдылар.

Менә өченче ел инде Саранлы урта мәктәбе районда алдынгы урыннардан төшми. Директорның тырышлыгын авыл җитәкчеләре дә бердәм күтәреп алды. Нинди йомыш белән килсә дә, борып җибәрмәделәр, кирәк-ярагын да бирделәр, ремонтын да ясадылар. Һәрдаим иртәнге киңәшмә вакытына барырга күнеккән Сусылу Мирһади белән дә шунда танышты.

Озак еллар агроном булып эшләгән Ризван Хатимович лаеклы ялга киткәч, аның урынына районнан яңа белгеч килеп төште. Килү белән, җиң сызганып эшкә дә тотынды. Һәр басуга чәчелгән культураның исемен, җисемен таякчыкларга майлы буяу белән яздырыр өчен мәктәп балалары янына килә бу. Килә дә, нинди дә булса сәбәп табып, директор янына керә.

Мирһади Зиевичның болай әрсезләнеп йөрүләрен ошатмаса да, Сусылу аны күрүдән ниндидер ямь таба иде. Каенлы районында туган егетнең атаклы көрәшче, менә ничә ел инде Сабантуй батыры икәнен дә белгәч, кызыксынуы артты гына. Җитмәсә, совхоз директоры да, кызны күргән саен:

– Егетне кулдан ычкындырмаска иде, бик булдыклы күренә. Андыйларны бит район бик тиз «үстерә», китеп тә барыр. Әйдә, Сусылу Чибәркәевна, өмет сездә, – дип кабатлап кына тора.

Ул гына да түгел, Мирһади күршедә генә, Хәдичә абыстайлар өендә яши. Сусылуның йорт тирәсенә чыгуын күрде исә, атылып ишегалдына чыга:

– Туташ, әйдә үзем су тартып* бирим әле!

Йә булмаса:

– Коймагыз аварга тора ич, кадак-чүкеч бирсәгез... – ди һәм, әллә нинди сәбәпләр табып, Сусылуга сүз кушарга гына тора.

Тагын күпме шулай йөргән булыр иде Сусылу, абый-

---

* *Су тарту* – коедан су алу.

сы белән булган сөйләшү киләчәккә корган уйларын үзгәртте дә куйды. Ерак-ерактан уратып йөрмәде абыйсы, турыдан әйтте дә салды:

– Сүз кушуларын да, сиңа битараф түгел икәнен дә күреп, белеп торам. Озак уйларга вакытың юк, сеңлем! Сөйләшеп утырдым, төпле күренә. Әнә совхоз коттедж төзи үзенә, китә калса да югала торган түгел. Яшең дә бар бит инде, көтәр кешең дә юк! Хәзер яратмасаң, торабара яратырсың. Тормыш яраттыра ул, тәвәккәллегең, уңганлыгың бар. Синең ялгыз булуың миңа да рәхәт түгел. Бөтен уемда син! Дөнья хәлен белеп булмый, мин дә мәңгелек түгел. Кемең бар, кемең кала?.. Бүген кич тагын киләм! – диде.

Абыйсы килде. Алар Мирһадины икәүләшеп каршы алдылар. Җылы сөйләшү булды ул, абыйсы да сөенеп китте, үзләре дә зур өметләр баглаганнар иде... Тагын су алды...

## *Сары яулык*

Исеңдәме, яшьтәш, дисәләр,
Күзләр зәңгәрләнә төшәләр...

*И.Юзеев*

Ике зур сумка тотырып эштән кайтып килүче Наилә подъезд төбендәге утыргычта аңа карап елмаеп торган ир-атка игътибар да итмәде. Үзенең олы юбилей кичәсенә әзерләнеп, мәшәкатьләнеп йөргән чагы. Илле бише тула. Күзенә ак-кара күренми. Кунаклар күп булачак, бергә эшләгән хезмәттәшләре, дуслары, туганнары җыела. Борчыла, болай зурдан кубып кунак төшергәне булмады шул. Туган көн бәйрәмен гомумән яратмый, төче сүзләр, чәчәкләр...

Туган көне дә кайсысы микән әле аның? Илле икенче елның җиденче апрелеме, әллә сиксәненче елның унын-

чы октябреме?.. Әфганстанда узган биш ел, анда үткәргән көннәр... Наиләнең чем-кара чәчләре көмеш төсенә кереп кайтты, исәнлеге дә ташка үлчим генә. Яшь хирург кыз солдатларның яраларын бәйләп кенә калмады, операциясен дә ясады, бик күпләрне үлемнән дә алып калды. Утыз өченче частьтагы котычкыч хәлне искә төшергәндә, әле дә чәчләре үрә тора, тәннәре чымырдап китә.

Бер кичне егерме җиде солдат китерделәр, ярым үле, ярым тере иделәр алар. Кычкырып кына түгел, улый-улый елады Наилә. Үзенең аларны үлем тырнагыннан йолып кала алмау көчсезлегеннән дә, сөлек кебек сылу ир-атларның – кемнәрнеңдер газиз баласы, ире, якыны, сөйгәненең – яшәүгә өмете юклыгына инанып та елады... Ыңгырашып, саташып кычкыруларга ямьсез сүгенүләр кушылып, ярдәмгә ашыккан шәфкать туташларын аяктан екты. Иртәгә авыр яралыларны район үзәгенә алып китәргә тиешләр. Авырту-газапларын беразга гына тынычландырып, беренче ярдәм күрсәттеләр дә бит... Ял итеп алырга дип башлары мендәргә тигәндә, таң яктырып килә иде инде.

...Подвалда ярдәм көтеп алты тәүлек ятты Наиләләр. Бәхеткә каршымы, исән калуларына бер сәбәп булдымы, медикаментлар саклана торган кечкенә бүлмәгә, идән астына төшкән кызлар «үлем йокысы»на чумып, өстәге хәлләрне сизми калдылар.

Янгын күз ачып йомганчы лазаретны чолгап алган. Беркем белми калган, беркем ярдәм итә алмаган, яралылар ярдәм сорап акыра-кычкыра тереләй янганнар.

Наиләләр ябылып калган бүлмәнең чыгу люгын ачып булмаганлыктан, бөтен өметләре Бөек көчнең кодрәтендә иде. Караңгы «баз»да ике литр спирттан кала бер эчемлек тә юк, кая ул берәр төрле ризык, кабымлык турында хыяллану?! Аннан аларның исән икәнлеген бишенче көнне торба шакылдаткан тавыштан гына белделәр. Ике шәфкать туташын да аңсыз килеш табып алды-

лар. Наиләнең чәче шунда агарды. Үлеп тереләделәр бит!

...Подъезд ишегеннән кереп, икенче катка күтәрелгәч, кемдер җиңеннән тартты кебек, Наилә, үзе дә сизмәстән, почта әрҗәсе янында басып калды. Юкка гына тукталмаган икән, ниндидер конверт бар. Почта әрҗәсенең ачкычы кая соң? Ул ашыга-кабалана сумкасын капшарга керешге. Һаман-һаман югалып торганга гәҗит-журналларны почтадан барып ала иде, ә бүген? Бүген аны ниндидер сәер бер көч туктатты!

Нинди хат бу?.. Кайчан килгән?..

Бер кулы белән азаплана торгач, Наилә сумка төбеннән ачкычын табып алды. Тимер капкачны ачып җибәрүе булды, хат, дулкын өстендә йөзгән йомычка кебек як-якка чайкалып, таш идәнгә килеп төште. Конверт тышына зур итеп «Наиләгә!» дигән язу күренеп калды. Иелеп алмакчы иде: мөһере дә, кире адресы да юк! Әфганда үткән еллар үзенекен итте. Һәр адымны, һәр хәрәкәтне сак кына кылырга күнегелгән. Шикләнде, конвертны алмады.

«Нәрсә бу? Кемнән?»

Наилә аптырады, нишләргә белмәде. Урлаганда тотылган кеше сыман, як-ягына каранды. «Тугыз катлы йорт, лифты дөбер-шатыр эшләп тора, кем кермәс тә, кем чыкмас, фамилиясе дә язылмаган! Дустан дошман күп дигәндәй, конверт кына димә! Әнә почта белән килмәдемени кеше үтерә торган порошоклар? «Наиләгә!» диярләр ул! Мин генәмени Наилә? Фамилиясе дә юк, кешенекедер?!» Башына тагын әллә нинди уйлар килде.

Хат, яшен вакытында аяк астына килеп төшкән утлы шар кебек, Наиләнең котын алып, таш идәндә ята бирде.

«Чү, лифт ачылды!»

– И Марат, син икәнсең, сумкаларымны подъезд идәненә куясым килмәгән иде, шушы конвертны гына алып бирче, зинһар?

– Шәһәргә киләләр дә кеше булалар, кем икәнлек-

ләрен оныталар, – дип мыгырданды соңгы айларда бик сирәк айнык күренгән Марат, идәндә яткан хатны алып Наиләгә сузганда. Аннары ул, нидер сөйләнә-сөйләнә, калтыранган куллары белән ачкыч тишеген көчкә табып, өенә кереп китте.

– Рәхмәт, зур үс! – диде хатын, шаяру катыш, күршесенең тупаслыгына исе китмичә. Белә бит ул аның бар дөньяга нигә ачулы икәнен... Юк, усал да, явыз да түгел Марат. Беркөнне, һич уйламаганда, ике яшьлек малаен ияртеп, хатыны ташлап китте аны. Монысы барып алмый, тегесе кайтмый хәзер. Яхшы ук салгалап йөри торгач, гел айнымаска әйләнде... Менә шулай бала ятим кала, ә ир-ат? Ир-ат... әрәм була. Кулындагы конвертны да онытып, әнә шулай әрнеп калды Наилә күршесе Марат артыннан.

Кабаланып хатның адресын, мөһерен барлады, әмма хат тышында чыннан да «Наиләгә!» диелгән һәм кечкенә хәрефләр белән «Наилдән» дип тә язылган.

«Наил?! Ничек?.. Каян?..» Наилә сискәнеп китте. «Ни гомер бит!..»

Яшен тизлегедәй күз алдыннан мәктәп еллары... бала чагы, яшьлеге йөгереп узды. Бу мизгел шулчаклы тиз булды ки, аның кан тамырлары буйлап кайнар кан таралды да, аңын яктыртып, Наиләнең уйларын бала чагына алып китте.

...Әнә алсу күлмәк кигән Наилә ялантәпи яшел чирәмнән атлый. Янәшәдә сыйныфташы Наил аның туфлиләрен тоткан... Алар, сөйләшә-сөйләшә, соңгы кыңгырау кичәсеннән кайталар...

Ачкыч тота алмаслык булып калтыранган куллары Наиләгә янә күршесе Маратны исенә төшерде. «Мин бит... мин айнык бит! Ә нигә минем кулларым калтырый? Нишлим мин? Наил? Кая син? Үз кулларың белән китердеңме хатыңны? Нигә адрессыз ул?»

Ишеген ачып өй эченә узган Наилә сумкаларын урнаштырып та, өстен салып та тормады, хатны ачарга

кереште. Ерак яшьлеккә алып киткән ап-ак конверт, очкыннар чәчеп торган утлы күмер кебек, кулны өтә иде... Аның эчендә хат түгел, ә ниндидер кабарынкы әйбер икәне кулга сизелеп тора. Наилә, кипкән иреннәре белән «Наил, Наил?!» ди-ди, аптырый-каушый, конвертны ачып җибәрде. Наиләнең күзләре тагын да зуррак булып ачылдылар, ул:

– Ә-ә-ә?! – дип кычкырып җибәрде.

Кояш төсле җете сарыга әфлисун төсендәге көзге яфраклар төшкән... капрон яулык! Ул конверт эченнән шуып кына төште дә, «Ниһаять, күрештек!» дип кочаклап алган сыман, Наиләнең аягы астына сузылып ятты. Үзенең барлыгын сиздереп, каты итеп, йөрәге урталай киселдеме, әллә еракта, яшьлек ярларында калган үз яртысын кабат китереп ялгап куйдылармы аңа, ул әллә нишләде. Наилә, иелеп, ефәк яулыкны алды да, хәле китеп, ишек катына чүкте.

...Җиденче март көне иде. Җиде чакрым араны күрше авылга йөреп укыйлар Наиләләр. Иртәнге автобус соңарып килгәнгә, дәресләр әллә кайчан башланган, мәктәптә тынлык хөкем сөрә. Йөгерүдән сулуларына капкан кызлар-малайлар, шыбыр-шыбыр килеп, сыйныфларга таралыштылар. 10 нчы «б»да усаллыгы белән бөтен мәктәптә дан тоткан тарих укытучысы Мәрьям апалары икән.

– Керегез, әйдә, керегез әле! Шыбырдашмый гына утырышыгыз! – диде, мыш-мыш борын тарткан укучыларга сөзеп карап, Мәрьям Соруровна. – Сорап карыйм әле мин сездә-ә-ән! – дип тә өстәде. Өсләрендәге салкын да сүрелеп өлгермәгән укучыларның башлары парта астына ук сеңде.

– Фәхриева, әйдә син сөйлә!

«Бетте баш!» – яшен тизлегендәге уй миен ярып узды Наиләнең. – «Нәрсә уттек соң әле без кичә, кичтән нәрсә укыдым соң мин?..»

Укымыйча дәрескә килгәне юк та соң, фикерләре

таралган чак бит! Ишектән килеп кергәч тә, Наилнең матур карашын күреп югалып калды ул. Сыйныфка берәү булган чибәр егеткә кызлар сыланырга гына тора, ә Наиләнең, аны әлегә кадәр ошатып йөрсә дә, керфек астындагы шомырт күзләрен тутырып, Наилгә карарга батырчылык иткәне юк. Егетнең карашы кызның аякларын хәлсез, үзен аңсыз итте ләса! Ул Наиләгә текәлеп карап елмайды да, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, ниндидер ишарә дә ясаган булды бит.

Мәрьям апа Наиләнең фикерләрен җыеп сөйли башлаганын көтеп тә, аңа ялынып та тормады, кискен итеп:

– Ишектән кергәндә үк, күзеңне туздырып, Хәмәдъяровка карадың. Онытылырсың да шул! Кая, нәрсә ымлады ул, нәрсә качырасыз анда? – диде.

Укытучы ашыга-ашыга кыз янына килде дә Наиләне этеп диярлек парта астына тыгылды... Аннан дүрткә бөкләнгән «Социалистик Татарстан» гәҗитен тартып чыгарды.

– Ә-ә-ә, һм-м-м! – диде Мәрьям Соруровна сузып кына. – Молодец, Хәмәдъяров! Менә ничек икә-ән! Үзең бер авыз сүз дә сөйли алмадың, Наиләгә соңгы хәбәрләрне гәҗите белән үк алып килгәнсең. Гыйшыкмыйшык дисез инде алайса?

Укучылар шым булды.

Әйе шул! Мәрьям апалары гәҗиттә басылган соңгы хәбәрләрне туплап, аларны укып килергә кушкан иде...

Укытучы, олы бер ачыш ясагандай, эре-эре атлап такта янына килде дә, кулындагы гәҗитен селки-селки:

– Аны укып килергә иде... – диде.

Шулчак озак көттергән кыңгырау шалтырады, ләкин берәү дә урыннан торып китәргә базмады, барысының да күзләре гәҗит эченнән җилфердәп төшеп, идәндә яткан сары яулыкта иде... Сыйныф беравык тын торды да кинәт шыбырдаша, чыш-пыш сөйләшә башлады.

– Тынычланыгыз! Утырыгыз барыгыз да, беркем беркая китми! Йә, Наилә, чыгып ал яулыгыңны! Ал, ал!

Бүләк ич, әнә нинди матур, кояш үзе бүлмәгә төшкән диярсең!

Иренмәде укытучы апа, яулыкны бөгелеп идәннән алды да, бар зурлыгына туздырып, сыйныф алдына селкеде. Оятыннан помидор кебек кызарган Наилә ни дияргә белмәде. Нәрсә бу? Кемнеке? Бер сыйныфташларына, бер укытучыга карап аптырады... Укучыларның бу хәлгә бик исләре китмәде, чөнки Наилнең күрше партадагы кыздан дәресләр буе күзен алмавын алар күптән беләләр, ә менә «дәрес хуҗасы» бөтен сыйныфны «пленга» алды. Дәвамы ничек булыр иде, әмма Наил барысын да үз урынына утыртты.

– Мәрьям апа! Сез дөрес аңламадыгыз. Ул минем гәҗит, тик яулыкны мин... әнигә алган идем, бәйрәм бүләге ул.

Аз сүзле Наилне бөтен сыйныф яклап чыкты:

– Мәрьям апа! Хәзер кызлар яулык бәйләми инде...

– Иртәгә 8 Март бит, әнисенә алды ул аны...

«Социалистик Татарстан» гәҗитенә кыстырылган сары кояш-яулыкны ул көннән соң сөйләүче дә, искә алучы да булмады. Оялчан Наил күрше авылның зифа буйлы, озын керфекләре арасыннан төймәләр булып күренеп торган шомырт кара күзле, икегә бүлеп үрелгән озын толымлы чая кызы Наиләгә бер авыз сүз дәшә алмый мәктәпне тәмамлады.

...Наилә сары кояш-яулыкны алып, битләренә, иреннәренә тидерде. Ерак балачак, мәктәп елларына әйләнде дә кайтты, әйләнде дә кайтты. Күз алдына туткыллы йөзле, кара бөдрә чәчле, төз гәүдәле һәм һәрвакыт моңлы карашлы Наил килеп басты.

«И Наил! Белмәдең... белми калдың шул син ул чакта ук инде чая кызның сине ничек яратканын! Гомер буе саф, бөредә килеш саклады бит ул сиңа булган тәүге мәхәббәтен. Синең армиядән өйләнеп кайтканыңны белгәч тә, аннан аерылышканыгызны ишеткәч тә өметен өзмәде. Менә марҗа белән тора дип ишеткәч

кенә, көнделегеннән сызып ташлаган иде. Ни булды соң? Син кайда, Наил?! Ничә ел бит!»

...Аз сүзле Наил дәресләр буе Наиләне күзәтеп утыра, әмма тәнәфестә ләм-мим сүз эндәшми. Кышкы буран, ачы суыкларда Наилә апаларында куна калса, сүзсез генә яныннан сумкасын тотып озата бара. Башка берәүдән дә озаттырмый. Менә шушы йомыкый «аю Наиле»н яратты Наилә. Биш ел институтта укыганда да сүз кушучыларга, егетем бар, дип кенә әйтте. Чибәр дә, тәкәббер дә син, диючеләргә дә җавабы бер булды – тәкәббер түгелне эзләгез! Ә Әфганда, ут эчендә, ир-ат затына булган мәхәббәте көчле дуслыкка әверелеп кенә калды... Искиткеч кырыс холыклы, каты куллы ир-атлар янәшәсендә үзе дә шул төркем кешесенә әйләнде бугай ул. «Якын дус»тан ары бара алмый үтте гомере.

Менә Наил?! Наил дус кына түгел шул. Наилә аны гомере буе яратты, көтте. Ир-ат сыйфатларын үзенә сыендырып, түзәргә, еламаска да өйрәнде, тормышның ачысын-төчесен дә байтак күргәнгә, сабыр була да белде. Бүген, менә әле хәзер, ни булды соң аңа?

Кулына ак конверт кочкан Наилә кабат яшьлегенә, мәктәп елларына кайтты.

...Чыгарылыш кичәсенә дип әнисе аңа, бер казга алмаштырып, каладан алсу күлмәк алып кайтты. Сылу тәненә сыланып торган өрфия күлмәкне кигән Наилә, бу кичәдә яңа сусылланып пешкән җиләкне хәтерләтте. Аның күлмәге башкаларның күз явын алса, үзен тагын да чибәрләтте. Әлегә кадәр бер сүз кушарга оялган Наилгә ни булгандыр, ул Наилә яныннан бер адым да читкә китмәде, күзеннән күзен алмады. Алар гел икәү биеделәр. Атлап түгел, очып йөрде Наилә. Таң каршыларга авыл башына чыккач, «сиңа суык бит» дип, Наил пинжәген кызның иңнәренә салды. Шул минутта куллар кулга тиде, күзләр очрашты. Нинди суык булсын ди, утлы учакта көйде Наилә, янды, пеште. Бу халәтне алар икесе генә белделәр. Таң кызыл-

лыгында Наилнең каратутлы бите дә кызарып тулышты хәтта.

Биш ел саен шушы җирдә очрашып торырбыз, дип сүзләр куешып, таралыштылар. Җитәкләшеп өйгә кайтып җиткәч, «иң кайнары» капка төбендә булды. Наил саубуллашырга дип кулын сузган кызны «әх» дигәнче кочагына алды да... Үбү булдымы ул, гомерендә бер тапкыр да әнисенең пәп итүеннән кала башканы белмәгән кыз аңлый алмый калды, Наилдән җилләр исте. Уку йортларына таралышканчы күрешергә куешкан сүзләр тормышка ашмады. Әтисез үскән малайның ике авыл арасында йөрергә матае булмадымы, әллә авыл егетләре туктатып кисәттеләрме, күрешә алмадылар. Наилә әзерлек курсларына Казанга китеп барды, аннан институтка укырга керде. Наил белән хатлар аша да табыша алмадылар.

«Наил! Кайда син? Ничек сакладың син бу яулыкны?..»

Наиләнең ерак үткәнгә киткән уйларын бүлеп, ишектә кыңгырау шалтырады. Сары яулыгын тоткан килеш, дулкынланудан кем икәнен сорарга да онытып ишекне ачып җибәрүе булды, тагын аһ итте Наилә. Бер кочак сары розалар тотып, күршесе Марат басып тора иде.

– Да! «Святыня» да уянды бугай, ахыр заман җитә, диләр, шулдыр, шулдыр, – дип мыгырданды ул, кулындагы чәчкәләрне аптыраган Наиләгә сузып. – Менә, мадам! Сезгә бирергә куштылар! Әллә ашыга, әллә ояла. Һм-м! – Марат тамагын кырып куйды.

– Кем иде ул, Марат?

Наилә баскычтан аска йөгерде. Менә хәзер, менә шушы минутта чыкмый калса, бик үкенер, гомер буе үзен гафу итә алмас, бик якын кешесен югалтыр кебек тоелды аңа. Бер кулына сары яулык, икенчесенә сары чәчкәләр тотып, Наилә подъезд ишегеннән урамга атылып килеп чыкты. Чыгып та басты, баскан урынында катып та калды. Ишегалдында аңа карап, елмаеп чал чәчле Наил басып тора иде...

## *Кызыл диплом*

Укыдыңмы, дисезме? Укыдым! Ничек кенә укыдым әле мин! Укып бетереп, кеше булганчы юлымда яхшы кешеләр генә очрады минем. Кайсына нәрсә бирсәм, шуны алдылар. Әллә ниләр уйлап башыгызны ватмагыз! Нинди җавап бирсәм, шуңа риза булдылар, дию-ем. Нинди рәхмәт әйтсәм, шуны кабул иттеләр... Һм... Да! Менә шул хакта сөйләмәкче булам да.

Бер-бер артлы үсеп килүче дүрт кызның иң кечесе мин булам. Мәктәпне тәмамлагач, дәлше укырга җибәрмәделәр мине. Әтиемнең: «Син дә китсәң, әниеңә кем булышыр», – дию җитте дә куйды. Аннан, искиткеч чибәрмен, бар яктан да килгәнмен мин. Ә матурларга егет-җилән бик бәйләнүчән була, шуңа авылда әниләр янында калырга булдым. Менә вакыт-вакыт көзге каршына киләм дә, үземнең матурлыгыма шаклар катам инде. Иң беренче күзем муеныма төшә. Әмма мин аны табалмыйм, юк ул миндә. Тиз генә артка борылырга кирәк булса, бөтен гәүдәне эшкә җигәргә кирәк. Аннары чәчләр, алар – искиткеч! Үзе сирәк, үзе йомшак, яңа чыккан бәбкә йоны кебек инде менә. Тарыйсың-тарыйсың, туза гына бара. Шуңа сирәк тарыйм. Кечкенә почык борын, кояшта аеруча ялтырап китә торган ак керфекләр арасыннан кирәксә-кирәкмәсә дә елмаеп караучы ике карлыгандай күз, тар гына маңгай һәм һич җыелмас авыз! И, ул минем ябылып та бетми бугай. Кечкенә чакта шул авыз аркасында күргәннәрем! Тешләрем чыга башлау белән, апам интектерергә тотынды:

– Авызың зур булу гына бер хәл, сөбханалла, тешләрең, савковый көрәкмени!

Авызым җыелды. Кыскасы, көлгәндә авызымны кулым белән тота башладым.

Балалыктан үсмер чакка күчүем дә кызык булды минем. Ник дисәң, төртсәң күз, тагын сүз инде. Ун яшьләр чамасы булгандыр, ындыр артындагы чишмәгә

суга барам. Әни яңа тегеп биргән, зәңгәр кыр чәчәкләре төшкән ак сатин күлмәгемнән күземне дә алмый атлыйм.

– Трр-р, малкай, нәрсә кызлар өстенә менәсең?!

Көянтә-чиләкләремә менә бәреләм дигәндә, ат туктады. И курыкканнарым! Атлап китәргә өлгермәдем, ат хуҗасының:

– Да-а, Рәшидә апаның бу кызын да каз тешләгән икән! – дигәнен ишетеп калдым.

Чишмәгә барып җиткәнче аягымны, кулларымны карап «каным калмады». Кайткач та, әллә ертыкмы икән дип, әйләндереп-әйләндереп күлмәгемне капшадым әле.

Тагын шул апам күземне ачты:

– И җүләр, шуны да аңламадыңмы? Ул бит синең күкрәкләреңне әйткән, – дип котымны алды.

Кая да булса чыгарга, кибеткәме, сугамы барырга кирәк булса, кат-кат кофта киям, янәсе, кеше сизәрлек булмасын. Ә алар, Ходайның рәхмәте, ай үсәсен көн үсә, зурайганнан-зурая гына баралар. Өч апаның да, зуррак күренсен дип, күкрәк савытлары эченә мамык тутырганнарын күреп кенә бераз тынычландым. Шөкер, минекеләр кем күрсә дә оялмаслык булып үстеләр үзләре. Һм-м, һм! Матурмындыр инде, шулай булмаса...

Әти председатель, гел атта йөри. Җәен тарантаста, кышын чанада. Сирәк кенә булса да атны кәнүшнәгә мин илтәм. Кышын бик йөртмиләр, чөнки суыкта кыз баланы үзен генә җибәрәселәре килми.

Ул чакта җәй иде. Әти кичен эштән кайтты да:

– Бар әле, кызым, атны тугарып кайт, – диде.

И сөенә-сөенә киттем. Күз алдыгызга килгәндер инде, чит-читләрен сырлап-бизәкләп ясаган, талдан үрелгән тарантас һәм шунда шырпы кебек нәзек мин утырган. Кәнүшнәнең кайсы яктан ачылганын аксак Гомәр абзый тиз оныттырды.

– И-и, Хәйретдин абзыйның бу кызы бигрәк матур икә-ән! Бер бочка сыворотка белән йотарсың, билләһи! – диде.

Ишеткән мәлдә, сөенечтән аякларым калтырап, баскан җирем уйнаклап киткәндәй булды. Тагын берәрсе ишетте микән дип, як-ягыма каранып алдым. Урамнан күрше Өммегөлсем узганда, әниләрнең «Бигрәк матур инде бу сабый, бер кашык су белән йотарлык!» дигәннәрен ишеткәнем бар анысы. Әмма монда «бер бочка сыворотка белән» ди бит. Сывороткасы да бит әле аның комбинатта сөтне эшкәртеп, аертып, каймагын, эремчеген алганнан калган яшел су гына. Үзе әче, үзе кү-үп бит! Юк, бүтән бармадым кәнүшнәгә. Апаларга да сөйләмәдем, үсә төшкән идем инде, анысын гына аңладым.

Авыл – уч төбе, диләрме әле, менә шулай тирә-күршеләрдән, бигрәк тә апамнан төртмәле сүзләр ишетеп үсә торгач, үзем дә хәйран гына җор телле, чая кыз булып җиткәнмен. Егетләр күзе төшәрлек үк булганмын. Артымнан өерләре белән кайталар һәм күрше Өммегөлсемне, Җарияне, бездән ары яшәүче кызларны озата китәләр. Шулайдыр инде, сагындыра торганнардыр, чөнки алар авылга атнага бер генә кайталар бит. Калада училищеда укыйлар.

Мин дә киттем бит укырга. Институтның филология факультетына үзем имтихан биреп, үзем кердем! Икесен «дүртле»гә, берсен «бишле»гә бирдем! И, көтәм теге институт тәрәзәсенәябыштырылачак кәгазьне. Беләсезме, пүртәнкә буйлы исемлекне керфегемне дә селкетмичә укып чыктым. Үз фамилиямне дә шунда күргәчме? И, генәләрем! Күзләрем шакмак булды! Авызым кипте, телем әйләнмәс булды. Торатаашлар гына булып каттым, билләһи! Керә алуыма, һәм бернинди блатсыз керә алуыма хәйраннар калдым инде. Ышануы читен, әмма хак! Ну, шуннан соң бик күпләр: «Рәшидәнең кәкре сыйрагы да укый әнә!» дип, кызларын ачу-

лана-ачулана укырга җибәрә башлады. Мин, әлбәттә, андый сүзләргә үпкәләмим, киресенчә, аякларымны турырак итеп басып, төзрәк атларга, яхшылабрак укырга тырышам. Ә менә беренче зачетлар, имтиханнар башлангач, эшләр кирегә китте дә куйды.

* * *

Гарәп теленнән зачет бара. Сөйлим, язган булам.

– Ым, һымм! – дип, тыңлаган булып утыра профессор.

Юк, бирә алмадым. И, үкерепләр елап кайттым инде. Фатир хуҗасы Бибинур апа миннән көлде генә.

– И балакай, елап утырма, иртә белән нәрсә булса да уйларбыз, яме. Тынычлан, бүтән дәресләреңне кара да ят, – диде.

Әнием башымнан сыйпап, баллап чәйләр эчерткән кебек булды, изрәпләр йокыга киткәнмен. Иртән шул зур авыз янында көчкә генә күренеп торган борынымны иркәләгән тәмле искә уянып киттем.

Бибинур апа тумышы белән Азнакай ягыннан, теле ягымлы, әйткән сүзе – күңелгә май.

– Менә, апаем, әйдә, чәйләп ал да шушы якмышларны*...

– О! Ә безнең якта «кәкәш» бу! – дидем мин, шатлыгымнан кулларымны чәбәкләп.

– Сездә мәзәгрәк сөйләшәләр шул.

Бибинур апа сумкама зур төргәк салды.

– Әйдә, озын-озак сөйләнеп утырма, укуың башланганчы йөгер. Укытучы абыеңа кертеп чык шул якмышларны.

Өстәл өстендә зур тәлинкә белән алсуланып кабарынган, мине ал да, мине ал, дип күзне кызыктырып

---

* *Якмыш* – кыстыбый.

утырган якмышларның берсен авызыма, берсен кулыма алдым да, дәресләр башланганчы барып җитим дип чыгып сыздым!

Институтка!

* * *

Аяк астында кыштыр-кыштыр килгән яфракларны, күзгә матурлыкны барлый-юллый, таң белән ап-ак булып төшкән кырауны ярып, юл салып урамнан атлыйм. Анда-санда урам җыештыручылар күренгәләп, куркак җанымны шик-шөбһәдән аралый. Сумкамны яхшы ук кабартып торган олы төргәктә әле кая һәм ни өчен юлга чыкканнарын бер генә дә күз алдына китерә алмаган «кәкәшләр». Алар минем кулымны, тәнемне, бөтен күңелемне җылыта баралар. Менә бүгенге өметем йолдызлары, һәм «эшем» барып чыга калган очракта, киләчәк көннәргә якты кояш кебек тә булып, җанымны иркәләүчеләр...

Институт вахтасында кулын артына куеп басып торучы сакчы абый мине күргәч аптырап калды:

– Че так рано?

– Э-э... это, мне надо, компитр надо!

– Странно!

Сорау алучы абый җилкәләрен сикертеп аптырап торган арада, пуля кебек икенче катка атылдым. Ул минем кай якка киткәнемне күрми дә калды. Шулайдыр инде, странныйдыр, сүз дә юк. Йомышым төшмәсә, мин әле бу вакытта төшләр күреп йоклап ятар идем. Бибинур апа кат-кат, тор инде, апаем, соңга каласың, дия-дия генә уятты үземне. Йокы чүлмәге мин!

* * *

Профессор Илморад Бәйрәмович олы яшьтә. Бик тыйнак, искиткеч зәвыклы укытучы. Ап-ак бөдрә чәч, кабарынып торган калын ирен, елмайганда чак кына

күренеп китә торган энҗе тешләр. Аңардан ниндидер җылылык бөркелә, күз карашлары да елмаеп иркәлиләр кебек. Яшь чагында нинди булды микән ул? Ә менә нигә ялгыз булуы әлегә һәркем өчен сер. Институтның бер бүлмәсендә яши. Үзе төрек булса да, бик матур итеп татарча сөйләшә. Дәрестән тыш вакытларда аны бөтенләй күреп булмый, үз бүлмәсенә керә дә бикләнә.

Кулымдагы кәкәшләрне тотып Илморад Бәйрәмовичның ишек төбендә, әле теге, әле бу якка атлый-атлый, әйтер сүзләремне кабатлыйм: «Бибинур апа бирде...»

Юк, озак уйланып торып булмый. Бер-бер артлы укытучылар, студентлар килер. Ә минем аның бүлмәсеннән чыкканны күрсәләр? Менә шунысы куркыныч та инде аның. Кеше күрмәскә тиеш!

Тоткасына кулым тиеп өлгермәде, ямьсез чинап, чыелдап, шәрран каерылып, ишек ачылып китте. «И Аллам! Йоклаплар гына ята торган булса, нишләрмен?»

– Кто там, войдите!

Күзләремне чытырдатып йомып, эчкә уздым. Берне атладым микән, икенеме, туктадым һәм кинәнеп киттем. Шикләнеп, әллә ниләр уйлап бетергәннәрем юкка чыкты. Эш өстәле артында күзлек астыннан сөзеп, миңа карап, укытучым утыра иде.

– Хәерле иртә... э... Ни, исәнмесез?!

Минем кычкырып әйтә башлаган сүзләрем әллә кая югала бардылар да бөтенләй ишетелмәс булдылар.

– Хәерле иртә! Ни булды?

Мин шатлыгымнан олы төргәкне өстәл өстенә ничек китереп куйганымны сизми дә калдым.

– Менә Сезгә...

Профессор минем балалыгымны аңлап алдымы, өстәл артыннан торып минем якка чыкты.

– И, нәрсә инде бу?

– Кәкәш, Сезгә!

Укытучымның йөзе үзгәреп, чырае сытылган кебек булды.

– Какаш?

Мин профессор да Бибинур апа кебек үк әйтәдер дип, дөресләмәкче булдым.

– Юк, якмыш!

– Какмыш?.. Ну-ка, открой!

Билгеле, ачып тормадым, укытучым күзен сирпеп ачканчы бүлмәдән юк та булдым. Миңа бик тә оят тоелды. Ничек итеп профессор бүлмәсенә килеп кердем соң мин? Бибинур апа гына, ул гына мине оятка калдырды! Яхшылык эшлим дип, көлке ясады. Хәзер ничек институтка барыйм да, ничек Илморад Бәйрәмовичның күзенә күреним ди.

Бу атнаның соңгы көне иде, без ул көнне күрешмәдек.

Ял көннәренә авылга кайткач, әниемә барысын да сөйләп бирдем.

– И кызым, бер дә куркып торма, әнә бер казны ал да кит! Аннан баш тартмас, отмиткаңны да куйдырырсың... – диде әни.

Иртәнге ике дәрес тә Бәйрәмычныкы. Мин алты килолы каз салынган сумкамны аудиториягә алып кереп, аяк астыма куйдым! Була, Алла боерса! Бүген куйдырам!

Бәхетсезлек аяк астында, диюләре шул буладыр. Тәнәфестә тагын ике пар шул дәресне укыячагыбыз турында әйттеләр. «Ничек? Ә каз нишли?» Минем чәч төпләремә җитмеш инә тыктылар диярсең. Беренче партада утыруымның әйбәтлекләре! Укытучымның күзләренә карыйм да аска күрсәтәм, карыйм да аска...

Ниһаять, аңлады бугай. Өстәл артыннан чыгып яныма килде.

– Хәмитова, үзегез генә чыга аласызмы? – дип сорады.

– Әйе, чыгам.

«Ул аннары чыгадыр инде, башкалар сизмәсен дип!»

Өстәл астыннан сумкамны алып чыгып барганда, шып туктап калдым. Каз эрегән! Профессор утырган

өстәлгә таба буй-буй булып аккан канны күреп һушым китте.

– Вам плохо? Әйдәгез!

Шушы дәрес буе уйнап утырган күзләрем янә укытучымның карашы белән очрашмасын өчен алтын тутырылган әрҗәләр генә бирер идем, җир ярылса, кереп кенә китәр идем...

Ишегалдында туктап тормадык. Аудиториядән кызлар чыгып, мине җитәкләп медпунктка кертеп калдырдылар. Табиб сау-сәламәтме икәнлегемне шактый озак тикшергәннән соң, казымны күтәреп кайтып киттем.

Институтка бүтән бармам инде дигән шик-шөбһәләремне тагын Бибинур апа туздырды.

– Бар, кайт та фермага төшәрсең! Авылга синең кебекләр бик кирәк анда. Нәрсәгә укып торасың? Укымыйча да дуңгыз карап була ич! Кеше институтка керә алмый азаплана, ә син кайтып китәм, дисең. Бар! Кайт!

Минем гадәтне белмәгәннәр генә чамаламый. Кайт, дисәләр, кайтмыйм инде мин, анысы – точно!

Икенче көнне, берни булмагандай, башны тилегә салып, институтка киттем. Профессорга карамаскарак тырыштым инде. Ике пар дәрес озаклады озаклавын, әмма үтте. Башымны бөгеп, күзләремне аяк астыма гына текәп чыгып барганда, кинәт:

– Хәмитова, зачеткагызны алып минем янга килегез әле! – димәсенме.

Аһ! Бетте баш! Ни дип җавап бирермен. Ә кәкәшләр турында сүз башласа...

– Хәмитова, кая, бир әле зачетканы?!

– Э... и, Илморад Бәйрәмович! Мин сөйлимме? Беләм!

Минем дулкынлануым йөземә чыккандыр, югыйсә башка вакытта профессор гел утырып кына тора иде. Бүген өстәл артыннан үзе чыгып, каршыма килеп үк басты. Кулымнан иләп кенә зачеткамны алды... Өстәлгә иелеп нидер язды. Шул мизгел эчендә минем

күргәннәремне сөйләп аңлатып була торган түгел. Беренчедән шундый «ялгышлык» эшләгәннән соң аның янында басып торуы үзе бер «тәмуг» булса, икенчедән, нәрсә яза икән ул минем кенәгәмә дип утта яндым…

Ниһаять, профессор минем тарафка борылды:

– Это за какаш, и каз тоже!

Сез минем урында булсагыз нишләр идегез?

Мин кенәгәмне учыма кысып чыгып йөгердем.

…«Каз эше»н Бибинур апа тәмамлаган булып чыкты.

Мондый маҗаралар байтак кабатланды әле. Институтны тәмамлаган елны минем кулымда сумкам булмаса да, «зачет» әзер иде. «Кичке бүлеккә күч», «Читтән торып укы» дия иде укытучылар. Миннән тәмам туюлары булгандырмы, жәлләүләре идеме, аңламамышка салышкан булып укып бетердем.

Укыдым мин. Очно! Кызыл диплом алып чыкты апагыз!

## *Ул чакта да…*

Көтү куарга дип капканы ачкан Илсөя чүт егылып китмәде. Ялгыш күрәмдер дип уйлап, сыер саугач юарга өлгермәгән куллары белән күзләрен каплады. Кычкырып җибәргәнен кеше-кара ишетә күрмәсен дипме, баш яулыгын алып авызына капты һәм каты итеп тешләде. Кысудан кашемир яулыкның җепләре өзелдеме, әллә Илсөянең урт-чигә сөякләре чыгырдадымы, нидер булды. Колаклары тынды, күзе күрмәс булды, аңы томаланды хатынның. Егылып китмәс өчен тотына-тотына, ишек янына барып утырды…

Кайчан, кайчан гына булды әле шундый хәл? Нигә шулай аяктан ук екты ул Илсөяне? Ерак балачак шунда гына икән ләбаса. Нәкъ шул чактагы кебек таң ата икән…

* * *

...Илсөя иртә торырга ярата. Әбисенең иртәнге намазга дип тәһарәт алырга чыгуын көтә дә, ялт итеп, әле җылысы суынып бетмәгән ястык уртасына кереп тә чума. И җылы да шул әби ястыгы! Ну, апалары торгач көлүен көләләр инде үзеннән:

– И, тагын әби янына яткансың, шуңа да тешсез каласың!

– Курыкма, кызым! Болары сөт тешләре генә, алары төшкәч, тимер тешләр чыга, – дип юата әбисе.

Әй, төшсә төшсен инде, чыгар әле! Алар әби белән йоклау рәхәтен белмиләр, шуңа шулай дип әйтәләр дә. Бәлки, үзләренең дә җылы ястыкка кереп ятасылары киләдер әле? Ә әбисе пыш-пыш итеп намаз укый башлагач ничек рәхәт икәнен белсәләрме? Әйтерсең кемдер Илсөянең башыннан сыйпый диярсең, ул яңадан изрәп йокыга китә. Әмма матур төшләр дәрьясында озак юанырга туры килми, әбисе кыштыр-кыштыр килеп комганы белән гөлләргә су сибеп йөргәндә, Илсөя янә уяна. Апалары йокыдан торганчы, әбисенең яшереп куйган тәмнүшкәләре белән чәй эчәргә дә өлгерә ул. Каз-бәбкәләрне инешкә куыша, кош-кортларны ашатырга булышып йөри. Әбисе аңа ачуланмый да, әллә үзенә иптәш дип ул да куанып йөриме?

...Шундый татлы, шундый якты иртәләрнең берсе иде ул.

Илсөя әллә кайчан уянган инде. Әбисенең комганыннан гөлләргә су сипкәнен көтеп ята. Әбисе дә бит, идәндә яткан кызлар өстенә «ялгыш кына» су тамыза-тамыза, тегеләрнең ачуын чыгарып йөри. И, ул көн дә шулай. Су сибә, аннары кызларның:

– И әби, соң инде! Самый тәмле генә йоклап яткан-да... – диешеп, икенче якларына борылып ятуларын күреп кеткелдәп ала.

Юк, уятмый әбиләре кызларны:

– Йокласыннар. Каникул вакытлары бит, – ди.

Әнә аның кечкенә Илсөясе чәй янына утырганны көтеп кенә ята.

– Әйдә, кызым, әнә каз бәбкәләрен суга төшерәсең, тавыкларны ашатасың бар. Мин синсез бернәрсә дә эшли алмыйм, үзең беләсең бит. Ә болар йокласыннар, алар торганчы без бөтен мәмәйне ашап бетерәбез, дамы? – дип, салпы якка салам кыстыра-кыстыра чәй әзерли.

Илсөягә шул гына кирәк. Юрган астыннан шуышып кына чыга да, аякларына да кими, йортка чыгып йөгерә. Ашыга-ашыга чыга. Аның ишегалдындагыларга сәлам бирәсе бар.

Әнә тавыклар арасында да апалары кебек йокы чүлмәкләре бар икән. Яңа гына кетәклектән төшеп килүчеләре күренә. Әтәчнең дә эше каты. Тавыкларын барлый, әле берсе, әле икенчесе янына килеп нидер сөйләп ала. Усал ул.

Бермәл әбисе белән ишегалдында йөргәндә, йөгереп килде дә Илсөянең башына сикерде. Маңгаен шундый каты итеп чукыды, ярый күзен эләктермәде. Ул вакыйгадан соң әбисе нәрсәдер эшләтте аны, хәзер тешләшми. Аннан соң Илсөя дә зур үсте, җиде яшь тула, әтәчтән тешләтеп тормый инде хәзер.

Ата каз Илсөянең чыкканын гына көтә, ысылдап ук килә башлый. Илсөянең, куркып, болдырга таба кире йөгергәнен күрсә сөенә инде. Аның артыннан ук ысылдап килүче ана каз белән гөлдердәшеп алалар. «Ка-ка, ка-ка»! Имеш, быел да унтугыз бәбкә чыгарганнар. Ә менә Илсөягә килгәндә, какай, какай, дип, бер дә дөрес әйтмисез! Илсөя бик тәти кыз! Аңа ул сүзне көненә йөзәр мәртәбә әйтәләр. Ата каз шундый инде ул, гаиләсен, балаларын саклый. Илсөя үзе генә булганда, кызны санга сукмыйлар алар, яннарына барып булмый, ә менә әбиләре белән елгага куганда, артка борылып та карамыйлар. Әбиләре янында Илсөя бәбкәләрне кулына да алып сөя әле. Ярата бит ул аларны.

...Казлардан соң, Илсөя Акбай янына ашыга. Эте дә бит, кыз ишектән күренүгә, оясы янындагы җирне кесәлгә әйләндереп бетерә. И, ыргыла, бәйдән ычкынмакчы була. Ике аягы белән Илсөяне кочып ала, аның бәләкәй кулларын, аякларын ялый. Кайчандыр Илсөяне тешләгән дә иде әле ул. Тыныч кына йоклап яткан маэмайга таяк белән сукты бит. Ә тегесе куркып уянды да, ыргылып, кызның кулын тешләп тә алды. Табибка бардылар, укол да кададылар әле. Шуннан соң кыз Акбай янына озак килмәде. Тора-бара гына дуслаштылар. Хәзер әнә Илсөя, йокларга ятканда да, «Сау бул, Акбаем» дип саубуллашып керә.

Бу матурлыкны, бу хәрәкәтне күрмичә апалары ничек йоклап ятадыр?!

И, алар укыйлар шул. Укый-укый арыйлардыр... Әбисе әйтә, каникулларында ял итсеннәр, ди. Тикмәгә генә укуны инә белән кое казу димиләрдер. О-о! Коены, инә белән?! Менә быел Илсөя дә «кое казырга» керә. Аның тизрәк укырга барасы, «укытучы апа» буласы килә. Күршеләрендә укытучы Сәрвәр апа тора аларның. Аның матур киенеп йөрүләре!.. Вак-вак кына басып, төз гәүдәләре белән турларыннан үтеп киткәндә, Илсөя аңа кызыгып карап кала. Күп вакыт аннан:

– Үскәч кем буласың? – дип сорасалар, Илсөя ике дә уйламый:

– Сәрвәр апа булам! – дип куя.

Аның укытучы апа буласы килә. Әнә шулай матур киемнәр киеп, иренен буяп, портфель, бер кочак китап тотып йөрисе килә...

Көтү китеп кенә барган, күрше-күлән апаларының сөйләшә-сөйләшә кайтулары үзе бер бәйрәм кебек бит!

– Әрәм иткәннәр, күр әле.

– Нигә шулчаклы буярга?

– Әллә дегет! Буяган капканы күрмәгәннәрдер инде, төнлә сылаганнар моны...

Ә бүген алар бөтенләй башкача сөйләшәләр. Чү, алар Илсөяләр капкасы каршында ук түгелме соң? Тик нәрсәгә шулай аптыраашта калганнар икән күрше апалары? Илсөя капка ачып урам якка чыкты.

– И, тәти кыз да торган икән!

– Сабый йоклыймыни ул?!

– Таң белән тора, ди әбисе...

Күрше апалар сөйләшә-сөйләшә китеп бардылар.

– Әй, кызым, ник урамга чыгасың? Кая, кемнәр бар анда? – диде ишегалдыннан килеп чыккан әбисе.

– Әбием, менә күр әле, капканы буяганнар, – диде Илсөя.

Нәгыймә карчык капкадагы дегетне күреп егылып китә язды.

– Ай, Аллакайгынам! И Раббым! Менә бәла! Кем эше булыр бу? Нигә безнең капканы? Ни өчен?!

Хәле киткән карчык капка төбендәге эскәмиягә утырмакчы булып килсә, анда төенләп бәйләгән кечкенә төргәкне күреп таң калды:

– Чү, кызым! Тотына күрмә!

Һәрвакыт алдан йөгереп барып, барысын да үз күзләре белән күрергә гадәтләнгән Илсөяне күлмәк җиңеннән эләктереп көчкә тыеп калды:

– И, бәхетең генә булгыры бала! Кая чаба икән? Әллә тиеп тә өлгердеңме? Ярамый, берүк тотына күрмә!

– Юк, әби, чыктым гына ич әле!

Әбисе теге төргәкне йорт себеркесе белән чиләккә төртеп төшерде. Аннары Илсөя белән бергәләп бәрәңге бакчасы аша салынган сукмак буйлап бардылар да аны тирес өеменә ыргыттылар. Әбисенең йөзеннән нур качты: ирен читләре эчкә батып, борын яфраклары кабарынып өскә чыкты, ә үзе һаман бер сүзне кабатлады:

– Кем эше булыр бу? Ялгыш хәлме, чын хәлме?.. Ни хәл итик?..

...Әле генә матур таңга, якты көнгә, кош-кортларга карап, дөнья рәхәтлегеннән балаларча тәм табып йөргән

әбисенең болай ачуланган чагын моңа хәтле күргәне булмаган Илсөя дә боекты.

Иртәнге салкын чыктан ялантәпи атлаган Илсөянең бәрәңге араларында ватылмый калган кәсләргә баса-баса аягы авыртып бетте. Әмма әбисеннән артта калырга ярамый, ул, аның ачулы адымнарына ияреп, эндәшми генә түзеп элдертүен белде. Әнә бит әбисе нигәдер борчыла.

Кире кайтканда гына үз янында аксый-туксый кайткан кызга игътибар итте әбисе:

– И бала! Ник кенә аягыңа кимәдең инде, йә?

Кечкенә Илсөяне кулына алгач, карчык тагын үзалдына сөйләнергә тотынды:

– Ялгыш хәлдер бу! Бүгенге көнгә кадәр үз кызым кебек булды. Бер яшерен нәрсә ишетелмәде. Ни хәл булыр бу?..

Әбисе, Илсөяне ишек төбендә калдырып, өйгә кереп китте.

* * *

...Илсөя беравык уйланып утырды. Ул чакта да нәкъ бүгенге кебек таң аткан иде. Ни өчен шулай хәтердә калды соң ул көн? Бәлки, чи канга баткан аягы аны һич онытмаслык иткәндер? Алай дисәң, бала чакта аяк, бигрәк тә тез башы, гел чи канда йөри инде ул.

– Илсөя, нишләп аңгыраеп утырасың, әйдә чыгар сөтеңне!

Илсөя, ишегалдында инде әллә кайчан әзерләп куйган сөтен тотып машина янына килде. «Сөт җыючы Саимә ни әйтер, и Ходаем!»

Ә анысы хатынның уйларын белгән кебек:

– Каралтkансыз! Капкагызны әйтәм. Кичәгенәк бик кызыгып киткән идем. Сары гәрәбә кебек иде. Хет олифка буярга идегез инде, – дип йөрәгән чеметтерде.

«Буярга идегез! Буямадык шул, әнә олифы да, буя-

вы да әзер тора. Һаман кул тимәде!» – дип уйлады ул эченнән генә.

Илсөя, бушаган чиләкләрен тотып, өенә таба атлады.

«Капканы, тактаны... Нишләргә инде?!»

Капкадан чыгып килүче ире Илгизәрне күреп, куркып китте. Ни дияр?!

Нык ачуы чыкканда да «Чәеңне түгәрмен!» дигән сүздән арыны әйтмәгән Илгизәр капканы күреп сызгырып ук җибәрде:

– Ах!.. Яп-яланаяк! Кем эше бу?!

Илгизәр ашыга иде. Машинасын кабызып, инде китәм дигәндә, аптырап торган хатынын күреп:

– Малай-шалай эше бу, юкка борчылып торма. Хәзер мастерскойдан бер-ике ир-ат җибәрермен. Буярлар да эше бетәр, – диде.

* * *

Аягын капшап елап утырган Илсөяне күреп, өйдән чиләк белән көл алып чыккан әбисе, бу юлы бөтенләй ачуы чыгып:

– Әй, утырма әле аяк астында, бар кереп кит! Ю аягыңны! – дип кычкырды.

Аннан урыс капканы зур итеп ачып куйды да, күлмәк итәкләрен ыштан бөрмәсенә кыстырып, капкадагы дегетне ышкырга тотынды...

Ничек кереп ятсын Илсөя, капкага шундый ямьсез кара дегет сылап киткәннәр. И, аларның капкасы! Авылда бер урыс капка ул! Җитмәсә, әле күптән түгел генә Мәскәүдән абыйсы кайтып буяп киткән иде. Күк йөзе кебек зәп-зәңгәр буяуга буяды ул аны. Өс читләрен челтәр калай белән дә бизәде. Менә шул матур капканы кем каралткан? Ни өчен?

Капка ачылганын күреп, урамга чыгып китәргә җай булды дип, өй янына какылдык казлар җыелды. Илсөя, аяк авыртуын да онытып, сикереп торды. Әтисе,

очында биш-алты яфрак кына калдырып, озын талчыбык өзеп биргән иде. Аның белән казлардан курыкмый инде ул. «Әйдәгез, әйдә! Кеш-кеш», – дип, аларны елгага таба куып китте.

«Әби нигә шулай борчыла икән?.. Нигә тиз-тиз капка юарга тотынды ул?» дигән уйлар кечкенә кызның башыннан китмәде. «Нигә шулай пошаманга төшәргә, юасың да бетә ич инде ул?!»

Әбисе чыннан да капканы ялт иттергән иде. Су белән дә юган. Капканы берни булмаган кебек ябып та куйган.

– И кызым, балакай гынам! Аягың инде, әйдә юындырыйм әле үзеңне. Аннан соң тәмнүшкәләр белән чәй эчәрбез, дамы?! Минем ярдәмчем бит ул! Иң тәти кыз ул, Аллага шөкер!

Әбисе белән тәмле итеп иртәнге чәйне эчеп, әппәр әйткәндә генә, ишектә Илсөянең җиңги әбисе күренде.

– Әйдә, җиңги, уз. Бик мактап та йөрмисең, ахры, яңа чәй яныннан тордык. Самавырны яңартыйммы соң әллә?

– Ярар, яңартсаң – эчәрмен, яңартмасаң – үпкәләмәм. Үзем дә чәйләдем анысы. Эч поша, йоклап булмый. Менә хәл белеп кайтыйм дидем. Аяклар да атламый хәзер. Көчкә килдем.

– Бар, кызым, тавыкларга бирәр нәрсә сал әле. Бар, бар! Олылар янында сүз тыңлап утырма!

Нәгыймә карчык Илсөяне ишегалдына хәтле озата чыкты:

– Кызым! Берүк кешегә әйтә күрмә, сөйләргә ярамый! Ишетсен колагың, бернәрсә булмады! Яме?!

Әле һаман ишек катындагы урындыкка утырып, читек өстеннән кигән кәлүшен салып маташкан Фәнүзә җиңги таңнан торып әбисенә булышып йөргән кызны жәлләп куйды:

– И, орышма инде! Иптәш бит әле, кыштыр-кыштыр

янында йөрүе үзе бер гаҗәп бит! Минем малайлар әнә төшкә хәтле йоклыйлар. Кирпеч саласы бар. Инде бүген, иншалла, тотынырлар дип торам. Көн яңгырга китмәсә...

– И, Аллага шөкер! Иртүк тора, Ходай рәхмәте! Тәтел-тәтел сөйләп торуы да рәхәт.

– Миннәхмәтләр кая киттеләр диден әле?

– Мәскәүгә! Мөнәвирем кайткан иде бит. Мәскәү күреп кайтырсыз, дип алып китте. Узган ел бәрәңге саткан акчаны җыеп куйганнар иде. Исән-имин генә кайтсыннар инде, Раббым ярдәменнән ташламасын үзләрен!

– Сыерыгызны кем сава?

– Галия сава, олы кыз. Сөбханалла, кул арасына керделәр инде.

– Ничәгә бара соң әле ул быел, бигрәк сабый күренә.

– Җидене бетерде, Алла боерса, быел сигезгә бара бит инде. Буйга гына кечкенә ул. Әлхәмдүлилләһи, бөтен эшне эшлиләр. Әниләре эшне бүлеп калдыра.

Илсөя ишегалдында озак юана алмады, аны зурларның сөйләшүе кызыктыра иде. Апалары торуга бөтен яңа хәбәрне алдан белеп куючы да ул шул өйдә. Шыпырт кына өйгә кергән кызны берсен-берсе узып сөйләшүче карчыклар күрми калдылар. Ул әкрен генә мич артына посты.

– Эшне бүлеп калдыра, дигәннән әйтәм әле. Үзе гел йөреп тора. Кайтып та керми бугай...

Нәгыймә карчык әллә нишләп китте: «Бер дә бушка йөрмәсен сизенгән идем, таңнан нәрсә булса да ишеткәндер бу явыз!..» Аннары:

– Тагын нәрсә ишеттең инде? Килененңне әйтер идем. Урам авыз булды, һаман гайбәт сөйли, җир бит! – диде.

– Чү әле, Нәгыймә! Мин әйткәнне көт. Утсыз төтен булмый, күрешкәннәр, дип сөйлиләр.

– Шуннан?

Нәгыймә тагын шомланып: «Капканы гына күрмәгән булса ярар иде!» – дип уйлап куйды. Фәнүзә, тавышын әкренәйтә төшеп:

– Каладан утырып кайтканын күргәннәр.

– Юкны сөйләмә! Мәйсәрә хөкүмәт кешесе ул. Кая бармас та, кемгә утырып кайтмас! Аллам сакласын! Персидәтель ул, өстәвенә район Советы депутаты. Йомышы булгандыр.

– Әй, үлдең инде киленеңне яклап. Бер генә тапкыр кибеткә барып кайт син, белерсең! Аң бул дип кенә килгән идем. Әйттем исә кайттым, миңа нием калган инде, – дип, Фәнүзә җиңги сыкрана-сызлана урыныннан кузгалды.

– Тукта, җиңги, тыңла әле! Бу минем гозерем. Әгәр тагын Мәйсәрәне сөйләгәндә авыз ачып тыңлап утырсаң, мәңге бәхиллегем юк! Юк сүз сөйләү – гөнаһ! Зур гөнаһ! Ишетсәң дә шулай дип әйт, дөрес хәл түгел!

Фәнүзә карчык эндәшми-нитми генә чыгып китте.

Мич алдында инде баядан бирле кайнап утырган самавыр да, гайбәт сүзне сөймәве булдымы, уфылдап куйды. Аннан әкрен генә чыжлый башлады. Нәгыймә карчык әле генә исенә килеп ишегалдына чыкты. «Әллә ялгыш каты бәрелдем инде?» дип, аягы авыртса да шактый ук араны китеп өлгергән җиңгәсе артыннан карап калды. Аннан, үзе артыннан чыгып килүче Илсөяне җитәкләп, эскәмиягә барып утырды...

* * *

Быел җитмешен тутырып килүче Нәгыймә карчык, әле эштә дә, ашта да дигәндәй, сынатырлык түгел. Сәламәтлеге дә ташка үлчим! Дөрес яшәде ул. Дөньяны, тормышны яратты. Ире Вахит колхоз рәисе иде. Начар яшәмәделәр. Әнә бит Фәнүзәләр әле дә, кирпеч салабыз, дип торалар. Нәгыймәләр сугыш вакытында

да салмадылар кирпечне. Тик бик иртә китте шул Вахиты. Алтмышы да тулмады, кәнсәләрдә нәрәт вакытында әллә нәрсә булды үзенә. Өч кенә көн ятты. Ике малай белән каенана-каената йортында яшәде Нәгыймә. Шөкер, әби-бабай белән үскән балалар булгангамы, уллары бик тәртипле булдылар. Унтугызынчы елгы Миннәхмәте армиягә киткән көнне күрше кызы япа-ятимә Мәйсәрәне алып кайтып калдырды. Капка төбендә ире Вахит, энесе Мөнәвир һәм Мәйсәрә елап калды. Инде кайтам дигәндә, сугыш башланды. Кырык җидедә генә кайтты Миннәхмәт. Никах укытып матур гына яшәп киттеләр. Башта Галия, аннары Гөлия, инде төпчеккә малай алып кайтабыз дигәндә, Илсөя туды. Мәйсәрә, ярәшкән егете кайтканчы, күрше район үзәгенә йөреп, тракторлар курсын тәмамлады, тракторда, аннан комбайнда эшләде, авылда кызлар укытты. Хезмәтен күреп, колхозга җитәкче итеп тә куйдылар, депутат итеп тә сайладылар.

Сугыш башланган елны Нәгыймәнең икенче улы Мөнәвир район үзәгендә шоферлыкка укый иде. Ул да сугышка алынды. Шөкер, исән-сау әйләнеп кайтты. Хәзер дәрәҗәле хәрби. Мәскәүдә яшиләр. Хатыны марҗа булса да, әнисен һинд чәеннән, әфлисун, лимоныннан өзеп тормый. Посылка арты посылка җибәреп кенә тора. Аларның да ике кызы бар – Инна белән Ангелина.

Бүгенге көндә Нәгыймә карчыкның биш оныгы бар. Бар да әйбәт, Аллага шөкер! Әмма менә бүгенге хәлне ничек аңларга? Нишләргә? Кемгә сөйләргә? Юк, ярамый! Сөйләргә дә, сорарга да ярамый! Ә капканы әле артык күргән кеше булмагандыр. Фәнүзә җиңги килгәндә, капканың эше беткән иде инде, күрми калды. Ә Мәйсәрә турында беренче генә ирештерүе түгел…

Нәгыймә карчык капкага күз салды.

«И, Аллага шөкер! Сизелми дә. Көл белән ышкуым да ярады. Мөнәвир парахут буявы дигән иде. Яхшы

нәрсә икән! Ә капка турында сораучы булса, көнләшеп буяган булганнардыр диярмен», – дип, үз-үзен юатты карчык. Авыл остабикәсе, укымышлы нәсел баласы булганга, гореф-гадәтне дә, им-том, дәваларны да бик яхшы белә ул. «Ә капканы бер дә юкка буямыйлар! Иренә хыянәт иткән хатынның капкасына гына гомер-гомергә дегет сылап киткәннәр. Юып та, кырып та бетми ул. Бик хурлыклы эш ул, хатын-кызга да шулай, бер яман сүз эләксә?! ...Теге төргәге дә күңелдән китми. Бозым да салмакчы булдылар микәнни? Аллам сакласын! Әстәгыфирулла тәүбә! Шикләнерлек бернәрсә дә юк кебек тә үзе... Беркем белмәс, иншалла! Беркемгә сөйләмәм...»

Бәхеткә каршы, ул хәлне яңадан сораучы да, искә төшерүче дә булмады.

Ә менә Илсөя онытмаган. Ул аны капка буяган саен, капка алыштырган саен исенә төшерде, әмма берәүгә дә сөйләмәде. Әбисе капка юган арада казлар куарга елга буена төшкәч, әле генә тирес өеменә ыргыткан кәгазь төргәген дә ачып карарга өлгерде ул. Анда ямь-яшел чирәм, чыршы ылыслары иде...

* * *

Илсөя дә мәктәпкә укырга керде. Укытучы Сәрвәр апасы укыта аларны. «Бишле»не җәлләми. И, инде өченче сыйныфта укый бит ул! Тырыш кызга ничек җәлләсен инде?

...Дәрескә чакырып кыңгырау шалтырады. Балалар, кыштыр-кыштыр килеп, парта араларына утырдылар. Гадәттәгечә ашыгып, Сәрвәр апалары килеп керде:

– Ирекле темага рәсем ясыйбыз, балалар. Язгыз: 1965 ел, 4 октябрь. Кем нәрсә тели, шуны ясый ала.

Әмма дәрестәгеләр чыш-пыш сөйләшә башладылар. Барысының да күзе тәрәзәдә. Мәктәп капкасыннан нindидер малай иярткән Зәйтүнә әби кереп килә.

– Тынычланыгыз, балалар, безнең сыйныфка түгел ул. Дүртенчегә. Эшкә тотыныгыз! – диде укытучы.

...Дәрес тәмам. Сәрвәр апасы гына, мәктәптән кайтканда, Илсөяне оялтты. Үзе ирекле темага рәсем ясагыз, диде, ә үзе...

– Илсөя, теге мәктәпкә килүче малайны ничек шулай тиз арада күзаллап өлгердең? Бигрәк оста ясагансың, – диде.

Илсөя кызарып ук чыкты:

– И, юк ла, Сәрвәр апа, миңа аның киеме генә ошады.

«Күрше Ситдыйк бабайның оныгы икән ул. Шәһәрдә яшәгәннәр дә хәзер күченеп кайтканнар икән. Әлегә үзе генә, әниләре соңрак кайта, ди. Бер авыз сүз татарча белми икән...» – боларын Илсөя өйгә кайткач апаларыннан ишетеп белде.

...И, кыланчык малай ла ул! Ботинка белән авыл урамында бик озак йөри алмас. Монда итек балтырыннан саз кергәнен белми әле!..

Ә менә ирекле рәсемне өченче сыйныф малайлары тәнәфестә шактый селкеп йөрттеләр:

– Кара, кара! Курткасы да, кепкасы да бар бит әле.

– Велвет куртка, велвет кепка
Кимибез генә икән...

Анда да Сәрвәр апасы коткарды:

– Ә сез нигә малайны гына күрәсез, мәктәп бакчасын, андагы чәчәкләрне күрмисез? Илсөя барыгыздан да өлгер булып чыкты. Шуңа «бишле» алды да.

* * *

...Замир татарча белми иде. Ситдыйк бабай белән Зәйтүнә әби инде картлар, өйдәге аралашу сүзләре генә малайның укуына булышмый, әлбәттә. Җитмәсә, урамында бер малай юк. Беркөнне Ситдыйк бабай, Замирны җитәкләп, үзе Илсөяләргә керде.

– Мәле, Миннәхмәт күрше, өч кызың бар, нәрсә бул-

са да әмәлләсеннәр бу малайдан. Ул безне аңламый, без аны аңламыйбыз. Урыс телен, арифмитикасын яхшы белә, диләр...

Замир шуннан соң гел кызлар янында булды. Дәресләрен әзерләп бетергәч, кызларга коедан суын да кертә, әтиләре янында мал-туар да карашып йөри. И, аның мәзәк хәлләрен сөйләп кенә бетереп буламы? Шәһәр малае сарык тизәге күргән нәрсәмени?!

* * *

Ә Замирның Миннәхмәт абыйларына кергән көненнән алып гармунда уйнарга өйрәнәсе килә. Алардан чыккач, әби-бабасын туйдырып бетерә:

– «Тымбата-тымбата, тымба итта, тымбата!» – Ул аны китап тотып та, самавыр астындагы подносны тотып та уйный. И, өздерепләр дә уйный бит Миннәхмәт абыйсы! Сиңа да өйрәтәм, ди бит!

Беркөнне алар икәүләшеп мунчага киттеләр. Юк, мунча керергә түгел, гармун уйнарга!

– Менә, энекәш, мин гармун уйнарга мунчада өйрәндем. Син дә өйрәнсәң, шунда гына өйрәнә аласың инде. Әйдә тарт әле, менә шунда, шунда басасың. Аннан соң ничек яңгыраганын тыңлыйсың. Гармун уйнау ул синең кебек такта тотып кычкырып йөрү генә түгел. Монда баш та, колак та, ике кул да, аяклар да эшләргә тиеш. Шулай булмаса, булмый!

Замир бөтен бармагы белән гармун телләренә басып тарта. И акырта, и кычкырта гармунны. Шул чакта Миннәхмәт абыйсы:

– Менә, брат, шуның өчен мунчада уйныйсың да инде аны. Өйдә мондый тавыш чыгарсаң, куып чыгаралар бит! Әйдә бирешмә! Чыга синнән гармунчы, чыга!

Бу хәтле мактаудан соң ничек уйнамыйсың? Замир тырыша-тырыша гармун күреген тарта.

Кайвакыт ачуы килеп:

– Никак! – дип тә куя.

– Как, никак? Давай, уйна! Аннан соң әтиеңә хат язарбыз, гармун апкайтсын!

Бизәкле авылында башлангыч мәктәп кенә булганлыктан, Замир да, Илсөянең апалары кебек үк, алардан биш чакрым ераклыктагы Сазлыкка йөри башлады. Әти-әнисе дә кайтты, үзләре дә мал-туар асрый башладылар. Замир хәзер татарчасын сиптерә генә, авылда туып үскән диярсең!

...Илсөя дә бишенчегә Сазлыкка йөри башлады. Замир күрше кызын күз уңында гына тотып йөрде. Мәктәптән сумкасын тотып кайтты. Миннәхмәт абыйсы:

– Син, брат, минем кызга күз-колак бул! Күрше булсаң күрше бул! – дип кисәтеп куйды.

Замир аны күрше абыйсы әйтмәсә дә белә инде. Илсөяне күздән ычкындырып кара син! Әнә нинди чибәр кыз бит ул. Ике бите ике алма, күзләре шомырт, йөзе якты айдыр. Шулай булмаса, аның хәтле сөйкемлелек каян килер иде? Алтынчы сыйныфка күчкәч, бигрәк тә матураеп китте. Замир аны яңа көн туганчы сагынып бетә. Иртән Илсөя артыннан йөгерә-йөгерә килеп керә...

Илсөя алтынчыга күчкән көннәр иде. Гел уйламаганда, әле егет дигән сүзне сөйләргә дә ярамаган бер мәлдә, тәнәфес вакытында аңа хат тоттырдылар.

– Хәзер укыма, беркемгә дә күрсәтмә! – диде аңа хат бирүче Салих.

...И, ул хат! Инде дәрескә дип кыңгырау да шалтырады. Юк, кереп буламыни соң дәрескә? Анда ни барын белмичә тыныч кына ничек утырмак кирәк?

Учны көйдереп, йөрәкне урыныннан кузгаткан бу кәгазь кисәген тотып, дәрескә ашыгучыларны этеп-төртеп, Илсөя урамга чапты. Нишләптер бу вакытта бөтен мәктәп аның кыланмышларын карап торадыр кебек тоелды. Каядыр качасы, үзе генә каласы килде аның.

Көзге яңгырлы көн иде ул. Чылана-юешләнә ишегалдындагы аулак почмакка борылды Илсөя, әмма, котын алып, артыннан ук кемдер кычкырды:

– Мәҗитова, нишләп йөрисең син? Дәрес башлана!

Бу завуч иде. Илсөя әйбер урлаганда тотылган кебек хәлсез калды:

– Мин?.. Ә… ни… апа, керәм бит!

– Тукта әле, нишләдең, әллә авырыйсыңмы? Йөзең акбур кебек булган бит!

– Юк, апа! Бер җирем дә авыртмый.

– Әйдә, кил әле менә шунда бераз утырып тор. Аннан соң дәрескә! Аңладыңмы?

Рәҗидә Каюмовна Илсөяне чишенү бүлмәсендәге урындыкка утыртты да, укытучылар бүлмәсенә кереп китте. «И, аңламыйммы соң инде. Авырыйм шул, апа, кулым пеште минем! Менә ич, учымдагы утлы күмерне күрмисезмени?..» – дип әйтәсе килде аның…

Илсөягә шул гына кирәк иде. Ниһаять, ул хатны ачып укыды. Анда «Илсөя + Замир! Мин сине яратам!» дип язылган иде.

Аһ!.. Ничек?.. Замир?.. Аны?.. Ничек инде ярата?! Илсөя нишләргә дә белмәде.

Кыз көзгегә үрелеп карады. Ике яклап «бәлешләп» үргән чәч, бит урталары алсуланып торган түм-түгәрәк йөз, кыйгач кашлар арасыннан менә хәзер-хәзер кабынып, янып китәргә җитешкән күзләр карап тора иде…

«Җүл-ә-ә-р! Әгәр укытучы апа хатны кулымнан тартып алган булса, беткән идем бит!»

Хатны еракка, әбисе бәйләгән йон оекбашның балтырына яшерде Илсөя. Дәрескә соңарып кергән кызның шатлыклы кыяфәте шулай ук укытучыга да сизелдеме икән, ул:

– Күр әле, соңга калып керә дип уйламассың да. Кояштай балкый. Утырып торма, әйдә сөйлә, – дип, кызны такта янына чакырды…

...Сөйләгәндерме, юкмы, Илсөя анысын хәтерләми. Әмма шул көннән соң ул сыйныфташ кызлары арасында бер башка зур үсеп китте. Хәзер чәчен дә толымлап, ике якка бантик белән үреп җибәрә. Мәктәпкә кайбер көннәрдә җылы кофта киеп барса, аны салып, парта астына тыгып куя. Форма матуррак бит. Кара алъяпкычның күкрәк турысына челтәр дә тегеп куйды. Илсөяне үсендергән сәбәп, әлбәттә, Замир иде. Җитмәсә, көн дә Салих артыннан хат җибәрә тора...

И, Замирны бөтен мәктәп ярата ла! Кызлар да, укытучылар да! Гел мактап кына торалар. Гел «биш»кә укый. Рәсеме – Почет тактасында.

* * *

Замир – шаян егет. Ә менә Илсөя аның бөтен дөньясын оныттыра. Иң ыспай егеткә әверелә дә куя ул. Бөтенләй телсез кала. Бер генә тапкыр булса да күрше кызының күзенә карыйсы, кулларыннан тотасы, чәчләренә кагыласы килә аның. Әмма кыргый боланны кулга ияләштереп кара син! Авыл клубына киномазар килсә, Замирның шатлыгы эченә сыймый. Ул күрше кызы белән кинога бара бит. Әниләре дә Илсөяне, Замирдан калма, дип озатып калалар...

Җиденчене тәмамлагач, җәйге каникул чорында авыл кызлары белән бергә Илсөя дә ындыр табагына эшкә чыкты. Кызларны ашлык ташучы машиналарга беркетеп куйдылар. Ә Замир комбайнда ярдәмче булып йөри. Кичләрен еш кына бергә кайталар.

...Шундый кичләрнең берсе иде. Коеп яуган яңгыр кырдагы бар эшне туктатты. Иртәрәк кайттылар.

Тыкрыктагы бүрәнә өемнәре өстендә Замир белән Илсөя утыра. Төнге күктә яумый калган болытлар йөгерешә. Алар куышлы уйныйлар кебек. Ашыгалар, табышалар... Бергә кушылып, тагын ары китәләр.

Болытлар арасыннан сирәк кенә түм-түгәрәк ай күренеп ала. Ул Илсөя белән Замирны күзәтә кебек. Янәсе, утыралармы? «Йөзләрен яктыртыйм әле, бер-берсенә тагын да нурлырак булып күренсеннәр!» – дип әйтә кебек ул.

– Илсөя, мин тугызны укырга калага китәм... Аннан институтка керергә уңай була.

– Ярый соң, китсәң, мин нишли алам, – ди Илсөя, ә үзе ут эчендә яна.

– Син дә тугызга минем янга килерсең. Икәү укып йөрербез. Мин сиңа булышырмын.

– Мин үзем дә гел «биш»кә генә барам. Так что, ярдәмең кирәкмәс.

– И, мин сине сагынырмын инде.

– Шәһәрдә кызлар бетмәс әле.

Илсөя үзе шулай ди, әмма Замирсыз ничек укып йөрүен күз алдына да китерә алмый.

– Илсөя, син мине көтәрсеңме?

– Син нәрсә, әллә армиягә китәсеңме?

– Юк, син әйт әле, көтәрсеңме? Мин атна саен йә ике атнага бер генә кайтачакмын.

– Әйтмим әле менә!

– Илсөя, айны күр әле! Нинди тиз йөзә ул. Әллә ул болытлар белән куышлы уйныймы?

– Ну, шуннан...

Илсөя әйтер сорау Замирның җылы иреннәренә тиеп югала... Ул шулчаклы тиз була ки... Илсөя торып йөгереп кенә китәр дә, җир ярылса, шунда гына качар иде. Торып китәргә дә оят. Ул башын шудырып кына төшерә дә, аны Замирның күкрәгенә куя. Замирның йөрәге дә, әллә кайчан күкрәк читлеген ташлап чыгып, бүрәнәләр арасына качканын Илсөя белми әле...

– Йә инде, Илсөя, ачуланма! Иртәгә китәм бит мин!..

Илсөя капка төпләренә кадәр йөгерде, аннан Замирның пинжәген бирер өчен генә тукталды. Тик кулларын җиңеннән чыгара алмый калды. Замир, аны көчле куллары белән кочып алып, тагын, тагын үпте.

...Ул төнне Илсөя ут янды. Моңарчы күренмәгән, моңарчы сизелмәгән күңел кылларын тибрәтеп, бу төн аны йокысыз интектерде.

Нинди сихри, нинди көчле икәнсең син, мәхәббәт!

...Илсөя дә мәктәпне тәмамлап институтка укырга керде. И, ул бәхетле студент еллары! Замир белән көн саен очрашу! Авылдан, әти-әнисеннән аерылып китүне дә кыз әллә ни авыр кичермәде, чөнки Замир аны һәрдаим кайгыртып торды, гел янәшәсендә булды. Аспирантурада калырга, өйләнешеп, калада яшәргә дип планнар корды алар.

Ә планнар корылган килеш кенә калды...

Институтның өченче курсын тәмамлап кайткан көннәрдә, Илсөяне кара кайгы көтеп торган. Сиксән өч яшен яңа тутырган Нәгыймә әбисен, аның кырыгы җиткән көннәрдә газиз әтисен җирләде ул. Кайгыдан сыгылган әнисен ташлап китә алмады. Апаларының үз тормышлары, һәркайсының үз дөньясы үз мәшәкате белән тулганга, әнисен ялгыз калдырмады. Авылда яңа төзелгән урта мәктәпкә укытучылар кирәк иде...

...Әнисенең кайгыдан бетеренгән күңелен нинди сүзләр белән дә юаталмаган яшь укытучы Илсөяне тагын язмыш үзгәрешләре сагалап торган икән. Һич уйламаганда, Замир марҗа кызына өйләнеп куйды. Илсөянең киләчәге, бөтен өмете өзелде, язмышы челпәрәмә килде кебек. Аңа бик кыен булды. Авыл халкы, менә-менә өйләнешерләр, бу мәхәббәт кавышу белән тәмамланыр, дип көткән бер мәлдә булды бу хәл. Алар хакында инде легендаларга кушып сөйлиләр, егетләр һәм кызлар арасында язылган мәхәббәт хатларында да «Замир абый белән Илсөя апа кебек яратышсак кына йөрибез» дип шарт куюлар киткән иде. Замирның башкага өйләнүен авылда атна буе сөйләделәр...

Менә шулай, балалык дуслыгы булып, соңрак мәхәббәткә әверелгән эчкерсез сөю әле бүген дә Илсөя-

нең йөрәген авырттырып искә төшә. Ул ярату яшьлек елларына, еракта, бер-берсен алыштырып килгән ел фасылларына ияреп, кайдадыр үткәннәрдә калыр дип кем уйлаган?..

...Йөрәгенә якын итеп йөргән Замирны югалтуын Илсөя авыр кичерде. Әле ярый янында сабыр итә белгән киңәшчесе, газиз әнисе, кечкенәдән укытучы апа булам дип хыялланган хыялы булды. Әнә шулар үрләргә үрләгәндә нинди генә киртәләр очраса да, Илсөягә аларны җиңә алырлык ихтыяр көче бирде.

Илсөя читтән торып институтны тәмамлады. Ул хәзер авылларында мәктәп директоры. Әтисе урынына эшкә килгән фельдшер егет Илгизәр белән өч кыз үстерәләр. Әнисе дә янәшәдә. Әмма, Замирның авылга кайтканын белеп, кайсы явызы Илсөяләрнең гөл кебек тормышын бозмакчы микән?

...Илсөя өйгә кермәде. Ул һаман, аны тартып, моны төртеп дигәндәй, эш табып, капка буярга килүчеләрне көтте.

Кичә кич Илгизәр, Зәйтүнә әбинең хәле авыр дигәч, күршеләренә хәл белергә керде. Ситдыйк бабай да күптән җир куенында инде, Зәйтүнә әби дә картайды. И, бу гомерләр!..

– Син, кызым, ешрак кер әле! Бигрәк ярата идек бит үзеңне... – дип калды авырып яткан Зәйтүнә әби.

Саубуллашып чыгып барганда, капка төбендә каладан кайтып килүче Замир белән кара-каршы очраштылар. Ничә ел инде аның күзенә күренмәскә тырышты, алар кайтканда, күрешмәс өчен, бакча артыннан гына йөрде Илсөя.

– Исәнме, Илсөя! – диде Замир, кулларын сузып. Әмма куллары сузылган килеш калды.

– Саумы, Замир!..

Илсөя башка сүз дәшә алмады. Кулын да бирмәде. Көтмәгәндә каршына Замирның килеп чыгуы, алдына яшен ташы төшкән кебек, аның җанын өтеп алды.

Абына-сөртенә, ашыга-ашыга китте ул аның янынннан.

И, үз күңелеңнән шулай качып кына булса икән ул!

Нинди якын, нинди газиз икәнсең син, мәхәббәт! Беренче ярату, беренче сөю! Шашып, бар дөньяны онытып, Аның өчен яшәү! Каядыр өзелеп кенә каласың икән син! Сузылып кына аласы да... янә яратасы, утта янасы икән...

Әмма туасы сабыйлар, янәшәңдә синең өчен җанын бирер зат булганда, Аның әнә шулай каядыр өзелеп калып бөтенләй онытылуы үзе бер бәхет икән, олы бәхет!..

– Тукта, Илсөя! Бер генә минут... китмә! Без күршеләр ләбаса...

Илсөя инде ерактан:

– Әйе, Замир, күршеләр генә!.. Хуш! – диде.

– Кичер, Илсөя!

...Бөтен очрашулары шул булды. Ә кемгә кирәк булды икән соң капканы буяу?

Ул арада, машинасына өч ир-ат утыртып, Илгизәр кайтты, әмма капканы бүген буямадылар әле.

Илгизәр, кызы Алия янына нинди егет килгәнен белер өчен, кече кызларыннан сорау алды. Ике яшьлек Зәринәдән сорап та тормадылар, ул үзе әйтте:

– Әнә күлсе апалалга кунак малай килгән, ул көн буе Алия апаны кысаклап йөри...

Шулчак барысы да дәррәү капкага ябырылдылар. Анда, чыннан да, графити баллонлы буяу белән сиптереп, «Алия + Альберт. Я тебя люблю!» дип язылган иде...

Илгизәр дә, килгән ирләр дә тәгәри-тәгәри көлделәр. Алия исә, йөгерә-йөгерә, күрше Замирларга кереп китте...

Әле һаман ни булганын аңлый алмаган Илсөя генә елый да, көлә дә алмады. Шушы ике сәгать эчендә парә-парә килде бит аның йөрәге. Намуслы татар хатыны, көн дә йөзләгән баланың күзенә карап «намус», «вөҗдан» төшенчәсен бәйнә-бәйнә аңлатучы укытучы гаиләсе өчен дә, кызлары өчен дә йөрәге белән кайгырып, ут-су кичте бит!

## *Көтүдә*

Малайлы йортларга карап, әниләре бер пошынса, кызлары Фәрдия белән Фәрсиянең йөрәге ике мәртәбә көчлерәк янды. Үсә барган саен, күрше малайларына карап, «Эх, безнең дә абый булса иде ул» дип көенделәр алар. Малай малай инде ул, көрәген-сәнәген дә уфылдамый гына җилтерәтә. Егылса да еламый малайлар! Башларын бәрәләр, аякларын имгәтәләр, әмма үзләренә берни булмый!

Җитмәсә, әниләре дә:

– Әнә, Сәгыйтьнекеләр! – дип, гел йөрәкне әрнетеп тора.

– И, алар малайлар бит! – дип әйтәсең икән, кыза гына төшә:

– Ә сез – кызлар! Кызлар тагын да уңган булырга тиеш!

Менә шулай күрше Сәгыйтьнекеләрдән калышмаска тырышып эшләп үсте дә инде Фәрдия белән Фәрсия. Әнисе белән әтисе совхоз эшеннән бушамыйлар, иртәдән кичкә хәтле фермада. Бөтен хуҗалык кызлар өстендә. Ике сыер, сарыклар, кырык бишләп куян, тавыгы-чебеше... Күп инде. Язга керделәр исә, утызлап каз, илләләп үрдәк! У-у-у! Кызлар урамда сызык чиртеп йөрмәде, кайчан карасаң, эштә, кайда күрсәң, ни белән булса да мавыккан булдылар.

Язга чыксалар, бәбкә саклау, җәен печән чабу, көзгә кергәндә, утын әзерләү... Шулар азмыни? Арбага әтиләре махсус утыргыч ясады хәтта. Атка, әти-әниләре янына менеп кунаклыйлар да әллүр – кызлар теләсә нинди эшкә әзер!

Аралары бер генә ел булганга, кызлар икесе дә бергә мәктәпкә укырга керделәр. Тәртипле баланың укуы да «бишле» инде аның. Узыша-ярыша укып, калага киттеләр, дипломнар алдылар. Фәрдия – укытучы, Фәрсия театр белгече хәзер.

Шәһәр кызлары булдылар да куйдылар. Үскәндәге кыенлыклар балалык белән сизелмәгән булса да, җыелышып сөйләшеп утырганда, кабат-кабат кайтып:

– И, эшләтеп тә куйдыгыз инде, әни, – дип әйттерә тагын.

Әмма авыр хезмәттән сабыр итәргә өйрәнгән әниләре аларга җылы сүз әйтми. «Әйе шул, балакайларым...» дисә, кызларның «йомшаруыннан» курка. Алда тормыш көтәселәре бар, ә бу тормышта җебек булып яшәп булмый. Бигрәк тә хатын-кызга.

* * *

Инде ничә тапкыр хыялланып, ялларын һич тә бергә туры китерә алмаган кызлар быел сөенә-сөенә авылга кайттылар. Ниһаять, озакка, кунакка!..

– Балакайларым! И, Аллага шөкер! Кем бәхетедер инде, минекеме, әтиегезнекеме? Бигрәкләр дә әйбәт булды бит әле кайтуыгыз, өч көн көтү көтәсе бар! Быел теге тананы да көтүгә йөртәбез бит! – дип, сөенә-сөенә каршы алды әниләре ишек тупсасына тотынырга өлгермәгән кызларны.

– Кечкенә чакта безне юатып, бу маллар сезнең белән бергә укырга китәчәкләр, балалар, ди идегез. Үстек тә, укып та бетердек, инде нигә кирәк шуның хәтле мал асрау?

– Үзегезгә газап кына бит, әнием, кирәкмәс иде...

Кызларның бер-бер артлы уфтануларына каршы әнисенең сүзе әллә кайчан әзерләп куелган да тел очында гына торган диярсең:

– И бәбкәләрем, әле алда нинди олы эшләр барын белмисез дәмени? Бер-бер артлы сезне кияүгә сорарга килсәләр, нишләрбез? Әле безнең кызлар бирерлек акчабыз юк шул, диярбез микән?

Әниләрен көлешә-көлешә кочаклаган арада, ишектә кичке эшләрне бетереп керүче әти кеше күренде:

– Дөрес, кызларым! Бетерергә кирәк, әниегезгә дә бик читен. Менә кар гына төшсен, Алла боерса, исән булсак, берсен дә калдырмыйбыз! – дип, кызларны аркаларыннан сөйде.

Кызлар аңладылар, шул арада әнисенә күз кысып өлгергән әтиләренең уйларын гына укырлык инде алар. Авыл тормышын да беләләр. Ничек итеп олы йорт белән тор да, бер малсыз яшә ди авылда. Аннан эшенең, кунагының ни кызыгы булыр соң? Әле бит әти-әниләре эшкә барса, җиң сызганып эшләрлек, ашына барса, рәхәтләнеп ял итәрлек итеп тормыш алып барырга тырыша.

Чәйләр эчеп, бераз юл тузаннарыннан арынып ял иткән кызлар кичен көтү каршы алырга чыктылар. Фәрдия сыер саварга утырырга өлгермәде, Фәрсиянең куркып кычкырган тавышын ишетеп сикереп торды. Тавыш килгән якка чыкса, исе китте. Фәрсия ике кулы белән үгез абзарының коймасына ябышкан, ә үгез, башына чиләк кигән килеш селтәнә, мөгри. Ул Фәрсиянең чыгу юлын бикләгән булып чыкты. Ул арада абзардагы тавышка әти-әнисе чыгып, көч-хәл белән үгез башындагы чиләкне салдырдылар. Әниләре:

– Соң, балакай, аның янына әтиеңнең дә кергәне юк лабаса. Алла саклаган инде үзеңне. Йә Раббым! Әле дә ярый күрәчәкләр булмаган, – дип сыкранды.

– Ә мин тагын кызларыма кияү эзлим, алар үсеп тә җитмәгәннәр икән әле! – дип кеткелдәде әтиләре.

Фәрдия сыер сауган арада, кечкенәдән ачуын бастырмыйча калмаган Фәрсия үгезгә берничә тапкыр:

– Кара син аны, котымны алды, бәдбәхет! Әгәр башына чиләк капланмаган булса, эчәгемне чыгара иде бит, – дип, сәнәк сабы белән дә, чыбыркы белән дә үгез сыртына тамызып алды. – Чиләк белән алдына фураж салган булам тагын!

* * *

Кызлар кайтып төшкән сәгатьтән үк уйга батты Әбелхан. Күр инде син боларны, башта кулыбызга белгечлек дипломнары алыйк инде, дип сөйләшәләр иде. Юкса үзләре эшләгән коллективта күптән инде хөрмәтле Әбелхановналар булып йөриләр, ә кияүгә чыгарга уйлап та карамыйлар.

Хатыны белән икәү генә калгач, гаилә башлыгы:

– Мал-туар бар чакта, үзләре матур чакта дигәндәй, кызларны урнаштыру ягын кайгыртырга кирәк. Син дә җитдирәк сөйләш. Һаман бала-чага кебек чырык-мырык килеп уйнап йөрмәсеннәр, – дип әйткәләп алды.

Кызларының бер-бер артлы үсеп, икесе бер вакытта туган оядан китеп баруларына күнегә генә башлаган Фәрдәнә, иренең төрттермәләренә кәефе төшеп:

– Юкны сөйләмә, өлгерерләр. Иргә чыгу туй үткәрү генә түгел икәнен бик яхшы беләсең. Яшьлекләренең кадерен белеп калсыннар. Насыйплары чыгар, сизми дә калырсың әле.

Әмма Әбелхан башта әйтеп кенә үтә, ләкин барыбер үзенчә эшли. Бу юлы да шулай булды. Кичен өстәл янында кызлардан:

– Әллә бер дә кияүләр юкмы соң, кая, кайсыгыз алдан сөйли? – дип сорап куйды.

Әбелхан аларны кечкенәдән:

– Яле, кайсыгыз? Кем беренче өлгерә? – дип, узышырга өйрәтте. Әле дә кызларының үсеп җитүен, гомумән, аның кечкенәләре күптән мөхтәрәм затлар икәнен әллә соң белми дәме?

Әлбәттә, кызлардан җавап ишетелмәде. Алар берберсенә карап елмаюдан ары узмадылар.

Без барында йокласыннар, ял итсеннәр, дипме, иртән әтиләре йокыдан уянганчы ук, кызлар сыерны савып,

малларны ашатып өлгергән иделәр инде. Көтүгә чыкканда, әтиләре:

– Иртән кабаланмый гына атлагыз, үзләре әкрен генә ашап баралар алар. Көн кызуында сабырсызлана башлыйлар. Кигәвен борчый үзләрен. Әрәмәлеккә таба бара торыгыз. Төштән соң үзем дә килермен, – дип, киңәшләр бирә-бирә икесенә дә чыбыркы тоттырды.

Авыл зур булмагач, көтүе дә шулай гына инде аның.

– Егерме өч сыер, икебезгә унберәр чыга. Берсен урталай бүләбез, – дип мутланып алды Фәрсия.

– Әни кичәгенәк, егерме ике сыер бар инде, сезгә ул прагулка гына, дигән иде.

Авылны чыгып, әрәмәлек юлына төшкәч, кызлар берсе алдан, берсе арттан бара башлады. Алдан баручы Фәрдия ашыкмый гына тирә-юньне күзәтте. «И авыл! Менә шулай бер мәшәкатьсез генә түгел шул син. Синдә тормыш таң белән башлана. Арып-талып эшләсәң дә рәхәт, һаваң рәхәт, эчәр суың тәмле синең. Менә бу кошлар сайравын шәһәрдә ишетеп буламыни? Әнә ничек үзәкләрне өзәләр бит алар. Ә таң атуың? Алсуланып көн ачылуын күрү үзе бер ләззәт бит! Без шәһәрдә эшкә ашыкканда, кояш әллә кайчан күтәрелеп, биек-биек йортлар түбәсенә менгән була...» – дип уйлады ул. Нечкә күңелле, сабыр холыклы Фәрдия авылны яратуын яшерә алмады.

Сыерлар артта калмасын дип барлап баручы Фәрсиянең генә күңеле тыныч түгел. Аның күзе, керфек сирпеп ябарга да куркып, әледән әле артта кала барган үгездә иде. «Каян килеп чыкты соң бу үгез? Аларныкына да охшаган кебек, ләкин аны әтисе, көтүгә чыгармыйбыз, дип сөйләнгән иде. Хәер, үгез үгез булыр инде, бар да бертөсле бит инде алар...»

Ә үгез, Фәрсиянең курыкканын белгән кебек, һаман үкерә-пошкыра артта кала бирә. Аның атлауларын гына кара син, фил бара диярсең! Берне атлый да икенче

аягын җирдән озак итеп алмый тора. Шул арада Фәрсиянең:

– Кая кала, әйдә атла, ну-ка, ф-ю! – дип сызгырып, чыбыркы шартлатканын ишеткәч кенә, үгез тагын берне атлый. Атлавын атлый, әмма ризасызлыгын белдереп башын боргаларга тотына. Бу вакытта аның сырт йоннары да кабарынып алалар кебек. Боларның барысын да Фәрсия генә күрә дә, Фәрсия генә сизеп бара. Көтүче кыз инде әрәмәлек буена килеп җиттек, аннан Фәрдия белән бергәрәк булырбыз дип уйлап өлгермәде, үгез кинәт, ямьсез итеп акырып, Фәрсиягә таба килә башлады. Кыз моны көткән иде, баядан бирле шул хәл була калса дип үзенә сыену урыны күзләп барды бит. Бар көченә ерак түгел генә туктаган машинага таба чапты ул. Үзе чапты, үзе кычкырды Фәрсия:

– Әй!.. Коткарыгыз!.. Әй, әһей!..

Кыз үзе кычкырды, үзе бернәрсә күрмичә, бернәрсә ишетмичә чапты да чапты...

Инде менә бирегә ничек менде икән дә, кем коткарды икән аны?..

Шулай уйлап, машина кузовыннан башын күтәреп караса, исе китте: ике балыкчы егет, көлешә-көлешә, ат белән килгән әтисе Әбелханга Фәрсия турында сөйлиләр иде...

Ә үгез чыннан да аларныкы булып чыкты. Аны Фәрдия чыгарган иде. Ул әти-әнисенең аны симертер өчен абзарда ябып тотуларын белмәгән. Үгез үзен кичә кыйнаган кызны ачудан сөзмәкче булгандырмы, әллә абзардан бер дә чыкмый торгач уйнаган гынадырмы, әмма Фәрсиягә таба түгел, авылга чапты ул...

Ә теге балыкчы егетләр ялга кайткан кызларны икенче атнада сорарга килделәр. Эшкә түгел, ә кияүгә!

# ПАРЧАЛАР

## *Кыр казлары киткәндә*

Ишеткәне дә, китаплардан укыганы да бар Гадиләнең: гомер уза барган саен, тормышның кадере арта, яшәгән саен яшисе килә. Тормыш мәшәкатьләре белән көн үткәнен сизми дә каласың икән. Әле генә, әле генә бит җирләр кардан арынып, бакчада, үзебезгә ашарга насыйп булсын, ди-ди, тегесен-монысын чәчеп йөргән идек. Инде көз җиткән. Бушап калган басу-кырлар, иркен сулап, киләсе елга хәтле ялга туктаганнар. Аратирә кукуруз, көнбагыш кырларында кызу эш кайнавы күренә. Кинәт яңгырларга китеп урылмый калмасын дип ашыга авыл кешесе.

Автобус тәрәзәсеннән паром каланчаларын күргәч, Гадиләнең уйлары бөтенләй башка якка борылды. «Казан юлы – газап юлы» димәсләр иде. Ярты юлны автобус белән киләсе дә паром чыгасы, аннан, янә автобуска утырып, калган юлны үтәсе бар. Җәен шуннан чыгар өчен су буе чират... Мескен шоферлар интегә инде. Кышын да бер газап. Юлга чыкканда, суык булыр дип катлы-катлы киенәсең. Калага барып кергәч, киемеңне кая куярга белмисең, шәһәрдә җылы шул... Яз-көз бөтенләй юл өзелә. Нужа бабай килеп тотса, Чаллы аша да барасың – ул юл тагын да газаплырак.

Паромга кереп урнашкач та, арттан калмый озата барган акчарлакларга карап, тагын уйга калды Гадилә. Көн туган саен арта барган борчу-мәшәкатьләр белән быел кыр казларының киткәнен дә күрми калды ул...

Акчарлаклар, берсен-берсе узып, паромны озата бара. Кара инде бу талымсыз кошларны! Әллә соң мине озата барасызмы? Канатларыгыз талып бетәдер инде. Әй, кошкайларым! Ямьле җәйләр үтте шул, суык кышлар килә. Ә сез әнә ничек әрсезләнәсез, кешеләр янында булырга тырышасыз...

Машина ишеген ачып, паромга чыгып баскан Гадилә әллә нишләп китте. Чү! Нинди таныш тавыш бу? Күтәрелеп караса, исе китте: зәңгәр күкне иңләп кыр казлары очып бара иде. Эй, э-һә-һәй! Кошкайларым, бәгырькәйләрем минем! Сезнең тавышны ишетәмме соң мин? Китеп бетмәдегезмени әле? И бигрәкләр дә күбәү икәнсез!

Гадилә, кояш нурларыннан күзен каплар өчен кулын каш өстенә куеп, күктәге казларны санамакчы иде дә, ишеткәне бар: санарга ярамый! Сау булыгыз, сау гына була күрегез! Исән-имин әйләнеп кайтыгы-ыз!..

Сау булыгыз, кыр казлары –
Ак канат сеңелләрем.
Беләсез, диңгезләр кичеп,
Яшәүнең серен, ямен...

Күптән онытылган шушы җырны көйләп алды Гадилә. Аннан, минем болай кыланганымны күзәтмиләр микән дип, тирә-ягына карап куйды. Һәркем үзе белән мәшгуль: аны да күрүче юк, кыр казлары берәүне дә кызыксындырмый...

Кешеләр әллә нишләде хәзер. Ничек итеп кыр казлары хәтле кыр казларын күрмисең ди? «Кыйгак-кыйгак... Чый-чый...»

И-и, хәсрәтле дә соң тавышлары... Авыл өстеннән бер генә түгел, әллә ничә тапкыр урыйлар бит алар. Каурыйларын җилпи-җилпи кычкырып киткәндә, тирә-юньгә әллә нинди сагышлы моң тарала. Юк, түзә алмый, үксеп-үксеп елый Гадилә. Китәрләр дә кайта алмаслар кебек. Юллары бигрәк ерау, бигрәк ерак бит. Шуңа да моңсу итеп саубуллашалардыр. Ул, күзенә тулган яшьләрдән кыенсынып, кызу-кызу машинага утырырга барган җиреннән тагын туктап калды: кыр казлары кабат әйләнеп паром өстеннән очалар иде. «Күрәсезме, әнә ич алар!»

Гадилә як-ягына каранды. Тик кешеләр генә... Кайсы көнбагыш чиртә, кайсы сыра белән балык кимерә, кайсы тәмәке көйрәтә. Берәү дә, хәтта балалар да кыр казларын абайламый калды.

И-и, бәгырь канатларым!.. Сау булыгыз!..

Гадиләгә моңсу булып китте. Түзә аламыни ул еламыйча, тыеп кара син ул күз яшьләреңне?!

## *Күңел күзе*

Синең тәрәзәдән урамга карап торганың бармы? Юктыр, чөнки вакыт таба алмыйсың. Шулайдыр шул... Ә минем бар. Кайчан дисеңме? Өйдә, үзем генә калган чакларда. Тәрәзә төбенә таянып урамга карап торырга үлеп яратам! Кайчагында әкрен генә җырлый-җырлый карап торам, кайчагында елыйм да! Тормыш бит, андый көннәр дә була.

Карыйм һәм күзәтәм. Бер генә дә эшең юк икән, диярсең. Бар, дустым, эшем күп! Эшкә барасым, язасым бар! Әмма тәрәзәдән карамыйча яши алмыйм. Берәүләр «буш вакытта ятып торыйм әле бераз» дип уйласа, мин, тәрәзәдән карап, үземә ял табам. Ашаганда да күзем тәрәзәдә. Урамнан узганда да тәрәзәләргә, анда эленгән пәрдәләргә карыйм...

Тик карыйм гына. Ничек бар, шулай кабул итәм.

Карарга яратуым бер хәл, тәрәзә юарга да бик яратам әле. «Тәрәзә – күңел көзгесе» ди иде әби, мәрхүмәкәй. Гомерем буе тәрәзә чистартам. Янәсе, тәрәзәсе ямьсез кешенең күңеле дә шундый. Үземнең дә, чит-ят җиргә барсам, иң беренче булып күзем тәрәзәләргә төшә. Ул гадәтне ташлый да алмам кебек.

...Эш урынымдагы бүлмәнең өч тәрәзәсе бар. Алар искиткеч зурлар. Кем төзегәндер бу кадәр олы итеп? Бер карасаң, ул шәһәр читенә юлларны күзәтү өчен салынган смотровой ГАИ бүлмәсенә охшап тора. Икенчедән, кышкы суыклар җитсә, интегәбез инде: ябып та, томалап та бетереп булмый.

...Зур тәрәзәдән урамга карап торам. Шәһәрнең бөҗра дигән бер почмагы күренә. Монда троллейбусларның

соңгы тукталышы да, уңга-сулга, базарга, шәһәргә һәм башка якларга китә торган юллар кисешкән урын да.

Бермәлгә үземне җәйге челләдә урман аланында басып торган кебек хис итәм. Агач төпләренә оя корып куйган кырмыскалар күз алдыма килә. Күргәнең бардыр, ничек итеп йөгерәләр, чабалар алар. Кайсы уңга, кайсы сулга. Берсе үзеннән зур йомырка күтәреп, икенчесе йомычка сөйрәп...

Ә биредә кешеләр, машиналар чаба. Берәүләр эшкә, берәүләр эштән. Кемдер кунакка, кемдер кунактан. Берәү үзе китә, берәүне куалар...

Кемнедер... соңгы юлга озаталар. Кара ситсы белән уратып алынган машина артыннан зур бер оркестр килә. Аның артыннан, кара төтен кебек, халык тезелеп киткән. И Алла! Берәү башына төшкән ачы хәсрәт инде бу! Кемнеңдер якыны, кемнеңдер бердәнбере... Ә бәлки?.. Мең сорау.

Тәрәзәдән күп карап йөрсәң, әллә ниләргә таруың бар икәнен дә беләм. Ирексездән туган авыл, андагы кешеләр искә төшә. Безнең авылда, яшьли тол калып, биш баласын ялгыз үстергән, үзенең усаллыгы белән дан тоткан Хәмидә апа яши. Балалары күптән үсеп таралышып беткән. Хәзер ул япа-ялгызы. Авыл җирендә мал-туар асрамаган кеше юк бит инде. Ә аларны сатып алынган азык белән генә туйдыра алмыйсың. Шуңа да авыл кешесе төнлә йокламаска тырыша, азык эзләп ферма юлын таптый. Ә Хәмидә апаның йоклар вакытлары узган, төнлә йөргән каракларны тәрәзәсе аша гына карап тора икән дә, икенче көнне бәйнә-бәйнә совхоз директорына җиткерә икән. (Совхоз директорын аның туганы диләр.) Бер төнне Хәмидә апаның урам якка карап торган дүрт тәрәзәсенең дә пыяласын буяп киткәннәр бит! Майлы буяуны ничек итеп бетермәк кирәк, әй интекте дә, юды-кырды, мескенкәй...

Күзем тәрәзәдә...

...Менә монысы – банк. Аның янында халык бетеп тормый. Акчага килүче күп. Әнә парлылардыр инде,

ир белән хатын чыгып бара. Менә бәхетлеләр, ичмасам! Бер уйласаң, шәһәрдә генә кулга-кул тотышып йөриләр инде. Ә авыл халкының җитәкләшеп йөрергә вакыты да юк, килешми дә кебек... Туп-туры машинага киләләр, иномарка бугай. Машинаның ике ягына басып, бер-берсенә карап озак сөйләшеп тордылар. Шулай инде, яратышсаң, сөйләшер сүзең бетми, карап күзең туймый ул. Утырдылар...

Чү, ни булды? Хатын утырган ишек кинәттән ачылып китте дә, аяклары чуалдымы, бөтен гәүдәсе белән җиргә егылды. Торып басмакчы булып азапланган арада, әле генә аны җитәкләп чыккан ир, йөгереп, машинаның икенче ягына чыкты да... Әни, канатым! Шундый итеп кизәнеп сугып җибәрде ки, хатын янә җиргә барып төште... Юк, тартып торгызмады, машинасына утырды да, кинәт кенә артка чигеп, выжлатып китеп барды. Ә хатын, бераз яткач, торып, өс-башын кагыштырды, аннан әкрен генә юл буйлап атлады... Нигә болай булды соң бу? Җитәкләшеп, матур итеп чыкканнар иде ләбаса. Ник карап торганыма оялып, тәрәзә яныннан эчкәрәк шуыштым. Теге ир, эзләп кереп, миңа да кундырыр кебек тоелды.

* * *

...Монысы машина тәрәзәсе. Мин кабинада, балаларның кибеттән чыкканын көтеп, тәрәзәдән урамга карап торам. Шундый матур язгы көн! Табигать уянган чак. Чалт аяз. Керфек күтәреп карап булмый. Кояш, үртәгән кебек, күзләрне камаштыра. Түбәләрдән тып-тып тамчылар тама. Бар җиһанда тәмле җир исе. Яз яз инде! Ни әйтсәң дә, күңелләр яшәрә, хисләр ташый. Сөясе, сөеләсе, якын кешеңнән җылы сүзләр ишетәсе килә...

Шулчак безнең каршыга, сызгырып, иномарка килеп туктады. Аннан ярсып бер кызый килеп төште дә, машина ишеген дә япмыйча, кызу адымнар белән халык арасына кереп юк булды. Машина хуҗасы да, чыгып, кыз артыннан бераз карап торды әле, аннан соң,

кулындагы бер кочак роза чәчкәләрен... о-ой, асфальтка ташлады. Шомырт кара толымнарын үреп ике якка ташлаган чибәркәйне шушы искиткеч матур чәчкәләрне алмаслык итеп ник үпкәләтте икән бу?..

Тамчы тамып җыелган күлләвектәге шушы кызыл розалар көне буе истән китмәде. «Артык чибәр артка тибәр, – ди иде әби. – Матур булмаса да ярар, батыр булсын, артык матур тәкәббер була ул», – дип, безгә дә матур егетләр сайламаска куша иде.

Тагын бер тәрәзә. Монысы телевизор тәрәзәсе. Әле Чечняда сугыш, әле тагын кайсы җирдә шартлау булган... Кеше үтереш, кан кою. Кемгә кирәк бу? Ни булды сиңа, халкым?! Тыныч, матур көннәрдән туеп буламыни? Ник сугышасыз? Түзә алмас бит җирем, түзә алмас бит!..

Иртән-иртүк тәрәз төбендәге гөлләремә су сибәм.

– И гөлләрем, гөлкәйләрем минем! Сусагансыздыр инде. Менә мин сезгә су эчертим әле. Ходай ризалыгы өчен булсын! «Исән-имин яшәсеннәр, кайгы-хәсрәтсез, бәла-казасыз гомер кичерсеннәр» дип теләк теләгез!

Тәрәзәдән янә урамга карыйм: ике күгәрчен үбешә. «Гү-гү, гөлдер бу-у!» дип берсен-берсе макташалар бугай, тагын үбешәләр.

И-и, туган ягымның талымсыз кошлары! Елның кайсы фасылында да сез безнең белән. Кышкы суыклар да куркытмый сезне. «Гү-гү, гү-гү!»

> Күгәрченнәр ояда, оялары пыяла,
> Күгәрченнәрдәй гөрләшеп яшик әле дөньяда!..

Һәр көн иртән йорт-нигездә таныш тыныч тавышыгызны ишетәм. «Гү-гү, гөлдер гү-ү!» Шуңа иркәләнеп ятагымнан тормый ятам. Тынычлык кошлары шул сез! Матур яшәгән парларга да «Күгәрченнәр кебек гөрләшеп торалар», табындагы ризыкка да «И-и, күгәрчен сөте генә юк монда!» диләр ич, сезнең исемне кушып...

> Тәрәзә, тәрәзәләр! Тәрәзәләрдә... эзләр...
> Караган саен матурлык, күрсеннәр иде күзләр!

## *Яшим, яшим дип...*

Адәм баласы дөньяга туган сәгатеннән башлап яшәргә тырыша. Бала әле ана карынында чагында үзен чорнап алган су эчендәге мохиткә яраклашып яшәсә, туганнан соң, беренче минутында ук аңа яшәр өчен һава кирәк. Тугач та кычкырып елап җибәрүе аның яшәргә омтылуы бит!

Ә ана? Ул да шулай. Туып үскән, аннан укыган, җан яратканы белән кавышып, нәсел дәвамы – бала алып кайткан... Бу да яшәргә тырышу. Үз хәлең хәл, ә башыңны күтәреп баланы күрү, аның беренче авазын ишетү, сәламәт икәнен белү теләге кайсыбызда булмады икән? Үзең дә яшәргә, балаңны да яшәтергә омтыласың бит!

Һәр көн табында җаның теләгән ризыгың, кияр өчен киемең, бала-чагаңның да өсте-башы бөтен булсын дисәң дә, эшләргә, яшәргә тырышырга кирәк!.. Тырышабыз да. Яшәгән саен яшисе, әллә ниләр эшлисе килә!..

Мин дә бөтен сәламәт кешеләр сыман, көн туган саен, Аллага шөкер кылып, дога укый-укый эшкә ашыгам. Табында ни бар, шуның белән ризыкланып, үземә ошаган киемемне киеп, урамнан атлыйм. Тирә-ягымда да минем кебек үк кешеләр, алар да ашыга, каядыр бара, кайта. Кемдер үзеннән зур сумка, кемдер чәчәк тоткан. Кемдер мазутка буялып беткән эш киеменнән, кемдер затлы костюм кигән...

Йөгерәләр, ашыгалар...

Юлым үзәк ял паркы аша үтә. Әле иртә булуга карамастан, эскәмияләрдә утырып торучылар да юк түгел.

...Уйларымның чиге юк. Күңел әллә кайдан матурлык эзли.

Әнә ике яшь пар ничек матур итеп сыенышып утыралар. Ял көннәредер. Аларга карап үтүләре рәхәт. Ирексездән үзеңнең шундый чагың күз алдыннан уза. Тик безнең яшьлек үзгә иде шул. Болай итеп көпәкөндез кочышып утырырга... Ай-һай, ярамый иде.

Ә икенче эскәмиядә әби белән бабай. Тик алар сөйләшмиләр, тын гына тирә-якны күзәтеп утыралар. Мөгаен, әкрен искән җил белән ишетелгән агач яфраклары шавы, аларны да үткәнгә – яшьлеккә алып киткәндер…

Яшьләр киләчәк хыяллары белән яна, ә карт-коры «узган гомер бигрәк жәл» дип уфтана… «Үткән гомер – утсыз күмер» димәсләр иде аны.

…Табигать-ана быел көзне искиткеч матур китерде. Алтынсу сары төскә кергән агач яфракларын аллеяны матурлау өчен махсус элеп куйганнар диярсең! Аяк астында да сары келәм җәелгән кебек. Җиргә басарга да оялып барган чагыңда, җилдә кинәт кыштырдап куйган яфракларны күреп кенә тынычланасың. «Җирдә икән бит мин!» дип уйлап куясың. Бу матурлыкны аңлау өчен, аны үзеңә күреп, тоеп карарга кирәк.

…Кара әле син бу агачны! Исең китәр. Ничек матур итеп үскән. Киң, колачлап та тота алмаслык кәүсә, аннан ботаклары. Әйтерсең һәрберсен үлчәп кисеп куйганнар. Нинди ыспай! Тигез, тыгыз итеп урнашкан ботаклар, чыннан да, ясалма агачны хәтерләтә. Ул да үз чиратында ябалдашларын җилдә тибрәлдереп, «Мине күрәсезме!» дигән кебегрәк масаеп тора. Шәһәр уртасындагы бу паркта агач күп күбен, тик моның кебеге сирәк. Шуңа да ерактан күзгә чалынып, игътибарны җәлеп итә дә. И, күпме гашыйкларны үз ышыгына сыендыргандыр ул, аларның бер-берләренә әйткән назлы сүзләрен ишеткәндер?!

Ә бу агачка әллә нәрсә булган. Үсә алмый калган, күрәсең. Зәгыйфьләнеп утыра. Аның яшәргә тырышкан кәүсәсендәге ботаклары да, «Әй, кешеләр, үтеп китмәгез, миңа да күз салыгыз әле, урыным бик җайсыз. Үземнең генә хәлемнән килми, күчереп утыртсагыз, бәлки, яңа туфрак, яңа җирдә тернәкләнеп китә алыр идем» дигән кебек, сукмакка таба иелгәннәр.

Тукта! Каяндыр гармун тавышы ишетелә түгелме соң? Көзге моңсулыкны ярып, берәү гармун уйный.

...Күрсәм яңадан сезне, дусларым,
Бәхетем арта, белегез шуны.

Әкрен генә, үзем дә сизмичә, гармун тавышы килгән якка борылам. Үзем юл читендә итәкләренә сабыйларын утырткан хәер эстәүче хатыннарны күзәтә киләм. Сабыйлар шушы суыкта туңып, калтыранып утыралар. Өсләрендә дә юка кием... Йә Раббым! Ташлама! Тиеш дип уйласаң да, ярдәмнәреңне бир шул адәмнәреңә. Рәхәтлектән алай чыгып утырмаслар бит инде.

Паркны чыккач, тротуар читендә урындыкка утырган, алдына савыт куйган, берсеннән-берсе матур көйләр уйнаучы гармунчы янына килеп җиттем. Сукыр икән! Аз булса да күрәдерме, юкмы, ике күзен дә йомган. Йөрәгем кысылып, әрнеп куйды. Тумыштанмы?.. Сугыштанмы?..

Һәр ел саен язлар кайта сиңа да, миңа да,
Һәр көн саен кояш чыга сиңа да, миңа да...

Нурын күрә алмаса да, кояш җылысы белән тулган аның күңеле. «Сукырның күзе ябык, күңеле ачык» диләр. Кешеләрдән дә җылылык көтә ул...

Ерак түгел тезелешеп киткән вак-төяк товар сатып торучы әбиләр янында әйләндем дә әйләндем. Тегесен сораган, монысын караган булдым. Кешеләр уза торды. Әмма савытка акча салучы табылмады. Дөньясы әллә нишләде шул, кешеләре кырысланды...

Гармунчы урам көе сузып җибәрде.

Сорамагыз хәлләремне,
Хәлләр сорарлык түгел...

Шулайдыр, хәлең әйбәт булса, җылы өй түрендәге урындыкка утырып кына уйнар идең... Кулым ирексездән кесәмдәге, эштән кайтканда ипи алырга дип салган акчага үрелде. Аз инде ул, ояла-ояла тартмага салдым.

Менә бу моң иясе дә яшәргә тырыша, эшләп ашый! «Тукта әле, иртән-иртүк торып эшкә баручыларның

күңелен күрим әле», – дип урамга чыкмаган бит инде ул, юклыктан аптырап чыккан...

Эшкә җилкенеп килеп кердем. Бәлагә тарган берәүнең хәлен белгән кебек хис иттем үземне. Олы бер яхшылык эшләгәндәй канатланып, көне буе күңелемнән гармунчы уйнаган көйне көйләп йөрдем...

Тормыш кадрен белеп яшик, дуслар!
Нинди матур итеп сайрыйлар кошлар.

Яшәгән саен яшисе килә...

Өч кенә көнлек тормышның кадерләрен белеп яшик әле, туганнар!..

## *Музейда*

Әни, канатым!.. Сугыштан кайткан су фляжкасы. Ничәмә-ничә ел аңа?! Тәннәрем чымырдап куйды. Бер җыерылдым, бер куырылдым. Әйтеп тә, аңлатып та бетереп булмас бу халәтне. Кечкенәдән киноларда гына карап белгәнгә, тарих укытучысы Әсгать абый сөйләгәннәрдән генә сугышның нәрсә икәнен чамалаганга, күргәч тә бераз тын алалмый тордым. Колагыма чиелдап төшкән бомба тавышлары ишетелде. Алар менә-менә төшеп җитәрләр дә... Ай! Ике кулым белән башымны тотып читкәрәк киттем.

Юк, беркая да китеп булмый, яңадан үз урыныма әйләнеп килдем.

Сугыш кыры... Ядрәләр шартлый... Яралылар... Балалар... Юк, Аллам сакласын! Ходаем күрсәтмәсен ул афәтне!

Яньчелеп, кырылып беткән су савыты... Ниләр генә күрмәдең икән дә, кемнәрнең генә соңгы сулышларын ишетмәдең икән син?.. Бәлки әле, кемне дә булса үлемнән алып калгансың?.. Килеп тигән пуля сине күкрәк кесәсендә йөрткән сугышчыны саклагандыр...

Суыңны эчеп, япан кырдамы, окоптамы берәр сугышчы сусавын баскандыр...

Санитар кызның авыр ябалардан сызланып яткан егеткә әйткән, беркем, беркайчан кабатлый алмый торган юату сүзләрен дә ишеткәнсеңдер әле син...

Күзләрем белән карап, фляжканы пыяла аша гына сыйпагандай иттем. Тәнемне янә өшү биләп алды, куркып киттем. Кулым белән ялгыш кагылырмын да аның мәңгегә тынып калган тынычлыгын бозармын кебек тоелды. Яңадан дөбер-шатыр бомбалар шартлар... пулялар... танклар...

Юк! Кирәкми! Берүк сугыш кирәк-яраклары шушында гына, музей экспонаты булып кына тора бирсеннәр!..

Кирәкми кан кою! Дөньялар имин булсын, балалар ятим үсмәсен! Кирәкми сугыш! Йә Раббым, үзең сакла! Яман бәла-казадан, сугыш утыннан, кайгы-хәсрәттән, үлем афәтеннән сакла!

Кечкенә әлүмин фляжка! Нинди күп ачылмаган сер ята синдә?!

Нинди зур хәсрәт сыйдыргансың син үзеңә. Күргәннәреңне аңлап, тасвирлап бирә алсам да, серләреңне мәңге белә алмам...

Шушы бер мизгелдә сугышчы җилкәсендә йөргән әлүмин савытны күреп кенә дә күз алдыма олы бер тарих – сугыш чоры килеп басты.

И-и Аллам! Сугыш эчендә, ут арасында, окоп һәм блиндажларда ятканда ниләр генә уйлады икән безнең әтиләр?..

# *Эчтәлек*


Иҗат кыйбласы – ихласлык. *Л.Кәшфи* . . . . . . . . . . . . . . 3


## Хикәяләр


Җыр иясен көтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Каргыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Болытлар артында кояш бар . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
«Художник» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Кеше өсте – без өсте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Курыктым шул, улым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Кабатлана икән язмышлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Күңел җылысы җитә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Изге Рамазан ае иде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Күрәчәк күренеп килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Кунак ашы кара-каршы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Бака . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Сусылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Сары яулык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Кызыл диплом . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Ул чакта да... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Көтүдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126


## Парчалар


Кыр казлары киткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Күңел күзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Яшим, яшим дип... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Музейда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

Литературно-художественное издание

**Ахметшина** Минзифа Хайретдиновна

***Желтый платок***

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Әхмәтшина** Миңзифа Хәйретдин кызы

***Сары яулык***

Мөхәррире *Л.М.Шәехов*
Рәссамы *Д.А.Шульятева*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.04.2010.
Форматы 70´100 1/32. Шартлы басма табагы 5,85.
Тиражы 500 д. Заказ О-435.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru. e-mail: tki@tatkniga.ru.**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.